**Министерство образования и науки Республики Татарстан**
**МБОУ «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа № 71**
**с углубленным изучением отдельных предметов»**
**Ново-Савиновского района**

# ЛИШЬ ТЕБЕ, НАРОД, СЛУЖЕНИЕ…

*Открытые педагогические чтения имени татарского просветителя,*
*педагога и общественного деятеля Мухлисы Буби*

**Казань – 2014 г.**

УДК ?
ББК ?
Л ?

*Редакторы:*

**Т.Р.Шакирова**, Заслуженный учитель Татарстана, директор высшей квалификационной категории муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани;

**Р.Р.Кашапова**, заместитель директора первой квалификационной категории по вопросам национального образования муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани

**Л ?** **Лишь** тебе, народ, служение... – Казань: РИЦ «Школа», 2014. – 292 с.

В сборник включены тезисы научно-исследовательских работ учителей школ г.Казани и республики, представленных на II республиканских педагогических чтениях имени татарского просветителя, педагога и общественного деятеля Мухлисы Буби. Сборник адресован преподавателям общеобразовательных организаций.

© МБОУ "Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов", 2014
© РИЦ «Школа», 2014

# ЛИШЬ ТЕБЕ, НАРОД, СЛУЖЕНИЕ!



***Педагогические чтения посвящены одной из наиболее ярких страниц истории татарского просветительства – женскому образованию конца 19 – начала 20 веков. Огромен вклад татарских женщин в образовании девочек татарок. Одна из этих замечательных женщин – Мухлиса Буби.***

***Сегодня о Мухлисе Буби вспоминают не только как о просветителе, религиозном деятеле, но и как о первом политике среди татарских женщин.***

Выдающаяся личность – представитель знаменитой семьи просветителей Мухлиса Нигматуллина (Буби) родилась в 1869 году в деревне Иж-Буби Сарапульского уезда Вятской губернии в семье деревенского муллы Габделгалляма (сегодня это деревня Иж-Буби Агрызского района Республики Татарстан).

Мухлиса уже в четырехлетнем возрасте научилась читать и писать. Ее мама Бадрульбанат абыстай позднее обучила дочь арабскому и персидскому языкам. В распоряжении талантливой девочки оказалась богатая домашняя библиотека отца.

В 18 лет Мухлису выдают замуж за немолодого муллу из Мензелинского уезда. Личная жизнь девушки не сложилась. Со своей дочерью Мунжией и приемной дочерью Нажией она вернулась к своим родителям.

Вернувшись в родной дом, Мухлиса вместе с братьями, их женами приступает к созданию школы для девочек. К этому делу молодые просветители относятся с особым трепетом, так как считают, что именно воспитание и обучение женщин, предоставление им широких возможностей для повышения уровня образования и культуры – одно из необходимых условий преодоления отсталости и обеспечения прогресса нации.

Благодаря их стараниям, Иж-Бубинские школы становятся известными не только в своей округе. Учиться сюда приезжают из Москвы, Ка-

зани, Уфы, Симбирска, Самары, Астрахани, Ташкента, Петропавловска, Семипалатинска и других городов.

В 1905-1908 годы Буби добиваются открытия при своих школах мектебах) педагогических училищ (медресе). В 1907 году им разрешают принимать экзамены и выдавать свидетельства о присуждении звания учителя-мугаллима и учительницы-мугаллимы. Эти свидетельства являлись официальным документом и признавались административными округами России.

Во время столыпинских реформ татарские школы начинают закрывать под предлогом, что они разрушают российское государство.

В 1912 году после закрытия женского медресе Мухлиса начала работать учительницей в троицкой школе Г.Ахмарова. Она сумела убеждить местных мурз в необходимости открытия школу для девушек «Сююмбика». В 1915 году Мухлиса возглавила женскую учительскую семинарию «Дарульмугаллимат».

10 мая 1917 года на Первом Всероссийском мусульманском съезде Муслиха Буби была избрана духовным судьей (кази) в Центральное духовное управление мусульман России. Это был первый и единственный случай в исламском мире, когда женщина-мусульманка была избрана казией – судьей по шариатским делам.

М.Буби выступала с публикациями в журналах, составляла фетвы, выступала арбитром по семейным проблемам.

Мухлиса быстро заработала авторитет и известность. О ее справедливости, честности в народе слагались легенды. Именно к ней, в Уфу, за сотни верст, в поисках защиты и справедливости стекались тысячи обездоленных женщин и находили у нее помощь и понимание.

Волна репрессий не обошла стороной и ЦДУМ. Блестящий педагог, более 20 лет отдавшая делу распространения женского образования среди мусульманок России, авторитетнейшая казия ЦДУМ, прослужившая верой и правдой на этом посту 20 лет, Мухлиса Буби на заседании Тройки НКВД Башкирской АССР 30 ноября 1937 года была обвинена в участии в «контрреволюционной повстанческой националистической организации Башкирии» и расстреляна 23 декабря 1937 года.

*Т.Р.Шакирова,*
*директор МБОУ «Школа№71»*

# ЗАГОЛОВОК НУЖЕН?

| | | |
|---|---|---|
| 10.00 | **Открытие педагогических чтений** | Шакирова Т.Р., директор МБОУ «Школа №71»<br>Литинский С.И., директор Детско-хоровой школы №3 |
| | Становление светского образования<br><br>Инновации в системе образования | **Махмутова А.Х.,** к.и.н., доцент, лауреат премии им.Ш.Марджани АН РТ<br>**Гибатдинов М.Г.,** к.и.н., институт истории им.Ш.Марджани АН РТ |
| 11.00 | Работа лабораторий | |
| **Лаборатория**<br><br>Ведущая идея | **Система национального образования: история и современность.**<br><br>Национальному образованию принадлежит ведущая роль в сохранении и формировании у подрастающего поколения национального самосознания. | **Руководитель**<br>Музафарова М.Г., к.п.н., зав.лабораторией национального образования ИРО РТ<br><br>Кашапова Р.Р., зам.директора по вопросам национального образования МБОУ «Школа №71» |
| **Лаборатория**<br><br>Ведущая идея | **История татарского просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби**<br><br>Подобного очага просвещения не было в то время не только у татар, но, пожалуй, и во всем мусульманском мире. | **Руководитель**<br>Гимазова Р.А., к.и.н., старший научный сотрудник института истории им.Ш.Марджани АН РТ<br><br>Шакирова Т.Р., директор МБОУ «Школа №71» |
| **Лаборатория**<br><br>Ведущая идея | **Созвездие имен – история хранит их…**<br><br>Независимо от того, из каких слоев вышли эти девушки и женщины – из села или города, из крестьянской семьи или из дворянской… – они стремились к одной великой цели – способствовать процветанию своей нации.<br><br>Фотографии столетней давности без искажений доносят до нас и их скромность, и изящество, и умный одухотворенный взгляд, и глубинную красоту их душ. | **Руководитель**<br>**Махмутова А.Х.,** к.и.н., доцент, лауреат премии имени Ш.Марджани АН РТ |

| | | |
|---|---|---|
| Лаборато-рия<br><br>Ведущая идея | **Стратегия профессионального развития педагога**<br><br>Только тот может стать учителем, кто способен идти по дороге самоусовершенствования и вести по ней других.<br>К.Д.Ушинский.<br><br>Школьные учителя обладают властью, о которой премьер-министры могут только мечтать.<br>У.Черчилль | **Руководитель**<br>Кадырова Х.Р.,к.п.н, директор Зеленодольского института машиностроения и информационных технологий (филиала) КНИТУ(КАИ) |
| **Лаборато-рия**<br><br>Ведущая идея | **Школу реформирует учитель**<br><br>Менять педагогические ориентиры – это самое трудное и самое необходимое, что приходится делать сегодня.<br>В.А.Караковский | **Руководитель**<br>Бронникова Э.К., заведующая УМС ИМО УО ИКМО г.Казани по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам<br><br>Гимранова А.Р., зам. директора по начальному образованию МБОУ «Школа №71» |
| **Мастер-класс**<br><br>Ведущая идея | **Чаша педагогической мудрости**<br><br>Дети не готовятся к жизни, они уже живут. | **Руководитель**<br>Гумерова Ф.Г., зам.директора по учебной работе МБОУ «Школа №71» |
| Мастер-класс<br><br>Ведущая идея | Дошкольное обучение | |
| **Мастер-класс**<br><br>Ведущая идея | **Учитель среди учеников**<br><br>Учитель работает над самой ответственной задачей – он формирует человека.<br>М.И.Калинин<br><br>Воспитательная роль учителя определяется прежде всего теми отношениями, какие существуют между учителем и учениками.<br><br>Личность – это то, какие выборы человек делает на протяжении своего жизненного пути. | **Руководитель**<br>МухаматгалееваМ.Ф., директор МБОУ «Гимназия №13» |

| | | |
|---|---|---|
| **Мастер-класс**<br><br>Ведущая идея | **Духовный мир учителя**<br><br>Учитель не профессия, а личное звание человека.<br>Кто постигает новое, лелея старое, тот может быть учителем.<br>Конфуций | **Руководитель**<br>Фатхутдинова Г.А., директор МБОУ «Школа №43» |
| **Мастер-класс**<br><br>Ведущая идея | **Родители – первые учителя**<br><br>Без дружеского взаимодействия, без тонкого взаимопонимания учителя и родителя, школы и семьи невозможно счастье ребенка, жизнь его может лишиться счастья, а без этого нет детства.<br>В.А.Сухомлинский | **Руководитель**<br>Гумерова Г.Х., к.т.н., доцент кафедры инженерной компьютерной графики КНИТУ-КГТУ-КНИТУ, член родительского комитета |
| **Мастер-класс**<br><br>Ведущая идея | **Тренинговое занятие «Развитие профессионального самосознания»**<br><br>Кто в самом себе не носит источника живой деятельности, кто не надеется на себя, – тот вечно ожидает всего от внешнего и случайного.<br>В.Г.Белинский<br><br>Изучайте законы тех психических явлений, которыми вы хотите управлять, соображаясь с этими законами и теми обстоятельствами, в которых вы хотите их приложить.<br>К.Д.Ушинский | **Руководитель**<br>Челнокова Т.А., д.п.н., профессор ИЭУиП<br><br>Саляхутдинова Е.В. педагог – психолог МБОУ «Школа №71» |
| **14.00 Подведение итогов** | Сообщение о результатах работы лабораторий | Руководители лабораторий |
| **14.30** | **Персона** | **Сунгатуллина Зиля Даяновна**, народная артистка РФ,РТ, лауреат Государственной премии РТ им.Г.Тукая, кавалер Ордена Дружбы народов, профессор консерватории им.Н.Жиганова. |

# ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮЧЕ ЯҢА ГАСЫР ГАЛИМЕ: МИНЕМ КАРАШ

***Булатова Гүзәл Рамил кызы***
*11 сыйныф укучысы*
*Җитәкче:* ***Хуҗанбердиева Чулпан Тимергали кызы,***
*югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Түбән Кама муниципаль районы Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “35 нче лицей”*

***Туган телеңне өйрәнүгә кем комачаулый? Менә миңа беркем дә комачауламый. Мин үз телемдә сөйләшәм. Мине беркем дә тыймый. Үз балаларын туган телләренә өйрәтә алмаган килеш бөтен халык алдында милли сәясәт турында сүз куертучы кешеләр өчен оят миңа. Үз мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне сакларга телибез икән, баланы гаиләдә телебезгә, гореф-гадәтләребезгә өйрәтергә тиешбез.***

***Р.Н. Миңнеханов***

Туган тел ул – Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә тора торган бөек, изге һәм кадерле сүз. Аны тугач та ишетә һәм өйрәнә башлыйсың, шуңа күрә аны туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы, башлап, аның иң газиз кешесе – анасы өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырлары җырлый, иркәли, юата, шуңа күрә халык аны ана теле дип тә йөртә.

Соңгы арада татар яшьләре арасында үз телләрендә сөйләшә белмәүчеләр көннән-көн ешрак очрый башлады. Кемнедер әти-әнисе кечкенә чагында ук өйрәтмәгән, ә кемдер бәләкәй чагында рәхәтләнеп туган телендә сөйләшкән булса да, төрле сәбәпләрдә аны оныткан. Елдан-ел татар теленнән имтихан бирүчеләр саны да кими бара. Узган уку елында Татарстаннан 40 укучы – татар теленнән, 5се татар әдәбиятыннан бердәм дәүләт имтиханнары тапшырган. “Без моның белән көрәшәбез. Аның белән берничек тә канәгать кала алмыйбыз. Мәктәптә ана теле укучы кызыксынырлык итеп бирелми. Шуңа аны балалар бакчасында өйрәтүне көчәйттек”, – дип ассызыклый фән һәм мәгариф министры.

Ә югары уку йортлары, студентлар, тел-әдәбият белгечләре бүген ни хәлдә?! Гөрләп торган, ел саен көндезге һәм читтән торып уку бүлегенә 200дән артык студент кабул итә торган, ничәмә-ничә язучы, шагыйрьне олы иҗат юлына бастырган, үз галимнәре белән аерылып торган, минем әниемә, шулай ук безнең татар теле һәм әдәбияты укытучысына газиз булган КДУның атаклы татар факультеты бүген кайда һәм ни хәлдә? Бу сорауларга җавапны, бәлки, ачык ишекләр көнендә таба алырмын...

Минемчә, XXI гасыр галиме үз эшен татар телен һәм әдәбиятын чагыштырмача өйрәнеп, шул рәвешле, чагыштыру объекты итеп алангын башка тел һәм әдәбиятлары белән бер рәттә, татар теле һәм әдәбиятының аерым урыны барлыгын, аның хәтта камилрәк, үзенчәлерәк икәнен дәлилләү өстендә эш алып барырга тиеш. Мәсәлән, Тукай – Пушкин, Ә. Еники – Бунин, Г. Әпсәләмов – А.П. Чехов, Дәрдемәнд – Лермонтов, Р. Гаташ – С. Есенин, Байрон һ.б. Татар теленең рус, инглиз, көнчыгыш телләр белән уртак һәм аермалы якларын билгеләү шул телләрдә сөйләшүче кешеләрнең татар теленә карата кызыксынуын уята ала. Татар телен өйрәнергә теләүчеләргә үз телләре белән охшаш һәм аермалы якларны күрү өйрәнүдә зур ярдәмлек булачак. Мәсәлән, шул ук инглиз телендә аралашучы кеше татар теле белән танышуның беренче көнендә үк бәби – беби шул ук мәгънәдәге сүз икәнен белсә, бу телләр арасында күп гасырлар элек бәлки бәйләнеш булгандыр дигән кызыксыну уятыр: бу тел, халык каян килеп чыккан, аның тамырлары кая барып тоташа һ.б. сорауларга җавап табарга мәҗбүр итәр.

Галимнәр эшчәнлегенең икенче юнәлеше ул – татар телен чит тел буларак өйрәнүчеләр өчен on-lain китаплар, дәреслекләр булдыру. Бу юнәлешкә бик яхшы үрнәкләрне мәгариф министрлыгы тарафыннан әзерләнгән “Электрон мәгариф” порталында (www. edu.tatar.ru) табарга мөмкин. 15 темага лексика, грамматика, аудирование, диалоглар бүлекләре урнаштырылган. Шундый ук әдәбият тарихы, теориясе, язучы-шагыйрьләрнең тормыш юлы, иҗатына багышланган электрон китапларны күрәсе килә: фото-архив материалларын кулланып фильмнар, иҗаты белән таныштыру (аудиоязмалар, спектакльләр), ахырда тест сораулары, әсәргә анализ ясау калыбы (А.Яхин, А. Әхмәдуллин методикалары буенча), иҗади эш төрләре, аларга бирелгән темалар. Шул вакытта гына балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, урта проф. белем бирү йортларында укучылар бу дәресләргә теләп, зур кызыксыну белән йөрерләр, чыннан да хөрмәт итәрләр, өйрәнерләр, яратырлар. Хәзерге көндә мәктәпләрдә иң кызганыч хәлдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары, чөнки дәреслекләр эчтәлек һәм форма ягыннан яңартылмый. Инглиз теле

дәреслекләре кебек дәреслек + эш дәфтәре, сүзлекләр, аудиоязмаларны үз эченә алган уку-укыту комплекслары бездә кайчан булыр микән?

Минемчә, үз халкы, теле турында кайгырткан татар галимнәре иң беренче шуны аңларга тиеш: син тырышып, күпме көч куеп тикшереп, өйрәнеп, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре язган язучы иҗаты тиздән, болай барса, беркемгә дә таныш булмаячак. Ул шагыйрь-язучыны ишетеп булса да белгәне берәр әсәрен укырга теләсә – аңларлык дәрәҗәдә теле булмас. Бүгенге татар галимнәре балаларга, гомумән халыкка дөрес сөйләм культурасы, әдәпле тел тәрбияләү өстендә эш алып барырга тиеш.

*Фәннән сине аерса да*
*Гасырларның афәт җиле,*
*Аксакалларыңдай олпат,*
*Акыллы син, татар теле. (Н. Нәҗми)*

## ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ КЫССАЛАРЫНДА УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**_Вагизова Фәридә Гыйбадулла кызы_**
*Яңа Чишмә муниципаль районы*
*Зирекле лицееның югары категорияле*
*биология, география укытучысы*

Һәр халыкның үз тарихы, теле, гореф-гадәтләре, дине, йолалары бар. Бары тик шушы үзенчәлекләр генә милләтне – милләт, халыкны – аерым халык буларак бәяләүче төп күрсәткеч булып тора. Бүгенгесе болгавыр заманда, яшәешебездә акча һәм бары тик акча гына өстенлек иткән, һәрбер нәрсә “акча күзлеге” аша гына бәяләнгән чорда, илебез буйлап урыслаштыру сәясәте киң колач белән алып барылган вакытта, үзенең кешелек дәрәҗәсен җуймаган, үзен “милли рухлы кеше” – дип санаучы һәркем өчен, милләтебезне, телебезне саклап калу өчен армый-талмый хезмәт итү бурычы куела. Ни өчен бу мәсьәлә көнүзәк әһәмияткә ия соң? Чөнки еллар үтү белән буыннар алмашы нәтиҗәсендә халкыбызның гүзәл мәдәниятен, әхлагын, гореф-гадәтләрен аз белүче яки бөтенләй белмәүче, хәтта татар телендә дөрес, матур итеп, чиста әдәби телдә сөйләшә дә алмаучы яңа буын үсеп җитте. Дәүләтебез тарафыннан (СССР вакытында

да, хәзер дә) башка милләтләргә карата алып барылган милли сәясәтнең дә җимешләре өлгерде. Нәтиҗәдә милли горурлык, рухи байлык дигән төшенчәләр арткы планга күчте, “милли үзаң” дигән сүзтезмә үзенең әһәмиятен югалтты. Элек-электән башка милләтләрдән үзенең тотнаклылыгы, зыялыгы, әдәп-әһлаклылыгы белән аерылып торган татар милләте, бу күркәм сыйфатларын югалта барып, соры массага әверелеү чорына килеп җитеп бара. Шушы куркыныч преспективаны күзаллап, барыбыз өчен дә мөһим булган төп максат билгеләнә – халкыбыз җәүһәрләрен, милли, дини традицияләребезне, тарихи-мәдәни мирасыбызны саклап калу, яшь буында милли үзаң тәрбияләү, 90-нчы елларда башланган әхлакый-рухи яңарышны яңадан торгызу. Чөнки бу максат турыдан-туры халкыбызның киләчәк үсеше белән, милләт буларак сакланып калу-калмавы белән бәйле. Бу юнәлештә эшләү өчен иң кулай мөмкинлек – уку-укыту, тәрбия бирү юнәлешендәге оешмалар. Безнең Зирекле лицеенда да, бала үзенең милләте, үзенең татар баласы булуы белән горурлансын, үз тамырларын белсен, – дигән юнәлештә максатчан эш алып барыла. Бу – төрле сыйныфтан тыш чаралар да, дәресләрдә милли компонентларны, җирле материалларны актив файдалану да, авылда эшләп килүче китапханә, авылыбыз көнкүреше музее, “Аҗаган” яшьләр спорт клубы белән тыгыз элемтәдә тору да. Бары тик үз илен, туган җирен яраткан, үз авылы тарихын, тирә-ягын чолгап алган табигатен күрә, аңлый, саклый белгән кешедә генә милли хисләр, горурлану, хөрмәт итә белү кебек сыйфатлар тәрбияләп буладыр ул... Шуңа күрә дә мин биология, география, экология кебек турыдан –туры табигатьне өйрәнүче фән курслары кысаларында милли үзаң, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияләү кебек тәрбияви юнәлеш эшчәнлеген актив кулланырга тырышам. “Теләгән табар – ташка кадак кагар”, – ди татар халык мәкале. Бу чыннан да шулай. Теләсә кайсы теманы өйрәнгәндә дә үз авылың, районның, республикаңда булган мисалларны актив файдалану мөмкинлеге бик зур. Мәсәлән: 6-нчы сыйныфта ботаника курсы – үзебезнең авылыбыз тирәсендә үскән, үзләре һәрвакыт күреп белгән үсемлекләрне аерып, аларның татарча, диалекталь (әрекмән – әпертмән – кырмавык) исемнәрен өйрәнү, Татарстан, район, авылыбыз тирәсендә үскән, төрле-төрле үсемлек бүлекләренә караган (суүсемнәр, абага, наратбаш, плаун һ.б.,һ.б.) үсемлекләрне барлау, “Кызыл китап”ка керүче (урман лилиясе, алтын туй чәчәге), саклауга куелганнарны (ландыш, өргәзимбай чәчәкләре) ачыклау. 7– нче сыйныфта – зоология курсы – хайваннар дөньясын өйрәнгән вакытта да шундый ук юнәлештә эш алып барыла. 9-11 сыйныфларда гомуми биология курсы кыссаларында да бу юнәлештәге эшне оештырып була. Биоценозлар төрлелеге,

биогеоценозларның үзенчәлекләре, структурасы белән танышканда җирле компонент мисалларын куллану аеруча уңай нәтиҗәләргә китерә.

Биология фәнендә бу максат, бары тик тереклек дөньясы аша гына аңлатылса, ә география курсы ул инде тулаем терек булмаган табигатьне өйрәнү – “ни өчен шулай”, “ни сәбәптән болай булган” кебек сорауларга җавап табу. Мәсәлән, 6-нчы сыйныфта географик координаталар темасын үткәндә кайсыдыр материктагы ниндидер шәһәр, тауларны табуга караганда үзләренә якын булган Казан шәһәре, Идел, Кама елгалары башлангычын, койган урынын табу укучылар өчен күпкә кызыклырак. “Җир өсте сулары”, “Табигый зоналар” темаларын өйрәнгәндә республикабыз елга-күлләре, бездә үсүче агач, чәчәк исемнәре белән бәйле шигырь, җырларны ачыклау, татар халык мәкаль, әйтемнәрен куллану да милли үзаң тәрбияләүдә алыштыргысыз чараларның берсе булып тора. Ә 8-9-нчы сыйныфларда – Россия иле география сен өйрәнгәндә һәр бүлекне (рельеф, климат, туфрак, промышленность һ.б.) узган саен 1-2 дәрес дәвамында үз республикабызны өйрәнү (бу уку-укыту программасына кертелгән), үз авылыбызга хас булган үзенчәлекләрне ачыклау дәресләрне мавыктыргыч итүдә иң төп алшартларның берсе.

Экология фәне мәктәбебездә фән буларак укытылмаса да искиткеч күп төрле юнәлешләрне үз эченә ала. Шуңа күрә без, укучылар белән киңәшләшеп, лицеебызда “Яшел десант” исеме астында экоүзәк оештырдык. Экоүзәк эшчәнлегендә теләге булган һәркем катнаша, үзен кызыксындырган темалар юнәлешендә эшчәнлек башлар өчен тәгъдимнәр кертә ала.

Ә эшләребез чыннан да күпкырлы: агачлар утыртудан алып «Чишмә», «Ватанны саклаучылар паркы» проектлары, « Иң чиста урам», « Су буйлары бигрәк ямьле» диеп аталган акцияләр. Төрле экологик эчтәлектәге конференцияләрдә катнашу, темаларда үз төбәгең үзенчәлекләрен өйрәнү кебек темаларга зур игътибар бирү. Алда санап үтелгән барлык эшчәнлекләр балаларда милли үзаң тәрбияләүдә ярдәм итүче төп чаралар була ала дигән ышаныч тудыра.

# МӘКТӘПТӘ УКУЧЫЛАРГА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ

***Гарипова Гүзәлия Хәбибрахман кызы***
*Балык Бистәсе муниципаль районы*
*Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе*
*“Туган якны өйрәнү музее” җитәкчесе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

XIX гасырда ук күренекле мәгърифәтче, педагог, галим Шиһабетдин Мәрҗәни: ”Үзенең үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк.!”– дип әйтеп калдырган. Халыкның тарихын күзаллауда, үткәннәргә карап киләчәк турында фикер йөртүдә, балаларда кызыксыну тәрбияләүдә, музейларның әһәмияте зур. Безнең Балык бистәсе муниципаль районының һәр уку йортында диярлек туган якны өйрәнүче музейлар бар. Эш юнәлешебезнең проблемасы: туган як тарихын, мәдәниятен, табигатен, җирле гореф – гадәтләрне өйрәнү; балаларга патриотик тәрбия бирү. Араларында яңа гына ачылганнары да, озак еллар тәҗрибә туплап, уңышлы гына эшли торганнары да бар. Ә менә инде безнең Биектау мәктәбенең “Туган якны өйрәнү музее” ачылуга быел 28 ел булды. Музей тирән эчтәлекле, тарихи һәм тәрбияви яктан әһәмиятле булган күп санлы экспонатлары белән генә түгел, зәвыклы бизәлеше белән дә үзенә безне тартып тора.

Музей 6 бүлектән тора. Анда 5004 ләп экспонат исәпләнә. Музейның күпчелек өлеше, элеккеге татар крестьяны тормышына багышланган. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә өчпочмаклы Солдат хатлары да саклана. “Хәрби – патриотик тәрбия” бүлегендә дә шулай ук бик күп мәгълүматлар тупланган.. Хәрби – патриотик тәрбия бирүнең максаты – укучыларга Ватанны сакларга әзер булуның ни дәрәҗәдә җаваплы бурыч икәнен бөтен тулылыгы белән төшендерү; Ватанын, илен яратучы, өлкәннәрне хөрмәт итүче шәхесләр тәрбияләү.

Хәзер инде бу төшенчәгә ачыклык кертергә кирәк. Кем ул патриот? Патриотизм нәрсә ул? “ Патриот – үзенең туган җирен, халкын, илен, ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше”.

Укучыларда Ватанны, туган якны ярату, аның белән горурлану хисе тәрбияләү – иң мөһим бурычларның берсе. Безгә патриотик тәрбия бирүдә,туган якны өйрәнү музее, мөһим урын алып тора. Билгеле булганча, 19 нчы сентябрьдә район күләмендә үткән координацион совет карары, эшебезгә максат куйды һәм шуннан чыгып, туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәнендәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышла-

рына ихтирам һәм горурлык хисләре,укучыларда милли аң, уңай караш тәрбияләүдә күп кенә эшләр башкарабыз.

Тиздән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 69 ел тулуны, ягъни Җиңү бәйрәме тантана итүне оештырачаклар. Музеебызда сугыш кырында иң авыр җирләрдә хезмәт иткән солдатларыбызга багышланган стенд, фронттан килгән өчпочмаклы солдат хатлары урын алган. Стендта Гарипов Хәбибрахман, Шакиров Шәфыйкъ,Хәсәншин Хәбибрахман, Закиров Хәсән. Алар -дәүләтебезнең иң югары бүләкләренә,мактауларына лаеклар.

Патриотик тәрбия дигәндә, без, үлемсез шагыйрь М.Җәлил шигырьләрен алабыз, аларда илгә мәхәббәт, сагыну, ир исемен югары тоту, изге антыңа тугрыклы булу кебек гүзәл сыйфатлар алына. ”Туган якны өйрәнү” челәр белән берлектә М.Җәлилнең үлемсез җыры “Җырларым” шигыре эчтәлегенә нигезләнеп:

*Җыр өйрәтте мине хөр ишәргә,*
*Һәм үләргә кыю ир булып.*
*Гомерем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңгырар җыр булып, –*

дигән темага сөйнеф сәгате һәм татар халкының герой – шагыйре М.Җәлилнең тууына 108 ел тулуга багышланган “Җәлил безнең күңелләрдә”, – дип исемләнгән шигырь бәйгесе үткәрелде.

2012-2013 елны район үзәк музеенда булып, туган як тарихы белән якынрак таныштык. Районның “Батырлар аллеясы”на, “Авыл офыклары” газетасы редакциясенә һәм Чаллы шәһәрлеге урыннарында булу, бездә зур кызыксыну уятты.

Бүген музеебызда яшьләргә патриотик тәрбия бирү юнәлешендә күп кенә эшләр алып барыла. Мәсәлән:”Тупчы Зәки”,”Мәктәп тарихы”, ”Авылтарихы”, ”Алар Ватан өчен көрәштеләр”, ”Безнең авылдашлар гражданнар сугышында”, “Интернационалист-сугышчылар”, ”Хезмәт батырлары” һ.б.

Мәктәбебездә үткән координацион совет карары эшебезгә тагы да зур этәргеч бирде. Патриотик тәрбия бирүдә тыл ветераннарыбызның да тир түгеп хезмәт иткән еллары күп нәрсә сөйли. Минем иң тирән хисләр калдырган тәрбияви чара дип Г.Кутуйның “Сагыну” нәсере эчтәлегенә таянып эшләнгән,”Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!” – дигән тема астында оештырылган кичәне әйтеп үтәсем килә. Кичәне Ватан сугышы ветераны Вәлимөхәммәтов Муллахмәт абый, Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил ! – дигән юллар белән тәмамлады.

Безнең “Туган як”әгъзаләре һәм “Таң йолдызы” ошмасы укучылары, үзләренә беркетелгән ветераннарга, ялгыз яшәүче әби – бабайларга бул ышлык итәләр, тимурчылык эшен алып баралар. Ярдәмгә мохтаж әби – бабайларның өйләренә барып, идән юалар, кар көриләр, су китерәләр, утын өяләр, өй җыештыралар.

2013 елның ноябрь аенда районыбызда һәм безнең авылыбызда Хәтер Маршы үткәрелде. Аның маршруты Рус Әшнәге, Балык бистәсе, Биектау авыллары аша узды. Маршта катнашучылар Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә куелган һәм Советлар Союзы Геройлары Александр Сергеев, Зәки Шәймәрданов обелискларына гирляндалар салдылар.

Татарстан Республикасы Бөек Ватан сугышы музей – мемориалы мөдире Михаил Черепанов җитәкчелегендәге Казан Хәрби Дан клубы активистлары, эзләнү отрядлары сугышчылары бик тә игелекле максаттан аяк бастылар. Ул да булса моңа кадәр Икенче Бөтендөнья сугышында хәбәрсез югалган дип саналган якташларыбызның һәлак булган урыны һәм вакыты турында мәгълүматларны Геройларның туганнарына тапшыру иде.

Ел саен мәктәбебездә истәлекле кичәләр, шул исәптән 23 нче февраль, “Ягез әле, егетләр!”,”Ажаган”,”Солдат хатлары”,”Әфганчылар” кичәләре уздырыла. Менә болар безгә сугыш кырын, аның рәхимсез икәнен тасвирлый торган күргәзмә материаллар. Бирегә без Әфганстанда, Чечняда, илебезнең төрле төбәкләрендә хезмәт итеп кайткан ир-егетләребезне чакырабыз. Чыннан да болар “телле” шаһитлар. Ватан өчен хәзмәт итүнең нәрсә икәнлеген алар, эчтәлекле, үтемле итеп сөйләделәр һәм сөйли бирәләр.

Бездә янә зур тантана булып үтте. Каһарман авылдашыбыз, Советлар Союзы Герое Шәймәрданов Зәки Шәймәрдан улының истәлегенә мемориаль такта куелды. Ул күрсәткән батырлыклар һич онытырлык түгел, аларны киләчәк буыннар да онытмасын иде!

Гомумән, мәктәп музейлары безгә зур тәрбия учагы булып тора. Әүз илеңне, Ватаныңны, халкыңның тарихын, үткәнен белгән, табигатен яраткан бала, әлбәттә, мәрхәмәтле, чын патриот булып үсәчәк.

# БАЛАЛАРНЫ МИЛЛИ РУХТА ТӘРБИЯЛӘҮ

***Гыймадиева Дания Маликовна***
*Зеленодол районы Норлат урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы*

Туган телне өйрәнү – һәр кешенең рухи үсешен, аның гомумкешелеген һәм милли кыйммәтләрен үзләштерүен тәэмин итү чарасы итеп каралырга тиеш. Шуннан башка үткән, хәзерге һәм киләчәк буыннар, аларның традицияләре, гореф-гадәтләре, фәлсәфәсе, идеаллары арасында дәвамлылык өзелер иде.

“Татарстан халыкларының телләр турында” Татарстан Республикасы Законын кабул иткәннән соң үткән юлга, ирешелгән нәтиҗәләргә йомгак ясау, алдагы бурычларны күзаллау, барлау чоры башланды. Законда каралганча, аны рус теле белән бертигез күләмдә өйрәтү, укытуны камилләштерү, үзебезнең милли кадрларыбызны әзерләү иде. Бу юнәлеш безнең мәктәптә үтәлә дигән фикер әйтә алабыз. Мәктәп укучылар өчен белем бирү урыны гына түгел, ә аның җанын дәвалаучы, рухын тәрбияләүче урын булырга тиеш.

Татарстан Республикасы милли мәгарифенең “Телләр турында” законының концептуаль нигезләре проекты безнең алга мәгънәле карашлы яңа буын кешеләр тәрбияләү мәсьәләсе куя. Шушы законга нигезләнеп, безнең мәктәбебез белем бирү белән генә чикләнмичә, милли, әхлакый, мәдәни, тәрбия традицияләренә нигезләнеп, һәр баланы шәхес буларак ачу өчен шартлар тудырыга тырыша. Кешенең җаны, рухы һәрчак тәрбиягә мохтаҗ. Без балаларыбызның рухын ничек тәрбияли алабыз, анда саналган проблемаларны хәл итәбез дип уйлыйм.

Милли тәрбия бирүдә безгә әдәбият, музей, тарих һәм культура, бөек шәхесләребезнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү, милли-төбәк компонентлары ярдәмгә килә.

Безнең мәктәбебез укучылары Татарстаныбызда гына түгел, илебезнең төрле күренекле уку йортларында укырлык, иң нык гаилә корырлык, милләтебезгә тирән хезмәт итәрлек булып өлгерсен! Без бу алдыбызга әнә шундый зур бурыч-максатлар куеп, төшенкелеккә бирелмичә, күтәренке күңел белән эшлибез.

Шактый еллардан бирле укучыларыбыз район һәм республика күләмендә үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда

призлы урыннар алалар. Бәйгеләр, конференцияләрдә катнашу, проектлар эшчәнлеге балалар сәләтен үстерү алымнары күп төрле.

Мәктәбебезнең Туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге балаларны рухи яктан тәрбияләү буенча аерым зур эш алып тора. Авылдашларыбызның, борынгы әби-бабалар үткәнен өйрәнү, бала күңеленә сеңдерү,яшь буынны Норлат төбәгенең данлы шәхесләре белән горурланып яшәрлек итеп тәрбияләү өчен музей җитәкчебез Роза Илдус кызы Яһудина иҗади эшли, авторлык программалары төзи.

Укучыларда милли рух, тел-әдәбияты, тарихы турында күзаллау булдыру өчен һәр предмет үз программасына милли-төбәк компоненты кертү юлы белән ирешә. Халкыбызның тарихы, мәдәнияте, милли йолалары, бәйрәмнәре, күренекле шәхесләрен барлауны барлык фәннәргә дә кертеп җибәрергә була. Әмма укыту программасында халкыбызның бу чиксез бай мирасын бөтен тулылыгы белән яктырту мөмкинлеге юк. Шунлыктан һәр укытучы бу эшкә иҗади якын килергә тиеш.

Бу эшнең зарурлыгын истә тотып, безнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары календарь – тематик план төзегәндә милли-төбәк компонентларын файдалануны керттеләр. “Мин яшәгән авыл”, “Безнең авыл”, “Туган ягаыбыз табигате”, “Авылым уңганнары” һ.б. шундый темаларга иншалар язу, класстан тыш чаралар үткәрү укучыларның кызыксынуын көчәйтә, материалны үзләштерүгә зур йогынты ясый.

Класстан тыш уку дәресләрендә, тарихи романнар укыганда, язучыларыбызның әсәрләре буенча китап укучылар конференцияләрен үткәргәндә милли-төбәк компонентын нәтиҗәле итеп кулланабыз.

Рус телендә сөйләшүче балаларда татар теленә мәхәббәт тәрбияләүдә дәрестән тыш чараларның да әһәмияте бик зур. Мәктәпләрдә традициягә кереп киткән һәм үткәрелә торган чаралардан “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Сабантуй” һ.б., “Татар теле” декадаларында, атналыкларда укучылар күбрәк катнашуы аларның белемнәрен тагын да арттыра, тормышны күзаллауларын киңәйтә, рухи яктан баета.

# УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ СЫЙНЫФТАН ТЫШ ЧАРАЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

***Зарипова Фәния Рифкать кызы,***
*Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле лицееның*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*

21нче гасырның башлангыч этабы милләтара мөнәсәбәтләр – кешелек алдында торган проблемаларның иң әһәмиятлеләренең берсе икәнен раслап кына калмады,ә аның бөтен җир шарында глобаль үзгәрешләргә китереп җиткерергә мөмкин икәнлеген дә күрсәтте. Киләчәктә җәмгыятьтә кискен борылышлар килеп чыкмасын өчен бердәнбер юл – ул үсеп килүче яңа яшь буынга дөрес тәрбия һәм белем бирү. Халкыбызның бүгенгесе, киләчәге, дөньякүләм тоткан урыны, һичшиксез, аның аң –белем дәрәҗәсенә, рухи – әхлакый үсешенә турыдан – туры бәйле.Шуңа күрә яшь буында милли үзаң,рухи сәламәтлек кебек сыйфатлар тәрбияләү, бүген көнүзәк темаларның берсе булып тора.

2002 елдагы җанисәбен алу Россиядә татарларның 36 меңгә кимегәнлеген, ә инде 2010 елдагы халык санын алу 240 мең кешегә кимүен ачыклады. Шундый зур тизлек белән кимүне дәвам итсәк, берничә гасырдан милләт буларак яшәп кала алырбызмы икән? Бүгенге информацон технологияләр заманында еш кына яшьләрнең ана теленнән,милләтеннән читләшә башлавы, ата – аналарның балаларын бары тик рус мәктәбендә генә белем алдырырга омтылуы, милләтеннән, ата – бабаларыбыз рухи мирасыннан ваз кичүе – татарларның санына һәм гомуми үсешенә көчле тәэсир ясый.Моңа өстәп татарларның өчтән бер өлешенең генә Татарстанда яшәвен, калган милләттәшләребезнең төрле кыйтгаларга сибелгән булуын исәпкә алсак, милләтебезнең аянычлы, хәтта фаҗигале хәлен күз алдына да китерүе кыен.

“Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк” дип белми әйтмәгән безнең борынгы бабаларыбыз. Үз иленең, милләтенең тарихын, аның бөек шәхесләрен белгән; геройларын – батырларын таныган;үзенең бөтен гомерен, барлыгын халкының бәхете өчен фида иткән шәхесләрен белгән кеше – беркайчан да үзенең милләтен, телен онытмас, һәм иң мөһиме, үзенең татарлыгынннан оялмас, ә киресенчә, шундый көчле бер милләтнең вәкиле булуы белән горуланыр гына.

Бүгенгесе көндә туган телебезне саклау һәм үстерү турында даими сөйләп, язылып тора. Бу юнәлештә республикабызда күп эшләр баш-

карылуын да,телләрне,мәдәниятебезне саклауга зур игътибар бирелүен дә беләбез.Тик алга таба уңышларыбыз,үсешебез тагын да зуррак тизлек белән алга барсын өчен үсеп килүче яшь буынны тәрбияләүче мөгаллимнәр,тәрбиячеләр өстенә икеләтә зур җаваплылык йөкләнә. Бүгенгесе көндә авыл мәктәпләре – телне саклаучы чыганак булып тора дибез. Ләкин шуны да онытырга ярамый: бүгенге татар авыллары үзләре дә зур бер диңгез өстендәге ялгыз көймәне хәтерләтә. Ни өчен без бүгенге көндә авыл балалары әдәплерәк, тәртиплерәк дип саныйбыз,чөнки авыл баласы борынгы гореф – гадәтләребез, йола һәм ныклап кереп урнашкан традицияләребез нигезендә тәрбияләнә. Ә бу инде укучыларда милли үзаң тәрбияләүнең төп факторы булып тора. Тәрбия – һәрбер халыкта аның туган теле белән бергә барлыкка килә. Туган телдә сөйләшмичә, аралашмыйча телебезгә карата ихтирам да, мәхәббәт тә тәрбияләп булмый. Беренчедән, һәрбер татар мәктәпләрендә,лицейларында укыту – тәрбия эшен үз югарылыгына куярга – ана телендә генә алып барырга кирәк. Шуның өчен татар мәктәпләрендә эшләүче мөгаллимнәргә дә ике телне дә – татар һәм рус теленнәрен камил белүне максат итеп куярга кирәк. Икенчедән, балаларын татар мәктәпләрендә,татар сыйныфларында укырга курыккан ата – аналарны һәрвакыт соңгы статистик мәгълүматлар белән таныштырып торырга кирәк. Бүген беркем өчен дә сер түгел, татар сыйныфында укучы балалар да БДИ ларын начар бирмиләр, ә киресенчә, кайбер күрсәткечләр ягыннан хәтта, уздырып та җибәрәләр. Ләкин без зур баллар артыннан куып бөек мәгърифәтчебез Р.Фәхреддиннең сүзләрен дә онытмаска тиешбез: “Тәрбиясе булмаган җирдә, гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия – иң кирәкле бер эш булачактыр”. Балаларыбызның тәрбиялелеге тормышыбызның, яшәешебезнең төп күрсәткече булып торуын һәркем аңларга тиеш.”

Укучыларда милли үзаң тәрбияләүдә сыйныфтан тыш чараларның әһәмияте дә әйтеп бетергесез зур. Һәрбер чараны үткәргәндә милли традицияләребезне, гореф гадәтләребезне истә тотып үткәрергә кирәк. Мин тәрбия эшләре буенча директор урынбасары буларак тәрбия эшемне шушы принципларга туры китереп алып барырга тырышам. Укучыларга милли тәрбия бирүнең, сыйныфтан тыш чараларда миллилекне саклап калуның тулы бер системасын булдырдым.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ ЭШЧӘНЛЕГЕН ҮСТЕРҮГӘ ПРОБЛЕМАЛЫ ҺӘМ МОТИВАЦИОН ЯКЫН КИЛҮ (ФДБС ТАЛӘПЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП)

***Заһидулина Альбина Фәнис кызы***
*Казан шәһәре Совет районы*
*“Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 22 нче урта гомуми белем мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү. ФДБС шартларында укучыларның шәхси һәм иҗтимагый компетенцияләрен үстерү сөйләм культурасы, телгә мәхәббәт аша гына тәрбияләргә мөмкин.

ФДБС шартларында рус телле укучыларга татар теле укытуда сөйләм телен үстерү мөһим, чөнки тел һәм сөйләм балаларның психологик үсешенә нык йогынты ясый. Сөйләм телен үстерү, аралашу проблемасын хәл итү өстендә Ф.Ф. Харисов, Р.З. Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниәтуллина, Р.Л. Малафеева кебек галимнәребез эшлиләр. Хәзерге көндә Татарстанның барлык рус мәктәпләрендә дә рус телле балаларга татар теле дәресләре әнә шул юнәлештә укытыла, ФДБС буенча дәреслекләр (Хәйдәрова Р.З.) шуңа яраклаштырыла.

Урта мәктәптә әле беренче ел гына эшләвемә карамастан, укучыларның татар телендә коммуникатив мәсьәләләр чишкәндә, төрле аралашу ситуацияләрендә югалып калуларын, татар телендә сөйләшүгә ихтыяҗ тоймауларын аңладым. Әле Казан Төзелеш Көллиятендә студентлар белән практика үткәндә үк татар теле дәресләрендә укучыларның кызыксынучанлыгының түбән дәрәҗәдә булуына инанган идем. Нәтиҗәдә, мәктәптә дәрес оештыруның нигезенә проблемалы мотивлаштыру технологиясе салынды, чөнки укучыда телне өйрәнүгә теләк, аңа ихтыяҗ, кызыксыну булганда гына барлыкка килә. Шуңа күрә, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, минем методик темам болайрак яңгырый: “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә рус телле укучыларның коммуникатив эшчәнлеген үстерүгә проблемалы һәм мотивацион якын

килү”. Рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә сөйләм эшчәнлеге зур әһәмияткә ия. Текстларны дөрес кабул итү һәм эчтәлеген сөйләү, сорауларга тулы җавап бирү, үз фикерләреңне җиткерә белү һәм башка кабул итү алымнары сөйләм теленә бәйле рәвештә үсеш ала. ФДБС шартларында сөйләм телен үстерү өчен үз эшемдә мин түбәндәге методларны кулланам:

– Күнегүләр эзлеклелеге ярдәмендә сөйләм телен тикшерү;

– Төрле практик эшчәнлекләр вакытында, уен барышында, тормыш-көнкүреш шартларында укучыларны күзәтү;

– Сөйләмдә тулы, дөрес, бер-берсенә бәйләнгән җөмләләр куллануга алшартлар тудыру, кызыксыну хисен уяту;

Төрле уен формаларында яки укучыларны гадәти тормыш-көнкүреш шартларында хис иттереп, укучыларның сөйләмен күзәтәм. Фраза сөйләменә (кыска яки тулы җавап бирә белү, сорау бирү, үз фикереңне җиткерү һ.б.) һәм әңгәмә барышында югалып калмауга аеруча басым ясыйм. Укучыларны күзәтү аларның белемен билгеләүгә һәм алга таба үз эшемне планлаштыруга, һәм иң мөһиме, укучыларны төрле аралашу ситуацияләренә әзерләүгә үз өлешен кертә.

Укучыларның сөйләм күнекмәләрен ныгытып тикшерү өчен түбәндәге күнегүләрне кулланам:

1. аерым ситуатив рәсемнәр буенча төркемләп җөмләләр төзү;
2. берничә укучыга бер-берсенә бәйләнгән рәсемнәр буенча җөмләләр төзетү;
3. текстның эчтәлеген сөйләү. Бер төркем башлый, икенчесе дәвам итә.
4. рәсем буенча хикәя төзү;
5. үзең турында хикәя язу;
6. нәрсәне дә булса сурәтләп бирү;

Укучыларның сөйләм дәрәҗәсенә карап, иҗади эш биремнәре дә өстәлергә мөмкин.

7. хикәяне язып бетерү яки билгеле бер темага хикәя язу.

Әлеге эшләр укучыларның белемен тулырак бәяләргә ярдәм итә. Ә бәяләүләр нәтиҗәсендә алдагы эшем планлаштырыла һәм уңай нәтиҗәләргә ирешелә.

Укучылар өчен коммуникатив биремнәр катлаулы, күп очракта алар телдән эшләүдән куркып, каушап кала. Шунлыктан, әлеге биремнәрне без уен формасында, яки алшартлар билгеләп эшлибез.

Дәрес барышында, әлбәттә предметара бәйләнешне дә онытмаска кирәк. Дәрестә башка фәннәрдән дә файдалану мотивацион якын килү өлкәсенә зур өлешен кертә, дәрес материалын үзләштерү дәрәҗәсен

күтәрә. “Татарстан – минем республикам” темасын үткәндә без туган ягыбызның тарихы белән танышабыз, гимныбызны тыңлыйбыз, Татарстан картасын өйрәнәбез. Шәһәр исемнәрен өйрәнгәндә шулай ук география фәненә мөрәҗәгать итәбез. Саннарны өйрәнгәндә математикага “чумабыз”. Диалоглар, хикәяләр укыганда, рольле уеннар уйнаганда укучыларда актерлык сәләтләре ачыла. Һәр дәрестә физминуткалар татар музыкасы белән үрелә. Һәм әлбәттә инде грамматик кагыйдәләрне өйрәнү бары тик рус теле белән чагыштырма планда гына алып барыла. Чөнки һәрбер кеше теләсә нинди чит телне бары тик туган теле белән чагыштырып, үз теле аша чагылдырып кына өйрәнә ала.

Татар телен предметара бәйләнешләр аша һәм, әлбәттә проблемалы-мотивацион укыту түбәндәге нәтиҗәләрне күрсәтте: укучыларның сөйләме яхшырды, алар үз фикерләрен булдыра алганча әйтеп бирә башладылар, диалоглар, монологлар төзергә өйрәнделәр, татар теленә, әдәбиятка, мәдәниятка кагылышлы мөстәкыйль фикерләр барлыкка килде, һәм, шунысы мөһим: каушау, курку арткы планга чигенде.

Әлеге нәтиҗәләр минем киләчәк эшчәнлегемдә дөрес юлны, юнәлешне күрсәтә, алдагы эшемне планлаштыра. Хәзер укучылар авыр, ләкин мавыктыргыч ТАТАР ТЕЛЕН зур кызыксыну белән өйрәнә.

## КАТНАШ МӘКТӘПТӘ ИКЕТЕЛЛЕЛЕККӘ ӨЙРӘТҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

***Зыятдинова Гөлнур Рәис кызы***
*Татарстан Республикасы*
*Зеленодол муниципаль районы*
*“Әйшә гомуми урта белем бирү мәктәбе”*
*муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүгенге көндә Татарстан җәмгыятьчелеге алдында иң әһәмиятле проблемаларның берсе – балаларга күптармаклы мәдәни һәм поликультуралы белем бирүне үстерү тора. Татарстан җирлегенең оешу үзенчәлекләре нинди булуга карамастан, ул төрле этнослар кушылумы, яисә тарихи күчеш процессы нәтиҗәсеме – белем бирү өлкәсендәге алгарыш гомумдәүләт мәнфәгатьләрен һәм биредә яшәүче халыкларның милли-мәдәни аермалыкларын исәпкә алып үткәрелергә тиеш.

Мәгариф системасында социаль-икътисадый үзгәрешләр чорында этно-мәдәни мәсьәләләргә кагылышлы бай тәҗрибә тупланса да, ике теллелеккә нык йогынты ясалса да, ул милли-мәдәни мәгариф проблемаларын иңләп бетерә алмый. Поликультуралы белем бирү аша халыкларның бер-берсе белән мөнәсәбәтен көчәйтү һәм культурасын үзара баету, үз халкының тарихы һәм башка халыкларның яшәү рәвешен өйрәнү аша укучыда универсаль культура тәрбияләү – заманча белем бирүнең мөһим өлеше булып тора.

Россия президенты В.В.Путин да 2012 нче елның 12 нче декабрендә Федераль собраниега булган юлламасында да бу мәсьәләнең мөһимлегенә басым ясады. "Без Рәсәй Федерациясендә яшәүче һәрбер милләткә зур хөрмәт белән карыйбыз, карарга тиешбез һәм карыячакбыз да. Безнең матурлыгыбыз һәм көчебез – күпмилләтлегебездә" – дип билгели президент. Бу проблема безнең мәктәп өчен дә бик актуаль, чөнки бездә бүгенгесе көндә 12 милләт баласы белем ала. Бер генә милләт тә үз мәдәнияте кысаларында гына бикләнеп кала алмый. Шуңа күрә бүгенге көндә поликультуралы җәмгыятьтә яши алучы укучылар тәрбияләү милли мәгариф системасының яңа стандартларында да мөһим урында тора. Мәктәпләрдә белем алучы укучылар татар һәм рус мәдәнияте белән генә чикләнмичә, әйләнә-тирәбездә яшәүче башка милләтләрнең мәдәнияте белән дә таныш булырга тиеш. Шулай булганда гына без илебездә, Габдулла Тукай әйткәнчә, "тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып" яши алырбыз.

Балаларны балачактан күп милләтле мөхиттә яшәргә, яшәеш өчен кирәкле белем алырга өйрәтсәк, киләчәктә аның камил шәхес булуы ышанычлы. Шуңа күрә уку процесында укучыларны төрле милләтләрнең культураларына якынайту, аралаша белү һәм төрле милләтле дәүләттә яшәргә өйрәтү максаты куела. Бүгенге шартларда ике телне генә өйрәнү түгел, инглиз телен, француз телен камил өйрәнү таләп ителә.

Мәгълүматның күләме тиз үскән вакытта, кирәген сайлап ала белергә, тәртипкә китерергә, кечкенә генә ачыш ясап куана белергә өйрәтү, юл күрсәтү уку-укыту өчен авыр эш. Укучы теманы уйлап, фикерләп, эзләнеп аңлый икән, әлбәттә, аның белеме ныклырак, төплерәк була.

Мәктәпләрдә башка милләт укучыларының татар телен өйрәтү сәләтен үстерү мәсьәләсе зур әһәмияткә ия. Ә моның өчен тиешле шартлар булдыру – укытучының мөһим бурычы. Укучыларньң татар телен тирәнтен үзләштерүе өчен безгә, укытучыларга, рус балаларында да телгә кызыксыну уятырга, сөйләм телен шомартыр өчен, дәресләрне кызыклы итеп үткәрергә, төрле алымнар кулланып эшләргә, класстантыш эшләрне дә нәтиҗәле оештырырга кирәк. Безнең бурыч – балаларның

утелгән темаларны, өйрәнелгән материалны үзләштереп баруларына ирешү; татар теленә генә хас булган авазларны дөрес кулланып, җөмләләр төзәргә өйрәтү; сорау җөмләләрне аңлап, дөрес җавап бирүләренә ирешү; җөмләдә исем, фигыль, алмашлык һ.б. сүз төркемнәрен, сан, зат, килеш кушымчаларын дөрес кулланырга өйрәтү. Кыскасы, балаларны бу телдә укырга, сөйләшергә, язарга өйрәтү. Ә моның өчен дәресләрдә сөйләгәнне тыңлап аңлау; диалог-монологлар төзү; ситуатив, коммуникатив биремнәр үтәү; текстларны укып, эчтәлеген аңлап сөйләү, тәрҗемә итү; дөрес язу күнекмәләре булдыру; текстлар күчереп язу; диктант язу; хаталарны төзәтү; биремнәр эшләү; язма эшләр, практикум-дәресләр, тестлар уздыру; карточкалар, таблица-схемалар ясау; төзәтүләр; зачет, консультацияләр оештыру өстендә эшләргә тиешбез...

Мәктәп еллары – кешенең шәхес буларак формалашуында мөһим чор. Шуңа да төрле социаль-инфраструктура объектлары белән элемтәдә торырга мөһим. Балалар иҗаты, аң-белем тарату үзәкләре, спорт оешмалары, танылган шәхесләр белән “Ялкын” журналы хезмәткәрләре белән очрашу ярдәмендә укучыларның төрле сәләтләрен ачарга һәм үстерергә тырышабыз. Язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең музейларында еш булабыз, бик күңелле дәресләр уздырабыз, балаларга мондый традицион булмаган дәресләр бик ошый.

Ике теллелек, поликультуралылык бүгенге көн тормыш таләбе буларак, төрле милләтвәкилләрен кеше буларак кабул итү, ярату һәм саклау дигән сүз.Бу чаралар милләтара дуслыкны ныгытуга, укучыларда берберсенә һәм олыларга карата хөрмәт хисе тәрбияләргә булыша.

Дөнья үзгәрә, дөнья белән бергә без дә үзгәрәбез. Яңалык белән без дә яңарабыз. Димәк, киләчәгебез безнең үз кулларыбызда. “кеше рухи көчне җиргә карап түгел, зәңгәр күккә карап ала. Хыялга, идеалга, максатка омтылыш – шәхеслек билгесе”, – ди күренекле язучы Галимҗан Гыйльманов. Безнең укучыларыбыз да киләчәктә шундый шәхес булуына ышанып калабыз.

# ТАТАР БАЛАСЫН ТАТАР ИТЕП НИЧЕК ТӘРБИЯЛӘРГӘ?

***Кашапова Гөлсинә Назыйф кызы,***
*Бөгелмә муниципаль районы*
*МБГББУ "Мостафа Өнҗәл исемендәге*
*лицей-интернат" татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Нәрсә соң ул милли үзаң? Бу сорауга шәхсән үзем шулай дип җавап бирер идем: "Үзеңне билгеле бер милләт кешесе дип тану, шул милләтнең телен, гореф-гадәтләрен саклап, киләчәк буынга тапшыру". Бары тик үзе турында "Мин – татар, туган телемдә сөйләшәм, балаларым да татар телендә аралаша," – дип әйтә алган кеше хакында гына милли үзаңның югары дәрәҗәдә булуын күрә алабыз.

Үсеп килүче буында милли үзаңны ничек тәрбияләргә соң? Тәҗрибә шуны күрсәтә: балалар бакчаларында, мәктәпләрдә туган телне укыту милли үзаңны тәрбияләүдә төп фактор булып тормый. Мин, әлбәттә, туган телне укытуга һич каршы түгел. Гаиләнең күп кенә вазыйфалары мәктәп җилкәсенә тапшырылган заманда укытучылар гына бу максаны тормышка ашыра алмый, кызганычка каршы.

Милли үзаңны тәрбияләүдә төп кеше – ана кеше, әлбәттә! Укытучы түгел, ә менә әни кеше. Татар халкы юкка гына әйтмәгән бит: "Ананың алага биргән иң зур бүләге – тел!". Үзем әни кеше буларак тәҗрибәм белән уртаклашасым килә.

Беренчедән, бала үзен таный башлау белән, сабыйга милләте буенча үзенең кемлеген ныклап төшендерә башларга кирәк. Мин кызыма кечкенәдән: "Син – татар, без – татарлар", – дип кабатлап киләм. Бу сүзләр балага үзенең кемлеген аңына сеңдерергә ярдәм итсә, дөньядагы кешеләрнең төрлелеген аңларга булыша. Мондый сүзләр һич кенә дә башка милләт кешесенә каршы кую булырга тиеш түгел!

Икенчедән, өйдә татарча сөйләшү булырга тиеш. Без татарларның өйдә русча сөйләшүебез берәүгә дә сер түгел. Хәтта татар теле укытучыларының күпчелеге балалары белән русча сөйләшә бит! Газиз балаң телеңне белмәгәндә, укытучының мәктәп баласына татар телен өйрәтүеннән бер файда да юк! Туган телендә теле ачылмаган балада милли үзаң булуга ышануы авыр, чөнки татар баласы татар булып туган телендә сөйләшеп формалаша. Рус мохитендә яшәгәндә, өйдә татар телендә аралашу бик мөһим. Татар кешесе тәрбияләүне төп максат итеп куйган гаилә өйдә туган телдә аралашуны төп закон итеп куярга тиеш. Бөгелмә ягы – рус телле як,

шуңа да безнең өйдә рус телендә сөйләшү катгый тыела, чөнки бала болай да мәктәптә, урамда рус телендә аралаша.

Милләтебез тагын шуны да аңласа иде: өйдә туган телне үзләштермәгән бала мәктәптәге татар теле дәресләрендә генә телне тулысынча үзләштерә алмый! Без туган телебезне башка төрле итеп ана теле дип тә атыйбыз. Ни өчен дигәндә, нәкъ менә ана – туган тел укытучысы бит!

Балага туган телне өйрәтүдә тагын бер кызыклы факт бар. Белгәнебезчә, Россия – күпмилләтле дәүләт. Татарстан җирлегендә генә никадәр милләт яши. Игътибарлы кеше шуны күрер: сан ягыннан чагыштырмача аз булган чегәннәр, үзбәкләр һ.б. милләт балалары туган телләрен яхшы белә. Ә бит чегән баласына мәктәптә туган теле дә, туган әдәбияты да укытылмый! Шуңа карамастан алар ана телендә иркен аралаша, үзләренең кем булуын әйтергә оялмый. Ә без татарларның ана теле дәресләре булып та, күпме татар туган телен белми, милли үзаңы түбән! Чит милләтләр безгә үрнәк булып торырга лаеклы, чөнки гаиләдә тәрбия туган телдә, халыкның гасырлар буена килгән гадәтләренә нигезләнеп башкарыла.

Милли үзаң тәрбияләүдә әби-бабайларның роле зур булса да, заманалар узу белән, өлкән буын вәкилләре дә үзгәрде. Бүгенге әбиләр, бигрәк тә шәһәр әбиләре, оныклары белән татарча сөйләшәсе урынга, үзләре белмәгән русчаны вата-җимерә, рус телендә сөйләшә. Көләрлек тә, еларлык та. Безнең милләт дөреслекне кабул итәргә яратмаса да, бу, чынлап та, шулай бит.

Баланы татар итеп тәрбияләүдә шулай ук ата-ананың шәхси үрнәге дә зур әһәмияткә ия. Ата-ана һич кенә дә баласына: "Сиңа татар теле ник кирәк ул? Башка фәннәрне үзләштер, алар сиңа күбрәк кирәк, " – дип һич кенә дә әйтергә тиеш түгел. Шулай дип баласына әйткән ата-ана милләтнең тамырына балта белән чаба. Әлбәттә, туган телне белүнең тормышта гамәли әһәмияте аздыр, ләкин телне белү безне милләт итеп саклаучы төп фактор. Телне белмәгән татар ул татар түгел!

Димәк, татар баласын татар итеп тәрбияләү бер дә катлаулы түгел, чөнки ул зур чыгымнар, матди нигез таләп итми. Бар нәрсә дә бары тик үзебездән генә тора. Үсеп килүче буынның туган телне белмәвендә, милли үзаңның түбән яки бөтенләй булмавында тышкы факторлар, башка милләт вәкилләре һич кенә дә гаепле түгел. Бүген безгә берәү дә татарча сөйләшмәгез, гореф-гадәтләрегезне сакламагыз дип әйтми ич!

Шулай итеп, милли үзаң тәрбияләүнең нигезе булып гаилә, ата-ана тора. "Оясында ни булса, очканында шул булыр", – дигәннәр борынгылар. Бу нигез төпле булганда гына, без укытучылар балага салынган милли үзаңны үстерә алабыз.

# УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Кашапова Кәүсәрия Дамил кызы***
*Менделеев районы Абалач*
*урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*1нче категорияле татар теле*
*һәм әдәбияты укытучысы*

***Җырлап торам; торган җирем тар булса да,***
***Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;***
***Г.ТУКАЙ.***

Туган тел! Татар теле! Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле сүзләрне без туган телдә әйтәбез.Туган – үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә. Туган телен кадерләгән халык кадерле була. Әйе, безнең телебез – бик борынгы һәм бай телләрнең берсе. Тел кешенең тормышында зур урын тота. Ул тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Ул кешеләргә бер– берсе белән аралашырга, аңлашырга, бер – берсенең теләк – максатларын, уй – фикерләрен белергә ярдәм итә.” Халыкның теле – аның бөтен рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган чәчәге. Телдә бөтен халык һәм аның ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә,”– дигән бөек рус педагогы К. Ушинский. Татар халкының рухи җәүһәрләрен югалтмыйча җыючы, саклаучы безнең көнгә кадәр китереп җиткерүче галимнәребез дә бар. Алар күп түгел. Һәр галимнең тел турында язган мирасы үзенчәлекле. Бу эшне башлап җибәрүче, аны бер системага салучы тел галимнәребез дә күп. Алар үз ана телен камил белгән, киләчәге өчен зур көч куйган галимнәр.Бу милләт өчен аларның карашлары битараф түгел дигән сүз.

Мәгариф, мәдәният, мәгълүмат системасы, икътисад, спорт – болар барысы да милли үсеш өчен кирәкле нәрсәләр. Ләкин иң актуаль, кискен проблема – милли үзаң. Кешеләр һәрвакыт күмәкләшеп яшәгәннәр. Алар, үзара бәйләнешләрне ныгыту өчен, яшәү кагыйдәләрен булдырганнар. Җир йөзендәге һәр халыкның үзенә генә хас яшәү кануннары барлыкка килгән, милли тәрбиягә нигез салынган. Милли үзенчәлекләр тарихи һәм хрономик ландшафт факторларына бәйле рәвештә формалашкан, дип саный галим Л.Н.Гумилев. Дин барлыкка килгәннән соң, кешеләр дин кануннарына да буйсынган. Дәүләтләр барлыккка килгәч, дәүләтнең рәсми рәвештә кабул ителгән кануннары нигезендә яшәү тәртибе кергән. Һәр дәүләтнең, халыкның, шул исәптән, татар халкының

да, язылган яки язылмаган, рәсми рәвештә кабул ителгән яки ителмәгән яшәү кагыйдәләре булган, алар, еллар узу белән камилләшеп, буыннан буынга тапшырылган, тиңе булмаган кыйммәт мираска – милли тәрбия кануннарына әверелгән. Кешенең табигать биргән мөмкинлекләрен үстерү, теге яки бу җәмгыять үзенчәлекләренә туры килгән шәхес формалаштыру, кешегә үз максатларына ирешүгә ярдәм итү системасы – тәрбия бирү барлыкка килгән. Тәрбия бирү рәсми рәвештә кабул ителгән концепция һәм программа нигезендә алып барыла. Милли тәрбия бирүнең эчтәлеге, нигездә, өч өлештән тора, дип әйтергә була. Беренчесе – укучыларга гомумкешелек кыйммәтләренең асылын аңлату һәм аларның бу кыйммәтләрне тануына ирешү. Икенчесе – укучыларда гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру. Өченчесе – балаларның татар милләтенең төп сыйфатларына ия булуларына ирешү. Күп төрле чыганакларда күрсәтелгәнчә, нигездә, гомумкешелек кыйммәтләре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1. Тормыш һәм сәламәтлек кыйммәте.
2. Гаилә кыйммәте.
3. Милли кыйммәтләр.
4. Белем һәм бәйсезлек кыйммәте.
5. Талант һәм сәләт кыйммәте.
6. Халыкара һәм милләтара бәйләнешләр кыйммәте.

Җир йөзендәге барлык халыклар өчен уртак гомумкешелек сыйфатлары кабул ителгән: намуслылык, вөҗданлык, кешелеклелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлылык, хезмәт ярату, милләтара дуслык, милләтпәрвәрлек. Югарыда санап кителгән тәрбия бирү юнәлешләрен уңай педагогик шартларда гына тормышка ашырыра мөмкин. Шул ук вакытта милли тәрбия бирүнең эчтәлеген билгеләгәндә, татар халкында очрый торган көнчелек, коллык психологиясе, урынсызга кешегә ярарга тырышу, җитәкчеләрдәге тәккәберлек, таркаулык, үз-үзеңә артык ышаныч кебек сыйфатларның барлыкка килүен кисәтү кирәклеген дә истән чыгарырга ярамый.

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ ПРИ ПРЕПОДАВАНИИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

***Кашапова Рамиля Равилевна***
*МБОУ «Школа №71» г.Казани*
*Заместитель директора по вопросам национального образования*

В целях получения оптимальных результатов обучения, внедрение эффективных педагогических технологий и методик, является на сегодняшний день актуальной. Повышение качества образования, формирование конкурентоспособной личности зависит в первую очередь от профессионализма педагога. Для этого мы, учителя, должны быть компетентными, мобильными и идти в ногу со временем. На сегодняшний день информационные технологии прочно вошли в нашу жизнь. Изменилась направленность образования. Использование ИКТ в образовании обогащает среду образовательной деятельности, расширяет круг доступных для решения задач. Современные информационные технологии помогают сделать процесс обучения интересным, эффективным, познавательным и творческим, повышают мотивацию учащихся и открывают большие возможности расширения образовательных рамок по каждому предмету, и татарский язык не является исключением. Поэтому одно из условий творческой деятельности учителя – это использование информационно-коммуникационных технологий. Как учитель татарского языка и литературы, на своих уроках стараюсь пробудить интерес к изучаемому предмету, раскрыть перед учениками красоту родного языка, используя различные активные формы и методы и новые компьютерные технологии.

На первый план при обучении татарскому языку как неродному выдвигается коммуникативное обучение через диалоговые тексты. Но одной диалоговой речи недостаточно, поэтому я использую презентации на своих уроках, чтобы заинтересовать учеников материалом, который я хочу преподнести им. Таким образом, в легкой, непринужденной форме диалога, сопровождаемые показом слайдов, приобретаются навыки разговорной речи и легче заучиваются, запоминаются новые слова.

Также я использую различные ребусы, кроссворды, игры, благодаря которым урок получается оживленным, более интересным. Игры имеют особое значение для изучения нового языкового материала, закрепления

и активизации пройденного лексического и грамматического материала. Наукой доказано, что игра развивает у детей мышление, речь и память. Я считаю, игра является эффективной и доступной формой деятельности при обучении русскоязычных учащихся татарской речи.

На уроках родного языка с помощью презентаций, можно выполнять все традиционные виды упражнений на зрительное восприятие, постановку знаков препинания, вставку букв, редактирование текста. Использование компьютера в обучении родному языку позволяет развивать у учащихся навыки чтения, письма, а также значительно расширить словарный запас.

Компьютер можно использовать как при объяснении нового материала, так и при закреплении полученных знаний. В ходе изучения нового материала можно создать обобщающие таблицы, схемы, по всем разделам науки о языке: фонетика, морфология, синтаксис и другие, а на этапе закрепления изученного или на этапе повторения пройденного использовать данные таблицы, схемы для решения учебно-познавательных задач, углубления изученного материала. Например, при работе с тестами, для отображения правильных вариантов использую эффекты анимации.

Использование компьютерных технологий на уроках показало, что возрастает заинтересованность учеников материалом, который я хочу преподнести им. В легкой, непринужденной форме диалога, сопровождаемые показом слайдов, приобретаются навыки разговорной речи и легче заучиваются, запоминаются новые слова, а главное – возрастает интерес учащихся к самостоятельному созданию таких презентаций.

Используя Интернет– технологии, учащиеся подготавливают к урокам сообщения, рефераты по творчеству татарских писателей. Таким образом, мы ещё раз убеждаемся: успешное обучение возможно только в том случае, если учителю удается пробудить интерес к изучаемому предмету и систематически поддерживать его.

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ШАРТЛАРЫНДА УКУЧЫЛАРДА ТОЛЕРАНТЛЫК ХИСЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ

***Комиссарова Фәнҗия Гавис кызы***
*Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Җәмгыятебезнең киләчәге бүген мәктәптә укучы егет һәм кызларның гражданлык сыйфатларына, чын патриотлар булып үсүенә бәйле. Сер түгел, демократик дәүләт төзибез дип, мәктәп тормышында яшәп килгән тәрбия системасын үзгәртеп кору гел уңай нәтиҗә генә бирмәде,мәктәп балаларына үрнәк итеп куярлык көчле шәхесләрнең исемнәре күбесе онытылды,күбесе юкка чыкты, тәрбия өлкәсендә ниндидер бушлык барлыкка килде.Бик тә аяныч хәл – балаларыбызның туң йөрәкле, үз мәнфәгатен бөтен нәрсәдән дә өстен куючы затлар булып үсү куркынычы килеп басты. Галимнәр әйтүе буенча кешедә ике төрле авыру булырга мөмкин. Берсе матди (физик), икенчесе – мәгънәви (рухи) авыру.Физик авыруны күз яки прибор белән күреп була. Ә менә икенче авыруыбыз – сөйләгән сүзләрдә, ясалган хәрәкәтләрдә күренә һәм бу авыруны төзәтү өчен көннәр, айлар,еллар таләп ителә. Яшьләрнең чирләшкә, йомшак характерлы була баруның да төп сәбәбе – аларның рухи зәгыйфълегендә. Хәзерге балаларга совет чоры әсәрләрен, бигрәк тә патриотик рухта язылганнарын аңлау кыенлашты. Ватаныбыз, халкыбыз бәхете өчен көрәшкән каһарманнар һаман онытыла бара, Ватан, патриотизм төшенчәләрен балаларга аңлату авырлаша. Ләкин, җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән яманны, ак белән караны, биеклек белән түбәнлекне аерырга, үз иленең гражданины, патриоты булып үсәргә тиеш.

Халкының үткәнен, тарихын, сәнгатен өйрәнгән, хезмәт сөйгән, матурлыкны күрә белгән, башка халыклар белән үзара дус һәм тату мөнәсәбәттә тәрбияләнгән һәр баланың киләчәге өметле, – дип әйтеп калдырган үз вакытында күренекле фикер иясе, мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин. Әдәплелек, тыйнаклык, намуслылык, кешелеклелек кебек асыл сыйфатларны үзеңдә булдыруда һичшиксез Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләре бүгенге көндә дә бик актуаль.

Безне алга чыгарачак яңа буын бүген мәктәптә формалаша.“Хәзерге дөньяда шәхесне формалаштыручы төп фактор буларак, белем һәм тәрбия бирүнең әһәмияте арта бара. Бүгенге балаларда әхлакый нигезләр, тирә – яктагыларга карата ихтирам һәм толерант мөнәсәбәт, патриотлык,

гражданлык хисе һәи узара тату яшәү культурасы тәрбияләү мөһим"– дип белдерде үзенең бер чыгышында Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев.

Икенче буын федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру шартларында мәктәп алдына куелган иң мөһим бурычларның берсе булып нәкъ менә толерантлы, бер-берсен хөрмәт итүче, рухи яктан камил, гомумкешелек кыйммәтләренә уңай карашлы шәхес тәрбияләү бурычы тора.

Соңгы вакытта без яшәештә, тәрбия өлкәсендә, аралашуда еш кына толерант дигән төшенчәне ишетәбез. Нәрсә соң ул толерантлык? Толерантлык сүзе латин теленнән түземлелек, чыдамлылык, сабырлык дип тәрҗемә ителә. Психологиядә исә бу төшенчәнең күп төрле аспектлары билгеле. Толерантлык ул – хезмәттәшлек итү, партнерлык рухы; чит фикерләргә колак салу; үзеңне башка шәхесләр белән бер яссылыкта күзаллау; башкаларга зыян салудан баш тарту. Ул тирә–юньдәгеләрнең үз-үзләрен тотышларына, мәдәниятләренә, диннәренә түземле булу дигән сүз. Бер– береңә карата түзеп тору мөһим, әмма бу җиңел түгел. Бер генә мисал: Заманында дин эшлеклесе, педагог **Бубый** (Нигъмәтуллина) Мөхлисә тыйнаклыгы, итагатьлеге, фикер-карашларының ачыклыгы белән замандашларын таң калдырган. Ул – Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсе белән җитәкчелек иткән. Мөхлисә Бубый үзенең гомерен динне саклауга, хатын-кызларны балаларын милләт балалары итеп тәрбияләргә сәләтле аналар итеп тәрбияләүгә багышлаган, алар турында кайгырткан, аларның хокуклары өчен көрәшкән, хатын-кызның илаһи көчкә сәләтле бөек зат икәнен, аның иҗтимагый тормышта үз урыны булырга тиешлеген раслаган. Үзенең кешелек сыйфатлары белән дә халкыбызның иң олы абруен яулаган, рухи камиллеккә ирешкән. Толерантлыкның матур бер үрнәге түгелме соң бу?

Без күпмилләтле республикада яшибез. Гомуми белем мәктәпләрендә төрле милләт балалары укый. Шундый шартларда укучыларда толерантлык хисләрен ничек тәрбияләргә соң?

Алабуга җирлеге мисалында укучыларда толерантлык хисләре тәрбияләү авыр түгел.Үзебезнең татар милли горурлыгыбыз янәшәсендә христиан диненә караган культура истәлекләрен өйрәнү,башка милләттән булган бөек шәхесләр турында әңгәмәләр үткәрү балаларның әйләнә-тирәне танып-белүен арттыра, башкаларга хөрмәт белән карарга өйрәтә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә төрле халыкларның традицияләре һәм гореф-гадәтләре белән танышабыз.

Дәрестән тыш вакытта укучылар белән бергәләп төрле милли бәйрәмнәр оештырабыз, чыгышлар ясыйбыз."Нәүрүз","Сөмбелә","Саб

антуй”,“Масленица” кебек кичәләр укучыларны милли культурага якынайтып кына калмыйлар, аларны бергәләшеп, төркемнәрдә эшләргә; башкаларның фикеренә колак салырга һәм алар белән килешергә өйрәтә. Бу сыйфатлар әлбәттә толерантлыкның нигезен тәшкил итә.

Толерантлыкның тагы бер тармагы – хезмәттәшлек итү, партнерлык рухы тәрбияләү турында аеруча әйтеп китәсем килә. Менә берничә ел инде Германиянең Вайльхаим шәһәре белән Алабуга шәһәре гимназиясе укучылары арасында халыкара мәктәп хезмәттәшлеге яшәп килә. Хәзерге вакытта ике як та 3 нче турны оештыру өстендә эш алып бара. 20-30 май -Алабуга-Вальхайм, 20-30 сентябрь – Вальхайм-Алабуга маршруты планлаштырыла.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, киләчәктә дәүләтләр һәм җир йөзендә яшәүче кешеләр язмышына йогынты ясый ала торган искиткеч зур көч – яшь буынны халыкара һәм милләтара татулык шартларында яшәргә әзерләү өстендә эшләү – безнең төп бурычыбыз.

# УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН МИРАСЫ

***Курмаева Рушания Рафиковна***
*Балык Бистәсе районы*
*Котлы Бүкәш урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Балык Бистәсе ягын күз алдына китердем: ни чыкса шул яктан чыга бит соңгы утыз елда. Ул сиңа Равил Шәрәфиевме диген, Әхәт Гаффармы, Кадыйр Сибгатуллин, Равил Фәйзуллин, Хәлим Җәләлов, элегрәк– Сәет Шәкүров, хәзерге Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Фәйзуллин. .. Бар нидер бар, ниндидер хикмәт бар бу төбәктә. Уйлыйм, Болгар дәүләте руслар һәм монголлар тарафыннан кат-кат җимерелгәндә, бу төбәктә әллә Бөек Болгарстанның аксөякләре, һөнәр, сәнгать осталары күчеп утырмадымы икән? Бу малайларның канында әллә борынгы болгар бабаларыбызның геннары уйныймы икән?”– дип язып, Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев районыбыздан чыккан әдәбият һәм сәнгать әһелләренә үзенең бәяләмәсен биргән иде.

Без, Котлы Бүкәш урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, районыбызның шифалы туфрагыннан үсеп

чыккан олуг шәхесләребез белән чын күңелдән горурланып, аларның иҗатларын яшь буынга, укучыларга җиткерү өстендә максатчан эш алып барабыз. Укытучының иң төп өстенлеге фәнен белү генә түгел, ә үз фәне белән тәрбияли алуында, дип яза К.Д.Ушинский. Әлеге сүзләрбезнең юлдашыбызга әйләнде. Әдәбият укытучысының бурычы әдәби әсәрләрне бала күңеленә сеңдерү, аларның мәгънәсенә, нәфислегенә төшендерү, укучыларда күркәм сыйфатлар тәрбияләргә булышу, әсәрләрен күбрәк укырга теләк уятудан гыйбарәт.

Без укучыларны әдәбият белән кызыксындыруда, аларда китап һәм көндәлек матбугат белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыруда, әхлак һәм эстетик зәвык формалаштыруда әдәби туган як материалларын өйрәнүнең әһәмияте зур дип исәплибез. Шуңа күрә бу эшкә бик җитди игътибар итәбез. Татар теле һәм әдәбияты кабинетында “Якташлар иҗаты” почмагы булдырылды. Анда якташларыбыз турында истәлекләр, фотолар, автографлы китаплар, аларга багышлап төзелгән альбомнар тупланган һәм аларны тулыландыру өлкәсендә даими эш алып барыла.

*Ике гомер безгә насыйп булмас*
*Бер яшибез җирдә*
*Бер туып.*
*Шушы җирдә бик каласы килә*
*Бер югалмый торган җыр булып.*

Әлеге шигъри юлларны язган, бүгенге көндә исеме югалмый торган җыр булып яңгыраган шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин районыбызның Балыклы Чүкәй авылында туып үскән, озак еллар журналист булып каләмен чарлаган, милли поэзиябезне берсеннән – берсе гүзәл әсәрләр белән баеткан. Ул 1974 нче елда “Әманәт” исемле җыентыгы белән шигърият мәйданына килеп керә. Хәсән Туфан аның газетадагы шигырьләрен укып: “Менә бу шагыйрь, тумыштан шагыйрь”, – дип соклана. Аның шигырьләре укучының күңеленә барып җитә, йөрәгенә үтеп керә.

15нче февральда якташыбыз шагыйрь К. Сибгатуллинга 72 яшь тулыр иде. Әмма, кызганычка каршы, язмыш аны әдәбият, шигырь сөючеләрдән иртә аерды. Кадыйр Сибгатуллин 30 ел татар поэзиясе мәйданының уртасында торган зур шагыйрь. Аның шигырьләрен онытуга юл кую – зур гөнаһ булыр иде. Шуңа күрә исемен мәңгеләштерү юнәлешендә максатчан, эзлекле эш алып бару безнең, исәннәрнең, – зур бурычы.

К. Сибгатуллинның юбилее уңаеннан район газетасы битләрендә аерым рубрика эшләп килде. Шагыйрьне белгән, аның белән эшләгән

авылдашлары, якыннарының истәлекләрен туплап, өйрәнеп бардык, бу истәлекләр буенча сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Шагыйрьнең юбилейлары мәктәбездә зурлап билгеләп үтелә. Аның шигырьләрен сәнгатьле итеп уку – аеруча игътибарга лаек. Укучылар Кадыйр Сибгатуллинның “Әни”, “Рәхмәт әби”, “Юлда үскән арыш”, “Дога” һәм башка шигырьләрен яратып яттан сөйләделәр, хис – кичерешләрен үз йөрәкләре аша уздырып, тыңлаучыларга, укучыларга җиткерә алдылар.

Төбәк әдипләренә багышлап үткәрелгән кичәләр бездә бер тематика астында “Шушы яктан, шушы туфрактан без” исеме белән үтә. Кадыйр Сибгатуллинга багышланган “Шушы җирдә бик каласы килә бер югалмый торган җыр булып” дип аталган әдәби – музыкаль кичә үткәрдек. Кичәдә шагыйрьнең туган якка, игенче хезмәтенә, сугышның фаҗигаләрен яктыртуга һәм бөтен кыенлыкларны да җиңәргә сәләтле чын һәм саф мәхәббәткә багышланган шигырьләре яңгырады, тормыш һәм иҗат юлы яктыртылды.

Әдәбият белән кызыксынучы балалар өчен “Әллүки” түгәрәге эшләп килә. Монда укучылар шигырь язу серләренә төшенәләр, газеталар чыгаралар. Февраль аенда туган көне уңаеннан Кадыйр Сибгатуллинга багышлап чыгарылган газеталарда аның турында истәлекләр, шигырьләр урын ала. Якташыбызның якты истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән “Авыл офыклары” район газетасы редакциясе коллективы Кадыйр Сибгатуллинның музеен һәм аның исемендәге премия булдырган иде. Марсилә Садыйкова, Габдрахман Фәйзуллин, Фәнүзә Галимуллина, Илгиз Галиев, Рәмзил Гыймлеханов кебек лауреатлар арасында күп еллар буе мәктәбебездә тарих фәне укыткан, бүгенге көндә мәктәптә эшләп килүче Туган якны өйрәнү музее җитәкчесе булып эшләгән Ахунов Кәрим Гыйльфанович та бар. Кәрим Гыйльфанович Кадыйр Сибгатуллинны исән чакта белгән, аның белән аралашкан кеше. Мәктәбебездә Кадыйр Сибгатуллинны белгән, аның белән еш аралашкан тагын бер укытучыбыз бар. Ул – география укытучысы Адиуллина Хәтимә Вагизовна. Мөгаллимлек хезмәтенә керешкәнче, ул районыбызның газета редакциясендә Кадыйр абый белән бергә эшләгән. Хәтимә Вагизовна Кадыйр абыйның шигырьләрен төнлә язуына игътибар итә. Шагыйрьне белгән мөгаллимнәребезне чакырып сыйныф сәгатләре үткәрәбез. Барыбызга да мәгълүм булган Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевка багышланган “Сагыш” шигыре дә Бүкәш мәктәбендә герой белән очрашканнан соң туа. Мәктәп коллективы герой белән очрашу оештыра, анда Кадыйр абый да катнаша.

Кадыйр Сибгатуллин исемендәге премиягә укучылардан беренче булып, укучым Ләйсән Фәтхетдинова лаек булды. Ул Кадыйр Сибга-

туллинга багышлап шигырь дә иҗат итте. “Кадыйр Сибгатуллинга” дип атала ул. Кадыйр абыйсы кебек Ләйсән Фәтхетдинова үзе дә бүген шагыйрә.

“Мәдәни Җомга” газетасының 2007 нче елгы 23нче март санында Нияз Акмалның “Без яратмый җирдә кем яратсын” мәкаләсендә мондый юллар бар: “Аның шигырьләрен, шигъри үрнәкләрен мәктәп балаларына, яшүсмерләргә сабый чактан ук, яшьтән укыту зарур. Кадыйр Сибгатуллин шигырьләрен әдәби түгәрәкләрдә сабак итеп өйрәтү зарур”! Бу сүзләр белән без тулысынча килешәбез. Киләчәктә якташыбызның иҗатын тагын да тирәнрәк итеп өйрәнү максатыннан шигырьләре әдәбият дәреслекләрендә урын алыр дип ышанабыз. Ул моңа лаек. Безнең аны онытырга хакыбыз юк.

## ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ПРОЕКТЛАР ЭШЛӘҮНЕҢ ПЕДАГОГИК МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

***Мәрданшина Раузилә Мәлик кызы***
*Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы*
*“6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе”*
*бюджет белем учреждениесенең югары*
*категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Теманың актуальлеге**.** Илебезнең төрле тармаклары актив үсештә. Бу шәхестән, җәмгыятьтән, дәүләттән яңа, сыйфатлы белем таләп итә. Без ачык белем стандартларына омтылабыз, һәм ул хәрәкәт белем бирү күрсәткечләрен яңадан карауны, үзгәртүне сорый. Белем бирү күрсәткечләрен яңача аңлау эш төрләрен, алымнарын актив эзләүләргә этәрә.

Бу проблема турында. Укучыларның проект эшчәнлеге потенциалы

С.С. Гриншпун, А.В. Зайцева, Г.В. Пичугина тарафыннан тикшерелде. Бу потенциал укучыларның танып-белүе артуында, социаль яктан кызыксынучанлыгы үсүендә, иҗади активлыгында, җаваплылык тәрбияләүдә, рухи-әхлакый тәрбиядә, информацион культурасы үсешендә күренә.

Проект эшчәнлеген булдыру максаты:

– балаларны шәхси үстерү, максатына ирешергә өйрәтү;

– баланың коллективта, яңа шартларда эшләү мөмкинлеген арттыру;

– баланы эзләнергә өйрәтү;

– педагогларның һөнәри эшчәнлеген үстерү.

Проект эшчәнлегенең этаплары

– Әзерлек этабы

– Планлаштыру этабы

– Практик этап

– Эксперименталь этап

– Йомгаклау этабы

Проект темалары. Балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, теге яки бу авторның әдәби әсәрендә безнең алга куйган проблемаларын чишү максатында төрле сыйныфларда төрле проект темалары алына.

Проект эшчәнлегендә укучының, җитәкченең шәхси һәм коллективта үсеше.

– Укучыларның үзбәяләре үсә.

– Алар проект эшчәнлеге моделе һәм структурасы белән танышалар.

– Проблемаларны аерып чыгарырга, планлаштырырга, максат һәм бурычлар куярга өйрәнәләр.

– Аларның иҗади фикерләү дәрәҗәләре күрсәткече үсә.

– Коллективта, группада эшләүнең уңай күренеш икәнлеген аңлау арта.

– Укытучыда һөнәри яктан уңай якка үзгәрешләр барлыкка килә.

## ЛИЦЕЙДА МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮ

***Сөләйманова Разия Талип кызы,***
*Чирмешән районы МБГБУ "Чирмешән лицее"*
*I нче квалификацион категорияле*

Соңгы еллар татар халкының тормышына зур үзгәрешләр алып килде. Халыкның туган теленә, милли мәдәниятенә, рухи дөньясына, тарихына игътибар артты. Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе. Башлангыч сыйныфларда уку чоры – баланың әхлак йөзе үсешендә мөһим этап. Бу елларда әхлак нигезе салына, тирә–якны беренче күзаллау, этик күзаллау, патриотик хисләр формалаша. Нәкъ башлангыч сыйныфларда балаларның акыл үсеше югары темпта формалаша.

Безнең Чирмешән лицеенда һәр яңа уку елына икешәр сыйныф туплана.Берсе аның татар, икенчесе рус сыйныфлары дип атала. Бездә татар балаларын татар сыйныфларына бирү проблемасы да бар. Ата-аналарның шактые балаларын татар сыйныфларына бирергә ашкынып тормый. Моның сәбәпләре нидә соң?

Ата-аналарның кайберләрендә балалары татар мәктәбендә укып чыккач, абруйлы югары уку йортына керә алмас дигән шик була.Югыйсә, нәкъ ата-аналар үтенече буенча барлык уку-укыту процессы рус телендә бара. Сыйныфтан тыш,дәрестән соң үткәрелә торган чаралар,ата-аналар җыелышы татар телендә барса да. Ә бит татар мәктәпләрендә рус теле тиешле дәрәҗәдә укытылмый дигән караш күптәннән үзгәрде. Хәзер инде рус теле милли мәктәпләрдә дә яхшы укытыла, һәм тырыш балалар мәктәпне тәмамлаганда рус телен дә тиешле дәрәҗәдә үзләштереп чыга. Элегрәк татар теле һәм әдәбияты фәннәренә кирәкле уку әсбаплары, техник чаралар да башка фәннәрнекеннән калыша иде. Хәзер ул проблема да шактый дәрәҗәдә чишелеп килә.Дөрес, бакча балаларына, башлангыч сыйныф укучылары өчен матур бизәлешле, кызыктыргыч китаплар әз бастырыла.

Без соңгы елларда укыту һәм тәрбия процессын фикерләүдә күп очракта халык педагогикасына таянабыз. Халыкның педагогик осталыгы, аның тәрбияви байлыгы галимнәрне генә кызыксындырып калмады, практик укытучыларның игътибарын җәлеп итте.Хәзер татар теленнән дә иҗади биремле күптөрле эш үрнәкләре барлыкка килде.

Минем укыту һәм тәрбия эшемдә милли төбәк материалы дәресләрдә куллану һәм укучыларда милли үзаң тәрбияләү буенча тормышка ашырыла. Мин укучыларда милли үзаңлылык тәрбияләүдә татар халык иҗатын кулланам.

Татар халык уеннары, әкиятләре, мәзәкләр, табышмаклар балаларда уйлану куәтен үстерә. Татар халык иҗатын өйрәнү, класстан тыш чараларда да дәвам итә. Шулай ук татар халкының гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре белән таныштыру, өйрәнү алып барыла. Минем максатым:мөмкин булган чаралардан файдаланып укучылырда милли төбәк материалларын куллану һәм милли үзаң тәрбияләү.

Без лицейда 25 декабрьдән алып 5 январьга кадәрге чорда **Нардуган** бәйрәме үткәрәбез. Бәйрәмнең төп мизгелләре түбәндәгеләр: кеше танымаслык итеп киенеп, йорттан йортка керү, йөзек салып багу,кеше турында төрлечә багулар бәйрәмнең төп мизгелләре булып санала.

Ямьле язны каршылап, һәр елны **Нәүрүз** бәйрәме оештырыла. XIX гасырда Урта Идел буенда татарлар яшәгән авылларда үткәрелгән бу

бәйрәм “яңа көн” дигәнне аңлата. Урта Азиядә, Иранда, Әфганстанда Яңа елны каршылау бәйрәме итеп үткәрелә.Бу көнне укучылар язны мактап җырлар җырлыйлар, шигырьләр сөйлиләр, ярышлар оештыралар.

Үзенә генә хас булган йола, атрибутларын һәм күңел ачу төрләрен үз эченә алган Казан татарлары бәйрәме– **Сабантуй**ны балалар белән май аенда табигатькә экскурсиягә чыкканда оештырабыз.

Кеше хәлен аңлый белү,кешегә ярдәм итү – шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек – җир йөзендә барлык халыклар өчен уртак сыйфат ул. Бәйрәм төсенә кергән. **Каз өмәсен** музыкаль композиция оештыруны бездә урта сыйныф укучылары үз өсләренә йөкләделәр. Җырлар җырлый-җырлый кызлар каз “йолкалар”, ә егетләр гармун тарталар.Кемне кызыксындырмас бу бәйрәм! Укучылар хезмәт ярату, җәмгыять өчен файдалы эш белән шөгыльләнү кебек сыйфатларны бәйрәмнәр, күмәк эш белән тормышка ашыралар.

26 нчы апрель – сөекле язучыбыз Тукай туган көн. Шул уңайдан безнең лицейда апрель ае – татар теле айлыгы дип игълан ителде. Балалар табышмаклар кичәсе, сәнгатьле шигырь уку конкурсына һәм башка чараларга ныклап хәзерләнәләр. “Соңгы шүрәле” әкиятен сәхнәләштерәләр. Мәдәният үзәге каршында оештырыла торган Шигырь бәйрәменә җыеналар.

Шулай итеп, безнең лицейда татарча укыту-тәрбия эшчәнлеге зур урын алып тора. Милли тәрбия эчтәлеге сыйныф сәгатьләре,әңгәмәләр, түгәрәкләраша тормышка аша. Бу максаттан лицей педагоглар өстәмә белем бирү учреждениелщре, музыка, сәнгать, спорт мәктәпләре мөмкинлекләренн дә нәтиҗәләреннән файдаланалар.

# ДИНИ ТӘРБИЯ ҺӘМ ЗАМАН ПЕДАГОГИКАСЫ

***Усманова Ильгия Илдус кызы***
*Казан шәһәре ГБМБУ “71 нче мәктәп”*
*татар теле һәм әдәбият укытучысы*

Педагогиканың үсеше педагогик фикерләүнең даими үзгәреп, яңарып торуына ярдәм итә. Шуның нәтиҗәсе уку-укыту, тәрбия өлкәсендәге үзгәрешләрнең төп шарты булып тора. Хәзерге чорда да педагогика, билгеле бер үзгәрешләр кичерә. Тарихка күз салсак, Советлар Союзы дәверендә кешенең әхлакый тәрбия принциплары бердәм коммунистик

идеологиягә нигезләнә. Бу чорда балаларның 80 проценты күп вакытларын яслеләрдә, балалар бакчаларында, мәктәптә, пионер лагерьларында үткәргәннәр. Яшь буынны тәрбияләүдә җәмәгатьчелек тәрбиясе өстенлек алган иде. Ә бүгенге көндә икътисадның җимерелүе, гаиләләр таркалу һ.б.шундый тискәре сәбәпләр балаларны җәмәгатьчелек күзәтчелегеннән һәм гаилә тәрбиясеннән дә мәхрүм итте. Хәзер алар бүгенге мохит йогынтысында тәрбияләнә. Статистик мәгълүматларга таянып, психологлар, социологлар баланың шәхес булып формалашуына гаиләнең йогынтысы 54 процент, урамның – 34 процент, ә мәктәпнең – бары тик 12 процент кына тәшкил итә диләр.

Бүгенге көндә җәмгыятьтә бердәм идеология булмау сәбәпле, иҗтимагый аңда идеологик бушлык барлыкка килде. Яшьләргә нинди идеалларга омтылырга? Тормыш мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт? Бу сорауларга төпле идеологик формада платформа булганда гына ачык җавап бирергә була: ул идеология фәнни-фәлсәфи яисә дини – икесенең берсе генә була ала. Идеологиясез педагогика камил шәхес тәрбияли алмый. Тәрбия эшенең барышы максатчан булып, һәр җирдә, гаиләдә, мәктәптә, эштә, ял итү, күңел ачу урыннарында гомум принципларга нигезләнгәндә генә уңышка ирешә ала. Гаиләдә дини принципларга, мәктәптә дөньяви карашларга таянып эш итсәк, бу хәл шәхеснең “икегә ярылуына” китерергә мөмкин. Хәзерге вакытта тәрбия эшендә гуманистик педагогикага, эксперименталь методларга игътибар бирелә. Ләкин психология һәм социология кебек гуманитар фәннәрен өйрәнгәндә, эксперименталь ысулларны куллану нәтиҗәләр бирми, һәм бу методлар белән тәрбия закончалыкларын ачып булмый. Чөнки кеше җансыз матдәләрдән һәм башка тереклек ияләреннән Аллаһы Тәгалә аңа өргән җаны белән аерылып тора. Шуңа күрә, мөселманнар әхлак кодексын, рухи тәрбия ысулларын ислам чыганакларыннан алалар. Соңгы вакытта җөмһүриятебездә талантлы балаларны эзләү, хуплау, үстерү буенча комплекслы программалар тормышка ашырыла. Төрле олимпиадалар, ярышлар уздырыла. Педагоглар балалар тәрбиясендә сәнгать, мәдәният, спорт хәлиткеч роль уйнаячак дип өметләнәләр.“Мәгариф нинди булырга тиеш соң?” дигән сорауга галим-педагоглар бертөрле генә җавап бирмиләр. Әлегә бу өлкәдә дини юнәлешләрдә тәрбияләү дигән тәкъдимнәр күренми. Шулай итеп, дини тәгълимат аша шәхес формалаштыру дигән фикер бүгенге көндә актуаль проблема, тикшерәсе мәсьәлә булып кала.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МИЛЛИ – ТӨБӘК КОМПОНЕНТЫН КУЛЛАНУ

***Хайруллина Ләйсән Альберт кызы***
*Чистай муниципаль районы*
*1 нче урта белем бирү*
*мәктәбенең татар теле*
*һәм әдәбияты укытучысы*

Заман алып килгән яңалыклар, үзгәрешләр уку-укыту эшчәнлегенә дә үтеп керде. Без татар теле һәм әдәбияты укытучылары алдындагы төп бурычларыбызның берсе – һәрьяктан камил булган зыялы шәхес тәрбияләү. Ә ул,үз чиратында, туган телебезне яратучы, үз халкының мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, иң күркәм йолаларын, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш.Туган якның табигате, аның тарихы,халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Укучылар дөньякүләм танылган язучы – шагыйрьләребез иҗатын кабул итсеннәр өчен, аларны туган як әдипләренең тормышы, эшчәнлеге белән таныштырып үтәм. Укучылар шәһәребез язучылары И.Исламов, М. Мифтахова, Ш.Хафиз, Р. Хисми, Р.Шәйхетдинова, Р.Сафина белән булган очрашуларда үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар эзлиләр, шигырьләрен укыйлар, ятлыйлар.

Шәһәребездә “Энҗеләр” һәм “Ступени” иҗат берләшмәләре эшләп килә. Һәр язучының да Чистай шәһәренә багышлап язылган әсәрләре бар, алар “Туган як энҗеләре” дигән китапта урын алган.

Чистай районында – сәнгать осталары күп.Сәнгать осталарыбызның иҗаты белән таныштыру,җырлар тыңлау укучыларны сәнгатькә якынайта. Сәнгать осталары халкыбызнын төрле милли йолаларын чагылдырган бәйрәмнәр уздыралар.

Безнең районыбызда да татар әдәбиятында якты эз калдырган Кояш Тимбикова исемендәге премия булдырылды . Бу премия зур уңышка ирешкән районыбыз әдипләренә бирелә. Хәйдәр Гатин, Фоат Хасанов, Рәшит Хисми бу олы бүләккә лаек булган язучылар.

Җирле материалларны кулланганда, дәрес җанлырак, кызыклырак уза. Укучылар да әсәрләрне җиңелрәк үзләштерәләр. Туган якның матурлыгын күреп үскән бала күңелендә начарлыкка урын калмый.

# ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫНА КҮЧҮ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА АЛДЫНГЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРГӘ НИГЕЗЛӘНҮ

***Хамидуллина Люция Сәетгәрәй кызы***
*Казан шәһәре 169 нчы урта мәктәктәпнең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Мәгариф системасына бүгенге җәмгыять зур таләпләр куя. Яңа технологияләргә нигезәнү, укытуның сыйфатын яхшырту, сыйфатлы белем бирү – бүгенге көн мәктәбенең төп бурычы. Россия Федерациясенең Мәгарифне үзгәртеп кору концепциясе критик фикерләүче шәхес тәрбияләүне төп максатларның берсе итеп тәкъдим итә. Белем бирү системасында бу төшенчә стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камилләшүен таләп итә. Укыту эшчәнлегенең икеяклы процесс булганлыгын истә тотсак, укытучы шәхесенең ни дәрәҗәдә белем байлыгына ия булырга тиешлеген күзалларга мөмкин. Чөнки төрле өлкәләрдә үзлегенннән белем алып, аны тормышта куллана алучы укучы шәхесе белән эш алып барабыз.

Критик фикерләү технологиясен тәкъдим итүче галимнәр әлеге юнәлешнең күп төрле һәм киң кырлы нәтиҗәләрен ассызыклыйлар.

Бу технология укучыга нәрсә бирә:

– мәгълүматның кабул итү тәэсирен көчәйтә;
– кызыксыну уята;
– критик фикерләргә этәрә;
– җаваплылык, үзаң формалаштыра;
– белем алуның сыйфатын күтәрә;
– бергәләп эшләтә;
– үзеңне замана белән бергә атлаучы шәхес итеп тоярга мөмкинлек бирә.

Критик фикерләү технологиясе укытучыга нинди мөмкинлекләр ача:

– класста ачык һәм эшлекле мөнәсәбәт булдыра,
– сыналган уку-укыту модельләрен, нәтиҗәле методларны файдаланырга этәрә,
– үз эшчәнлеген анализлый белүне таләп итә,
– һөнәри осталыкны ачарга ярдәм итә.

Критик фикерләү технологиясенең төп үзенчәлекләренең берсе – укучы белән укытучы арасындагы әңгәмәдә һәм укыту эшчәнлегендә

тигез хокуклылык. Укытучы мәгълүмат чыганагы түгел, ә юнәлеш, юл күрсәтүче буларак карала. Ул укыту эшчәнлеген кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештыра.

Соңгы елларда проект технологиясе нигезендә белем бирү бик актуаль. Бигрәк тә югары классларда бу алым отышлы. Өлкән классларда бу юнәлеш үзен аклый да, чөнки үз алдыңа масат кую, шуны чишүгә омтылу – эзләнүне таләп итә торган эшчәнлек. Тормышта үз урынын табарга омтылган яшьләр эзләнү-тикшеренү эшенә бик теләп алына. Әлбәттә, биредә алыштыргысыз ярдәмче – фәнни җитәкче. Бүген без – мәктәп укытучылары бу эштә дә үзебезне сыный киләбез, һәм әйтергә кирәк, сынатмыйбыз. Төпле фикер, акыллы киңәшләребез белән үзебезнең укучыларыбызга бик теләп ярдәм итәбез. Проект технологиясе нигезендә эш алып бару мәктәп укучысы шәхесенең үсешен төрле юнәлешләрдә ача. Мин аны түбәндәгеләрдә күрәм:

– әйләнә-тирәне аңлау, үзаңны үстерү;
– үзлектән белем алуны үстерү;
– иҗадилыкка ирешү;
– интеллектуаль һәм иҗади мөмкинчелекләрне үстерү;
– фәнни күзаллауны үстерү;
– үзең куйган көчкә ышаныч тәрбияли;
– үзмаксатка илтү юлын ныгыта.

Югары класс укучысы – шактый үсешкә ирешкән шәхес. Иҗадифәнни эш белән шөгыльләнү аның тел байлыгын тагын да баета, тирәнәйтә. Бу үзеннән-үзе тел өлкәсендәге лингвистик компетенция булдыруны күз алдында тота. Федераль дәүләт белем бирү стандартларының телләрне өйрәнүгә куйган төп таләбендә әлеге компетенция беренчеләр рәтендә. Иҗади эш белән шөгыльләнергә алынган укучы кирәкле мәгълүматны эзләп күп кенә белешмә сүзлекләргә, башка чыганакларга мөрәҗәгать итә. Үзен төрле яклап үстерә, камилләштерә. Үз фикерен дәлилләргә өйрәнә. Бу белем бирү стандартларының тагын бер таләбе коммуникатив компетенциянең үсешенә китерә. Стандартның өченче таләбе сөйләм культурасына ирешү аралашу барышында турыдан-туры барлыкка килергә тиеш. Чөнки тел нормаларына нигезләнергә күнеккән иҗади шәхес бу юнәлешкә үзеннән-үзе килә дип исәплим.

Фәнни-практик эш белән шөгыльләнүдә проект технологиясенә нигезләнү ике төрле юнәлешкә нигезләнә: беренчедән, дәрестә алган белемне үстерә, киңәйтә, камилләштерә, икенчедән, дәрестән тыш булган чараларны да читкә какмыйча, аларның әһәмиятен тагын да арттыра. Шул рәвешле, укыту-тәрбия эшчәнлегенең бербөтен камиллеген тәшкил итә.

Критик фикерләү технологиясе Блум ромашкасын куллануны күз алдында тота, шулай ук универсаль укыту гамәлләрен үтәүне дә үз эченә ала. Сорау бирү, ул сорауны укучының формалаштыруы, иптәшенең әлеге сорауга җавап эзләү барышы; шул бирелә торган сорауларның үз тәртибе булу, берсенең икенчесе дәвамы булып торуы; сорауларга җавап эзләгәндә укучының белгәннәрен үз башында тәртипкә китереп җавап бирергә омтылуы; фән буенча алган белемнәре белән бергә әйләнә-тирә мөхиткә дә таянып һәм башка фәннәрдән алган белемнәрен дә истә тотып җавап бирүе – дәрестә укучы эшчәнлегенең отышлы алымнарының берсе. Әлбәттә, куелган максатларның берсе – укучыларның критик фикер йөртү сәләтен үстерү. Әлеге сыйфат укуда гына түгел, ә бәлки мәгълүматны кабул итү, асылына төшенү, объектив бәя бирү, анализлау өчен тормышта да кирәк. Укучылар әлеге юнәлештә эшләгәндә, куелган сорауга җавап биргәндә уйланылган, төгәл адым ясарга өйрәнәләр. Мәгълүматны кабул итеп кенә калмыйча, аны төшенеп, аңлап, актив кулланып эш итәләр. Шулай ук критик фикерләү технологиясенең алымнары булган ПМК, БББ таблицалары нигезендә эш алып бару да каралган.

**Критик фикерләү технологиясендә дәрес структурасы**

| Этаплар | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Кулланыла торган метод һәм алымнар |
|---|---|---|---|
| **I стадия**<br>**Кызыксындыру**<br>Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү<br>-кызыксыну уяту,<br>-үзмаксат кую | алган белем һәм күнекмәләргә таянып, яңаларын кабул итәргә җирлек әзерли | искә төшерә, мәгълүматны бер җепкә тезә, сораулар куя | Алынган мәгълүматның исемлеген төзи: төп моментларны сөйли, схемага тезә.<br>кластерлар,<br>таблица,<br>дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар,<br>эзлеклелеге буталган логик фикерләр,<br>проблемалы сораулар,<br>гади һәм катлаулы сораулар таблицасы. |
| Эш төрләре индивидуаль, парлы, төркемдә башкарыла. Бу стадиядә мәгълүмат кабатлана, системага кертелә. | | | |

<table>
<tr><td>II стадия<br>Төшенү<br>– яңа материал кабул ителәə</td><td>кызыксындыру, белем һәм күнекмәләргә таянып, яңаларын формалаштыра</td><td>Текстны тыңлый, укытучы тарафыннан кулланылган метод һәм алымнарга таянып, текстны үзләштерә (тыңлый, кабул итә, кирәк моментларны билгели)</td><td>Инсерт,<br>Фишбоун,<br>Борт журналы,<br>Икеяклы көндәлек<br>Дәреснең башында куелган сорауларга җавап эзләү</td></tr>
<tr><td colspan="4">Эш төрләре – индивидуаль яки парлы. Парлап эшләгәндә шәхси күзәтү һәм фикер алмашу тәртибе сакланырга тиеш. Бу стадиядә яңа материал (текст, фильм, лекция, параграф) үзләштерелә.</td></tr>
<tr><td>III стадия<br>Рефлексия<br>Уйлану,<br>Фикер туу,<br>Яңа максат һәм бурычлар кую</td><td>Укытучы беренчел фикер һәм ниятләргә кайта; кирәк дип тапса, үзгәреш кертә; яңа үтелгән материал буенча иҗади һәм тикшеренү, гамәли биремнәр бирә</td><td>Укучы ике мәгълүматны (“иске” белән “яңа”) чагыштыра</td><td>– таблица, кластерлар тутырыла;<br>– төп фактлар арасында бәйләнеш ачыклана;<br>– терәк сүзләр, дөрес һәм дөрес булмаган раслаулар;<br>– сорауларга җавап;<br>– түгәрәк өстәл; дискуссия;<br>иҗади язма эш.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Эш төре – индивидаль, парлы, төркемдә. Материалны анализлау, иҗади эшкәртү, интерпретацияләү.</td></tr>
</table>

Яңа технологияләр куллану укуга кызыксыну уяталар, иҗади эзләнүне активлаштыралар, фикерләү сәләтен үстерәләр. Алым һәм методлар төрлелеге максатка ирешү чарасы булып тора. Иң мөһиме – укытучы үзенең эш нәтиҗәсен укучыларының уңышлары аша күрә.

# ЯҢА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР, АЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

***Хуҗанбердиева Чулпан Тимергали кызы***
*Түбән Кама муниципаль районы*
*Муниципаль бюджет гомуми белем*
*бирү учреждениесе “35 нче лицей”*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Соңгы елларда мәктәптә яңа технологияләр актив кулланыла. Педагогик технологияләр – укытучы эшчәнлеген билгеле бер эзлеклелектә оештыру һәм фаразланган нәтиҗәгә ирешү юлларын билгеләү ул. Технологияләр нигезендә эшләү ни өчен кирәк соң? Билгеләмәдән үк күренгәнчә, педагогик технологияләр нәтиҗә бирә торган эшчәнлекне аерым бер эзлеклелек белән алып бару өчен кирәк. Эш барышында технологик логика (мантыйк)ка нигезләнү көтелгән, гарантияләнгән нәтиҗәлеккә китерә дә инде.

Педагогик технологияләр 3 төп төркемгә бүленә (Ксекзова Т.И. бүленеше):

а) аңлатмалы-күрсәтмәле (объяснительно-иллюстратвные технологияләр;

б) шәхес үстерүне игътибар үзәгендә тоткан (личностно-ориентированные) технологияләр. Аңа төрле дәрәҗәдәге укыту (разноуровневое обучение), күмәк төстә үзара укыту (коллективное взаимообучение), модульле укыту (модульное обучение)керә;

в) үстерелешле укыту технологияләре (технологии развивающего обучения).

Әлеге 3 төркемне 2 зур терминнарга кертеп карап була: аның беренчесе – традицион, ә соңгы икесе инновацион технологияләр буларак тәкъдим ителә.

Аңлатмалы-күрсәтмәле технологияләр укыту эшендә укытучыга аерым бер урын билгели. Бу очракта ул үзен өстенлекле урында: командир да, хөкемдар да, түрә дә дип хис итә. Әмма шул ук вакытта: «Дәрес барышында бөтен нәрсә өчен җаваплы бит мин!» – дигән борчулы уйлар күңелен гел бимазалап тора. Шулай булгач, укучыга мөстәкыйль эшләүнең кирәге калмый: бары тик тавышланып утырмасын да укытучы күрсәтмәләрен төгәл генә үтәсен. Бу очракта баланың бернәрсәгә дә җавап тотасы юк.

Аңлатмалы-күрсәтмәле технологияләр төп игътибарны белемнең ни дәрәҗәдә үзләштерелүен тиз арада тикшерү мөмкинлеге булган тышкы күрсәткечләргә, ягъни өлгереш процентына, уку процессының дидактик яктан ничек җиһазланган булуын ачыклауга юнәлтә. Әмма шул ук вакытта бала аңында бара торган үзгәрешләр, аның үсешендәге интеллектуаль үзенчәлекләр белән бәйле эчке күрсәткечләр, эзлекле рәвештә өйрәнелмичә укытучының игътибарыннан читтә кала.

Шәхесне үстерүне игътибар үзәгендә тоткан технологяләргә:

– белемне тулысынча үзләштерү;

– төрле дәрәҗәдәге укыту;

– күмәк төстә үзара ярдәмләшеп укыту;

– модульле укыту технологияләр кебек яңа педагогик алымнар керә.

Алар уку-укыту процессын балаларның шәхси сәләтенә, төрле дәрәҗәдәге аралашуга, һәр мәктәпнең үзенчәлекләренэ яраклаштыру мөмкинлеге бирә.

Үстерелешле укыту технологияләренә Л.В. Занков, Д.Б. Эльконин – В.В. Давыдов, Ә.З. Рәхимов, А.Г. Яхин системалары кертеп карала. Әлеге системалар уку-укытуны шәхеснең аң үсеше чарасына әверелдерүгә ирешә.

Хәзерге вакытта мәктәпләргә кертелә торган барлык яңалыклар, башлыча, күнегелгән технологияләр кысасына керми торган уку фәннәре эчтәлеген, укыту рәвешен һәм алымнарын үзгәртүгә кагыла. Аның максаты укучыларның күпчелеге танып белүнең арта барган ихтыяҗы дәрәҗәсендә укый алырдай шартлар тудырудан гыйбарәт. Димәк, укытучының һөнәри эшчәнлегендә эзләнү, педагогик иҗат өчен офыклар һәрвакыт җитәрлек, һәм тормыш үзе дә яңа технологияләр куллануны таләп итә. Заман мәктәбенә балаларның шәхси үзенчәлекләрен искә алып һәм иң яхшы традицияләргә нигезләнеп укытуның принципиаль яңа системасы кирәк. Менә шуңа да укыту технологияләрен эшләү һәм аларны гамәлгә кертү, тагын да төгәлрәк әйткәндә, балаларның уку эшчәнлегенең ачык, максатлы һәм ирешелергә тиешле нәтиҗәне алдан планлаштырып оештыру бик тә мөһим.

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ҮСТЕРЕЛЕШЛЕ УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНЕҢ БЕР МИСАЛЫ БУЛАРАК А.Г. ЯХИН МЕТОДИКАСЫ

*Хуҗанбердиева Чулпан Тимергали кызы*
*Түбән Кама муниципаль районы*
*Муниципаль бюджет гомуми белем*
*бирү учреждениесе “35 нче лицей”*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Традицион программа нигезендә әдәбият дәресләрендә укытучы әсәргә карата дәреслектә язылган әзер нәтиҗәне сөйләп чыгарга мәҗбүр. Шунда язылганнар гына хакыйкать дип исәпләнә. Алай иткәнчә, әсәр – бер нәрсә, ә аның дәреслектә язылган эчтәлеге икенче нәрсә булып чыга.

А.Яхин программасы нигезендә һәр әсәрнең эчтәлеге өлешләрнең үзара бәйләнешләрендә генә ачыла. Шул бәйләнешләр күбрәк табылган саен, әсәрнең эчтәлеген, идеясен ачу иҗади эшкә әйләнергә тиеш тә. Иҗади эшкә укучы да, укытучы үзе дә катнаша ала. Алар әзер аңлатмагаябышып ятмыйлар, үзләре эзләп тапкан нәтиҗәне үзләре үк исбат итәләр. Авторның фикер эзлеклегеген укучылар үзләре күзәтәләр. Әсәр эчендәге бәйләнешләрнең күплегенә, ягъни эчтәлек байлыгына карап, укучы әсәргә дә, аның авторына да бәя бирергә өйрәнә.

Дәресләрнең шактый өлеше әңгәмә рәвешендә үткәрелү сәбәпле, укытучы китапта язганнар белән генә канәгатьләнә алмый. Укучыларны уйлату өчен ул үзе дә өзлексез уйларга тиеш була. Балаларга тулырак җавап эзләтеп үзлегеннән җиңелрәк өстәмә сораулар бирә, үткән дәрес материалларын искә төшерә – булдыра алган кадәр фикерләү юнәлешен күрсәтергә тырыша.

Укытучы дәреслектә язганнарны кабатлату белән генә чикләнми Укытучыга ярдәмлек рәвешендә Альберт абый тарафыннан укытучылар өчен дәреслек-кулланмалар да төзелгән. Яңалыкны кабул итеп, аңа күчү бер авырлык, киртә булып торса, рус мәктәбендә эшләүче укытучылар өчен иң авыры – татар төркемендә татарча аңлый, рәхәтләнеп сөйләшә алучы чын татар балаларының елдан-ел кимүе. Төркемдәге 2-3 бала гына әсәрне укып, эчтәлеген сөйли ала икән, нинди А.Яхин методикасы дияр күпләр.

Ләкин үзең белгәч, балаларга да житкерәсе килә бит укытучының. Үзем эшләгән татар төркемнәрендә А.Яхин методикасының кайбер эле-

ментларыннан бик теләп файдаланам. Шуларның укучыларга да, үземә дә ин якыны – ул инша язу. «Сочинение» атамасы «сочинять» (иҗат итү) дигән сүздән ясала. Шуңа күрә нинди темага нинди стиль белән язсалар да, укучыларга бер таләп куела: ул сочинениясен үзе уйлап язарга тиеш. Аннан-моннан башкалар язган җөмләләрне чүпләп цитаталар җыеп язу балага фәкать зыян гына ясый, мөстәкыйль уйлаудан белдерә. Башкалар язганны үзенеке итеп тәкъдим итү ялганнарга гадәтләндерә. А.Яхин методикасы буенча инша (сочинение) дигән жанр юк. Инша – мәкалә, фәнни хезмәт, иҗади эш, информация, очерк, хәбәр жанрларына бүленә. Иҗади эшкә вакыт бермә-бер күбрәк бирелә. Сочинение укучыны мөстәкыйль рәвештә уйларга һәм фикерләрен җыйнак, камил итеп язарга өйрәтә.

Фикеремне йомгаклап, шуны әйтәсе килә: технологияләр күп төрле, укытучы аларны үз белеме, мөмкинлеге, материаль-техник базадан, укучыларның белем дәрәҗәсеннән чыгып сайлый һәм куллана ала.

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНЫҢ МИЛЛИ РУХЛЫ ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮДӘГЕ РОЛЕ

***Шакирова Рузалия Мәүлемҗан кызы,***
*Аксубай муниципаль районы*
*“Шәрбән төп гомуми белем бирү мәктәбе”*
*I квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Балаларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, сәнгате белән кызыксынучы, үз милләте белән горурланучы шәхес тәрбияләү– бүгенге татар теле һәм әдәбияты укытучыларының төп бурычы. Татар теле һәм әдәбияты укучыларны тормышка әзерли, төрле яклап хәзерлекле шәхесләр формалаштыра, аларның хисләрен, әхлак сыйфатларын, зәвыкларын камилләштерә. Шуңа күрә укыту һәм тәрбия эшендә халык педагогикасына таяну зур нәтиҗәләр бирә. Укучыларга милли тәрбия бирүдә татар халык иҗаты әсәрләренең роле бәяләп бетергесез. Татар халык мәкальләре, әкиятләре, мәзәкләре, табышмаклары балаларда уйлану куәтен үстерә, милли үзаң тәрбияли.

Милләтебезнең күренекле мәгърифәтчеләре халык авыз иҗаты әсәрләренең зәвык, акыл, әхлакый тәэсир көченә, аларны өйрәтүнең

зарурлыгына һәрвакыт зур әһәмият бирделәр. Каюм Насыйри халык әкиятләренең, бала тәрбияләүдәге әһәмияте ягыннан, хәтта балалар өчен махсус язылган башка әсәрләрдән югары торганлыгын ассызыклый, үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлегендә алардан киң файдалана. Чөнки, ди ул, халкыбыз авыз иҗаты әсәрләренең гадилеге, алардагы саф күңеллелек бала психологиясе үзенчәлекләренә туры килә.

Татар халык авыз иҗатында, башка халыклар авыз иҗаты әсәрләрендәге кебек үк, фәлсәфә, медицина, этнография, география, педагогика, тарих өлкәләренә караган шактый күп гыйлемнәр табарга мөмкин. Без халык иҗаты аша тормышның төрле якларын, үткәннең дә, хәзерге көннең дә әһәмиятен тиәнрәк аңлыйбыз.

Туган тел чыганагы булган фольклор әсәрләрен мәктәптә өйрәнү балаларның тел байлыгын, фикерләү сәләтен үстеүгә булышлык итә .

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай да халкыбыз авыз иҗатына олы мәхәббәт һәм тирән хөрмәт белән карады. “Халык ядкарьләре – безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр... Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер”, – диде ул “Халык әдәбияты” дигән хезмәтендә.

Татар халык авыз иҗаты үз эченә күп төрле жанрларны ала: әкият, табышмак, мәкаль һәм әйтем, җыр, бәет, такмак, такмаза, риваять һәм легенда, кыйсса, эпос, дастан, мөнәҗәт, санамыш, тел көрмәкләндергеч, санамыш уеннар һәм башкалар.

Халкыбызның иң әһәмиятле беренчел педагогик әсәре, һичшиксез, бишек җырлары. Аларда аналарның теләкләре, ышанычлары, баласын рухи һәм физик яктан матур, булдыклы, игелекле, мәрхәмәтле, тәүфыйклы, гадел итеп күрү өметләре чагыла. Халкыбыз җырлары – күп төрле бизәкләрдән генә торган моңлы, аһәңле үзе бер дөнья. Җырларда дуслык, туганлык, халыкның кунакчыллыгы, татулык, кардәшлек һәм бердәмлек тойгылары чагыла.

Мәкаль һәм әйтемнәрнең эчтәлекләре дә бик гыйбрәтле. Аларны өйрәнгәндә яттан белү генә җитми. Үсмерләрнең башкалар белән аралашканда бу мәкальләрдә әйтелгән үрнәккә омтылулары, гыйбрәт алулары бик мөһим.

Әкиятләр кешенең гүзәллеген, сафлыгын, аның хыялларын чагылдыра. Аларда гыйлем алу, һөнәр – кәсеп өйрәнү, дуслык, үзара ярдәмләшү, батырлык кебек күркәм сыйфатлар турында сөйләнә.

Халкыбызның авыз иҗатында әкиятләр иң бай һәм мөһим жанрларның берсе булып тора. Мәктәпләрдә әкиятләрне өйрәнү

укучының зәвыгын тәрбияләргә, аның әдәби тел байлыгын, иҗади сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Җыр халык тарафыннан яратып иҗат ителә. Аның кешеләр өчен юлдаш, якын иптәш, рухи юаныч, көчле тәрбия чишмәсе булуын беләбез. Халык җырлары моннан бик күп гасырлар элек иҗат ителә башлый. Җыр кешенең рухын, күңелен баета, тормыштагы һәм сәнгатьтәге матурлыкны тоярга, күрергә, яратырга өйрәтә. Кешеләргә җыр көрәшергә, искене җимереп, яңаны төзергә булыша. Халык җыр белән авырлыкларны, хәтта үлемне дә җиңә.

Матур һәм тирән мәгънәле итеп әйтелгән мәкальне һәркем үз фикере кебек кабул итүе, яратып кулланучы мәкаль һәм әйтемнәрнең тиз таралуына һәм халык күңелендә озак вакытлар саклануына китерә. Мәкальләрнең төп максаты – кешеләргә әдәп-әхлак тәрбиясе бирү. Аларда яшь буынны тәрбияләү буенча үзенчәлекле милли яклар белән бергә бөтен кешелек өчен хас булган гомуми фикерләр дә чагыла.

Табышмаклар – мәкальләр һәм әйтемнәр кебек үк, халыкның афористик иҗат төре. Халык табышмакларын өйрәнү педагогик яктан әһәмияткә ия. Ул укучыларга өстәмә мәгълүмат биреп, тормышны танып-белергә өйрәтеп кенә калмый, балаларда игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияли.

Бәетләр татар халык иҗатына гына хас милли жанр. Бәетләр йөзләрчә ел буена халыкның тарихын, аның тормышында булган вакыйгаларны, хезмәт кешесенең кайгы-хәсрәтен, авыр тормыш шартларына нәфрәтен һәм киләчәккә булган якты теләкләрен чынбарлык җирлегендә чагылдырып килә.

Безнең татар халкы элек – электән бик тыйнак, хезмәт сөючән, олыны олы, кечене кече итүче, аң – белемгә омтылучы халык. Милләтне бетүдән саклап калу, анын мәдәни үсешенә юл ачу – безнең бурычыбыз. Бу даими, эзлекле булырга тиеш. Мәктәптә шушы эзлеклелек югалмаса, алып барылса, ул хәтердә уелып кала, гомерлек саклана. Әгәр дә без укыту – тәрбия эшен системага салып бирсәк, безнең киләчәгебез өметле булыр, балаларыбыз тәүфыйклы, тәртипле, миһербанлы, шәфкатьле булып үсәрләр.

# БАЛАЛАРДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Шакирова Миләүшә Рафаэль кызы***
*Тәтеш муниципаль районы «Каенкай"*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбияче*

Туган телебезне укыту проблемасы күтәрелүе, аны саклау һәм үстерү мәсьәләсе һәрвакытта да актуаль булып тора һәм ул заман таләбе. Шул уңайдан "Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Татарстан Республикасы законына нигезләнеп төзелгән планнар буенча эш алып барыла. Планнарны тормышка ашыруда тәрбиячеләр алдына зур бурычлар куела, нәтиҗәле эшләү өчен түбәндәге юнәлешләрдә эш оештырыла һәм белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү юлларына этәргеч бирә:

– диагностика һәм мониторинг нигезендә эшләү;
– практик юнәлештә эш формаларын көчәйтү;
– белем дәрәҗәсен бәяләүдә яңа формалар кертү;
– сәләтле балалар белән эшләүнең бердәм системасын булдыру;
– белем бирү процессында яңа педагогик һәм информацион– коммуникатив технологияләр куллану.

Бүгенге көн балалар бакчасы тәрбиячесе балаларга туган телне өйрәтергә, рус балаларының да татарча аралашуына омтыла икән, туган телне өйрәтү инновацион технологияләр кулланып, шул исәптән педагогның компьютер технологияләрен камил белүе, тирән белемле, тәҗрибәле, төрле яктан үрнәк шәхес булуы мөһим. Яңа стандартлар нигезендә белем бирүгә күчү уңае белән белем бирү программалары, методик әсбаплар төзелә. Туган телне өйрәтүнең дәүләт стандарты, белем эчтәлеген заман таләпләренә туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү бурычларын хәл итү максатында төзелә.Ул һәр баланың фәннән яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, һәр балага тигез мөмкинлекләр тудыра.

Туган телебезне саклау һәм үстерү һәрвакытта да мөһим мәсьәлә булып торды,чөнки телнең яшәеше һәм үсеше халыкның аны көндәлек тормышта ни дәрәҗәдә куллануына бәйле. Соңгы елларда туган телне укыту проблемасы күтәрелүе,аны саклау һәм үстерү мәсьәләләренең җитди рәвештә көн тәртибенә куелуы туган телне укытуны камилләштерүне таләп итә.

Социаль-иктисадый үзгәрешләр балалар бакчасы эшчәнлегенә дә яңалыклар кертүне таләп итә. Хәзерге заман шартларында эшләргә яраклашкан, көндәшлеккә сәләте формалашкан тәрбияче моделен булдыру кирәклеге иң әһәмиятле эш булып санала. Алдан күрү сәләтенә ия булган педагог кына хәзерге шартларда эшли ала. Мәктәпкәчә балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр яшь буынны белемле намуслы, кешелекле итеп тәрбияләү һәм тормышка әзерлә максатыннан күләмле эш башкара. Алда куелган бурычларны үтәү, белем бирү сыйфатын күтәрү өчен, яңа педагогик технологияләр кулланып, иҗади эшләүче педагоглар саны саны елдан-ел арта .

Технология – грек теленнән алынган сүз. Сәнгать дигән мәгънәне белдерә. Академик М.И.Мәхмүтов фикеренчә, алдан куелган бурычларны уңышлы үтәү өчен, тәрбияче һәм балаларның алдан планлаштырылган үзара бәйле эшчәнлеген технология дип атыйлар. Педагогик технологияне алдан планлаштырылган, һәр этабы конкретлаштырылган белем бирү, тәрбия процессы кагыйдәләре дип әйтә алабыз.

Милли мәгариф үсешен тәэмин итүдә мөгаллимнәребез максатчан эшли. Мәктәпкәчә яшьтәге эшләүче тәрбиячеләр арасында, яңа педагогик технологияләрне, аларның элементларын өйрәнеп, белем бирү, тәрбия эшчәнлегендә отышлы куллanучылар шактый. Яңа мәгълүмати технология кулланып эшләү тәрбиячeнең дә, баланың да тиешле әзерлекле булуын таләп итә. Технологияләр күптөрле, ләкин аларның барысы да гомуми бер идеягә-тәрбияченең танып белү эшчәнлеге белән идарә итү ысулларын булдыруга нигезләнә, белем бирү процессының нәтиҗәлелеген күтәрү, аң активлыгын үстерү һәм белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатына хезмәт итә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: тел – ул милләт сакчысы . Шуңа күрә балаларыбызга телебезне, әдәбиятыбызны өйрәтү, аларны тарихыбызның, мәдәниятебезнең, сәнгатебезнең энҗе – мәрҗәннәре белән таныштыру– безең изге бурыч. Күренекле галим, педагог, мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддиннең “Эш дәвамлы булганда гына нәтиҗәсе була” дигән гыйбарәсен күз алдында тотып, эшләребезне дәвам итәргә язсын.

# ТАТАР ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫНДА ӘХЛАК ТӘРБИЯЛӘҮ

***Шәрифуллина Лилия Рафык кызы***
*“Шәрбән төп гомуми белем бирү мәктәбе”*
*МБГБУ инглиз теле укытучысы*

Татар милләте үзенең яшәү, узара һәм башка милләтләр белән аралашып яшәү кануннарын булдырган. Алар әдәп-әхлак нормаларында,кешегә булган таләпләрендә чагылыш табалар. Шулай итеп,алмашка килгән һәр буын үзләштерергә, камилләштерергә, үстерергә тиешле булган яшәү кагыйдәләре, әдәп-әхлак идеаллары формалашкан. Ул кануннарны саклау, үстерү, яңаларын булдыру һәм аларны яшь буынга тапшыру милләтетебез педагогикасының мөһим бурычы булып тора. Моннан күренгәнчә, милләтнең иң изге хыялы һәръяклап үскән кеше тәрбияләү булган. Аның асылын әдәп, әхлак төшенчәләре тәшкил итә. Бу төшенчәләр телдә, мәгънәләре бердәй, якын булган, ягъни синоним тәгъбирләр итеп кулланыла.

Әхлак төшенчәсе-кешеләрнең бер-берсенә һәм җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләр калыбы,кысасы һәм мәсләкләре туплынмасы дип,ә әхлаклы,тәрбияле,әдәпле дип аңлатыла. Әдәп-әхлак кысаларында үзеңне тота елү кагыйдәләре, яхшы гадәтләр. Әдәпле кеше-инсафлы, тыйнак, тәртипле, тотанаклы, үз-үзен тота белә. Халык педагогикасы дип кешеләрнең табигый шартларда күзәтүләр нәтиҗәсендә туплаган тәҗрибәсен киң халык массаларын тәрбияләү һәм белем бирү өчен куллану ысулларын атыйлар. Аның нигезендә белем һәм тәрбия бирүдә киң халык массаларының тәҗрибә, сәләт һәм осталыкларыннан уңышлы файдалануы ята. Халык педагогикасын өйрәнгәндә еш кына безгә башка фәннәргә, бигрәк тә фольклор һәм этнография кебек, тәрбия бирүдә мөһим фактик материал бирүче фәннәргә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Тәрбияви өлкәдә фольклор әсәрләре аеруча мөһим роль уйный. Шуңа күрә дә яшь буынны тәрбияләү процессында еш кына педагоглар халык авыз иҗатыннан уңышлы файдаланалар. Халык педагогикасында яшь буынны тәрбияләүнең күп гасырлык тәҗрибәсе тупланган. Яшьләргә әхлак тәрбиясе бирү өлкәсендә халык гасырлар буе яшәп килгән үзара мөгамәләне чагылдырган нормаларга таянган. Халык педагогикасында игътибарны җәлеп итәрлек, кызыксындырырлык уңай тәҗрибәләр һәм халыкларның гади әхлак нормалары хәзерге мәктәпләрдә дә яшь буынны тәрбияләү процессында мөһим роль уйный. Тәрбия эшләрен уңышлы

алып бару өчен җирле халыкларның яшьләрне тәрбияләүдә кулланыла торган традицияләренә таяну, аларның гореф-гадәтләренә игътибар бирү зур әһәмияткә ия. Шуның өстенә, балаларга җирле халыкка якын һәм аңлаешлы булган әхлак тәрбиясе бирү тәҗрибәсе ата-аналарның педагогик аңлылыгын үстерүгә дә уңай йогынты ясый.

Әхлак тәрбиясе бирүдә балаларның зурларны ихтирам итүләренә нык игътибар ителә. Яшьләрнең әхлакый принциплары формалашуда гаилә тәрбиясенең роле бик зур. Гүзәллек белән тупаслыкны, яхшы белән ялганны буташтырмау, үзара мөнәсәбәттә ихтирамлылык, ялагайлык, ясалмалылык кебек сыйфатларны аера белү яшь кешене чолгап алган тирәлекнең йогынтысы тәэсирендә бара. Һәр кешедә, аеруча үсмер чакта, үзенә генә хас нечкәлек, эмоциональ сизгерлек була. Шәхеснең бу сыйфатлары үсешендә, уңай яки кире якка үзгәрешендә аны тәрбияләгән гаилә йогынтысы зур урын алып тора. Татар халык педагогикасында яшьләрдә әхлак тәрбиясе принципларын формалаштыруга, баланы кечкенәдән өлкәннәрне ихтирам итәргә өйрәтүгә зур игътибар бирелгән. Балалар кечкенәдән гаделлеккә, игелеклелеккә омтылалар. Алар бу үрнәкләрне өлкәннәрдән күреп кабул итәләр. Әгәр дә өлкәннәр боларның киресен эшләсә, балаларның да шуны ук кабатлавы табигый күренеш. Кешегә нинди мөнәсәбәттә булсаң, үзеңә дә шундый мөнәсәбәттә булырлар. Халык педагогикасында да бу фикер нык үстерелгән.

Балага әхлак тәрбиясе бирү – тәрбиянең төп бурычы. Әхлак тәрбиясе бирүнең нигезендә баланы яхшылыкка өйрәтү, начар икәнлеген белерлек итеп, тәрбияләп үстерү ята. Ата-ананың вазифасы үз балаларының кече яшьтән әнә шул принципларны үзләштереп үсүенә, аларның көндәлек күнекмәләренә әйләнүенә ирешүдән гыйбарәт. Татар халык педагогикасында элек-электән укуга зур игътибар бирелгән. Укыган, белемле кешеләрне олылар хөрмәт иткәннәр. Татар халкында китапка игътибар аеруча зур булган. Крестьян өйләрендә дә китапны тактадан шүрлек ясап, кадерләп шунда саклый торган булганнар. Күп тапкырлар тикшерү һәм өйрәнүләр нәтиҗәләре. Халыкларның кешелекле, әдәпле, кунакчыл булу сыйфатлары аларның характерының асылын чагылдыра. Өлкәннәр элек-электән яшьләрне кунакны каршы алу йолаларына өйрәтә килгәннәр. Татарлар килгән кунакны беркайчан да кунак итмичә, сыйламыйча җибәрмәгәннәр. Татар халкы, кунак килер алдыннан, үз хуҗалыгын тәртипкә китерә. Ихтирам йөзеннән татарлар кунакны капка төбенә чыгып каршы алалар. Халык педагогикасы үз-үзеңне генә яратуга, эгоизмга кискен каршы чыга. Коллективтан йөз чөергән, үзен башкалардан өстен куйган кеше халык һәм коллектив тарафын-

нан ихтирам казана алмый. Ялгыз, башка кешеләр белән аралашмыйча, аларның ярдәменнән башка яшәү, гомер итү ифрат авыр булыр иде.

Бүгенге көн шартларында әхлакый тотрыклы шәхес тәрбияләүдә халкыбызның тәрбия идеаллары түбәндәгеләр: балага гадел, шәфкатьле, әдәпле, игътибарлы, изге күңелле кешелекле, итагатьле, миһербанлы, ихтирамлы, тыйнак, инсафлы, нәфесне тыя белү, хезмәт сөючәнлек, җиренә җиткереп эшләү кебек сыйфатлар тәрбияләргә кирәк.

## ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРДӘ МИЛЛИ ТӘРБИЯ ТЕМАСЫ

***Якупова Раушания Галимулла кызы***
*Балык Бистәсе муниципаль районы*
*2 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Җәмгыятебез үзгәрешләр, борылышлар чоры кичерде һәм хәзер дә үзгәрүен дәвам итә. Бу үзгәрешләр, әлбәттә, әдәбиятка, мәдәниятка, рухи дөнья– безга йогынты ясамый калмый.

Икътисадта, тормышның башка өлкәләрендә югары технологияләр кулланыла, компьютерлар заманында яшибез. Ләкин рухи-әхлакый яктан алга китеш сизелми, киресенчә, яшьләрнең әхлаклылык дәрәҗәсе төшә, түбәнәя. Бигрәк тә аларның бүгенге хәле борчый. Соңгы елларда илдәге кыенлыклар, тискәре күренешләр яшьләргә тискәре йогынты ясый. Вакытлы матбугат, радио, телевидение үсеп килүче яшь кеше аңына һәм рухына әдәпсезлек, культурасызлык үрнәкләрен сеңдерә. Алар күп очракта милләтнең гасырлар буена формалашкан әхлакый-этик кагыйдәләренә каршы куелалар.

Әйе, әхлаксыз баланың рухы да сәламәт булмый. Кешенең күңел сафлыгы, гүзәл холкы барлык байлыктан да өстенрәк, дибез. Шәх еснең тәрбиялелеген аның үз-үзен тотышына-тәртибенә карап бәялиләр. Тәртип-киң төшенчә, кеше тормышының бар якларын үз эченә ала.

Галим Р.Фәхретдин сүзләрен яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүдә девиз итеп алырга мөмкин: “Бала чакта алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да биреп бетерә алмас”.

Әхлаклылык кешенең гадәти сыйфатына әйләнсен өчен,моңа аны бала вакытыннан ук гадәтләндерергә кирәк. Бу– ата-ана, укытучылар,

тәрбиячеләр вазифасы. Шуңа да бүгенге мәктәп укыту, тәрбия эшен үзгәртеп коруның яңа алымнарын, юнәлешләрен эзли.

Яңа шартларда милли мәдәниятны өйрәнүне көчәйтү максатында гамәлдәге программалар эчтәлегенә милли аңы югары дәрәҗәдә үскән шәхес тәрбияләргә ярдәм итә торган милли-мәдәни алмнарны кертергә кирәк. Алар, милли бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗатын кулланып үткәрелгән чаралар, гореф-гадәтләрне һәм традицияләрне өйрәнү.

Балаларда милли үзаң тәрбияләүдә һәм аларны милли мәдәният белән таныштыруда, милли гореф-гадәтләрне, әхлак-әдәп кагыйдәләрен өйрәтүдә укытучы эшчәнлеге зур урын алып тора.

Яшь буынны, күңеле ак кәгазь кебек чиста укучы баланы без, әлбәттә, әдәбиятыбызның йөзек кашлары булган, яшәү мәгънәсен аңлатырдай әсәрләр язган әдипләребезнең иҗат җимешләре ярдәмендә дөрес, туры юлга алып чыга алырбыз.

Күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре халкыбызның гореф-гадәтләрен ачык, гади, халыкчан, аңлаешлы итеп сурәтли. Аның әсәрләрен укыганда, үзеңне шул вакыйгалар эчендә хис итәсең, бу бәйрәм, йолалар күңел түренә. Укучылар йөрәгенә җуелмас хатирә булып кереп калалар дип уйлыйм.

Туган як, табигать җырчысы Гомәр Бәширов үз әсәрләрендә халкыбызның тарихын табигать матурлыгы, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең күркәмлеге белән тыгыз бәйли. Әсәрләрендә бабаларыбызның атларга хөрмәте, орлык чыгару, чәчү, Сабан туе, аулак өй. өмәләр уздыру күренешләре киң колачлап сурәтләнә.

Гаяз Исхакыйның “Сөннәтче бабай” әсәрендә татар халкының борын– гы дан сакланып килгән йолаларына, гореф-гадәтләренә зур урын бирелә. Хикәя аша шатлык-кайгыны уртаклашып яшәү, авыруның үлен белү тәртибе, мәетне күмү йоласы күрсәтелә. Гөлйөзем образы аша татар хатын-кызы– ның нинди керсез күңелле. Чиста-пакь, уңган булырга тиешлеге өйрәтелә.

Әхлаклылык, әдәплелек сыйфатлары да укучыларга түбән сыйныфларда ук өйрәтелергә тиеш. Әхлак-ул кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган сыйфат. Кешелек җәмгыятендә борын-борын заман нардан ук кешеләрнең үзара аралашу, үз-үзләрен тоту кагыйдәләре булдырылган.

Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәрендә әхлаклылык, әдәплелек кебек гасырлар буена халкыбызның күңелендә булган, төп тәрбия кануны саналган сыйфатларның югалу куркынычы астында торуы күрсәтелә. Без, әлбәттә, яшь буынга милли яшәү кагыйдәләребезне

өйрәтүдә әдәби әсәрләрне генә кулланып кала алмыйбыз. Аларга күргәзмәлелек тә оештырыла. Бу эштә, аеруча, милли бәйрәмнәрне зурлап билгеләп үтү, гореф-гадәтләрне, традицияләрне, йолаларны оештыру олы нәтиҗәгә ирешергә ярдәм итә.

“Нәүрүз”, “Нардуган” бәйрәмнәре үткәрүебез – моның ачык мисалы. Бу бәйрәмнәр турында укучыларыбызга тулырак мәгълүматлар бирү, бәйрәмне, чын мәгънәсендә, бәйрәмчә рухта бөтен мәктәп югарылыгында түткәрү, бу бәйрәмнәрдә үтәлергә тиеш йолаларны башкарубезнең бурычыбыз булып кала.

Татар халкы борын-борыннан моңлы. Җыр сөючән халык булган. Моңланып кайгысын тараткан, шатлыгын уртаклашкан, моң аша хисләрен белдергән. Шушы милли моңны балалар күңеленә кече яшьтән үк сеңдерү безнең өстә. Татар җырларын өйрәтү– әдәбият укытучысының бурычы, чөнки аларны бездән башка бер кеше дә өйрәтмәячәк. Мин үзем бәйрәм саен укучыларга, шул бәйрәмгә багышланган татарча бер җыр өйрәтергә тырышам.

Яшь буынны милли рухта тәрбияләүдә эчке дөньябыз, күңелебез генә үсәргә тиеш түгел, әхалкыбызның күңел бизәкләре саналган, горурлыгы булган митлли киемнәрен өйрәнү, аларны торгызу, камзул, түбәтәй, алъяпкыч –яулыкларны, чигәргә, тегәргә өйрәнүгә нигез салырга кирәк, минемчә. Бу эш тәэсирендә балалар, беренчедән, матурлыкны танырга, күрә белергә өйрәнсәләр, икенчедән, милли киемнәрнең тарихы белән танышырлар, ахыр чиктә шул киемнәрне киеп карау теләге туар иде.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: әгәр бала кечкенәдән үк милли рухта тәрбияләнә икән, татар халкының киләчәге дә өметле булачак.

# МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ МӘШҺҮР КЫЗЫ: МӨХЛИСӘ БУБЫЙ

***Габделвәлиева Лиана Ирек кызы***
*Казан федераль (Идел буе) университетының Алабуга институты*
*Татар һәм чагыштырма филология факультетының 2 курс студенты*
*Җитәкчесе:Мөхәмәтҗанова Айгөл Хәбибҗан кызы.*

Халкыбызның күпгасырлы тарихы шанлы да, аянычлы да. 16 нчы гасырда татар халкының дәүләтләре белән бергә бай рухи-мәдәни мирасының да күп өлеше эзсез югала, зыялылар юкка чыгарыла, милләт үсеше тоткарлана. Тик XVIII гасырның ахырында гына, Екатерина Икенченең Ислам диненә карата булган тыюларны, чикләүләрне җиңеләйткән Указы (1788 ел) чыгып, таш мәчетләр салырга рөхсәт ителгәч, татарларда рухи тормыш җанлана башлый, караңгылыктан чыгып югарыга күтәрелү өмете уяна. Татар зыялылары алга үсеш юлларын эзләүдә яңа баскычка күтәреләләр, яңа фикер туплыйлар, милләт бердәмлеге турында кайгырталар, аның рухи нигезе булган Ислам динен саклау, халыкның аңын үстерү өчен агарту эшенә керешәләр.

XIX йөзнең уртасы һәм икенче яртысында халкыбызда фикер җанланышы күзәтелә, татар дөньясына Шиһабетдин Мәрҗани өр-яңа фикерләр белән килеп керә. Ул дин белән бергә милли аңның татар үсеше өчен зур әһәмиятен аңлап эш итә. Аңа тулысынча фикердәш була алмаса да, Каюм Насыйри да татар үсешенә үзеннән гаять зур өлеш кертә. Исмәгыйль Гаспралы җәмгыять үсеше өчен мәгариф системасын үзгәртеп кору мәсьәләсен күтәреп чыга, җәдитчелек хәрәкәтенә нигез сала. Татар зыялыларының сәяси эшчәнлегендә дә үзгәрешләр хасил була. Россиянең барлык төрки халыклары зыялыларын берләштергән «Иттифак әл-мөслимин” фиркасе тирәсендә, төрле фикердә булуларына карамастан, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Муса Бигиев, Зыя Камали, Садри Максуди, Гаяз Исхакый кебек олпат шәхесләр милли идея тирәсендә берләшәләр.

Яңарыш чорында дини уку йортлары булдыруга, аларны динидөньяви уку йортларына әверелдерүгә аеруча зур әһәмият бирелә. Милләтебез үсеш юлына кергәндә шәкертләргә дөньяви белем бирүне дә максат итеп куйган «Мөхәммәдия” (Казан), Касыймия (Казан)”, «Галия” (Уфа), «Хөсәения” (Троицк), «Буби” (Әгерже), Себердә- «Манҗел” (Төмән) мәдрәсәләреннән татарның үткәндәге иң күренекле шәхесләре белем алып чыкканнар.

Гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, татарларда аң-белемгә игътибар зур булган, халык үзе гыйлемне буыннардан - буыннарга тапшырып килгән, мәчет салса, аның каршында мәдрәсә ачкан, шуңа да патша Русиясендә татар халкы иң гыйлемле халык булып саналган. Әмма мәдрәсәләрдә ир балалар гына белем алган. Үсеш чорына кергәндә татар кызларына системалы белем бирү максаты алга калкып чыга. Хатын-кызның бурычы дөньяга бала китерү белән генә чикләнми, ул аны тәрбияли дә, ә бала тәрбияләүче ана гыйлемле, мәгърифәтле дә булырга тиеш, дигән фикерне күтәреп чыгалар алдынгы карашлы татар зыялылары. Кызларга дини һәм мәдәни белем бирү милләт анасын тәрбияләү бурычына килеп тоташа. Хатын-кызлар өчен уку йортларын татар байлары, зыялылары, дин әһелләре ача, аларга хатыннары, кыз туганнары кушыла, алар арасыннан хатын-кыз лидерлар калкып чыга. Татар хатын-кызлары арасыннан Фәхрелбанәт Сөләйманова, Газизә Самитова, Маһруй Барудия, Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффарияләр, Ләбибә Хөсәенова, Фатиха Аитова, Фатыйма-Фәридә Ваһапова-Нәүрүзова, Мөхлисә Бубый һәм башка бик күпләр милләтебезне мәгърифәтле итү өчен зур эшләр башкаралар, мәгърифәтчеләр рәтенә басалар. Алар арасында Мөхлисә Бубый аерым урын алып тора. Заманында югары үсешкә юл тоткан, кызларга да белем биргән гыйлем учагы буларак танылган «Иж-Бубый" мәдрәсәсе ил тарихында беренче һәм әлегә кадәр бердәнбер казый дәрәҗәсенә лаек булган хатын-кыз исеме белән дә бәйле. Ул – Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсе белән җитәкчелек иткән Мөхлисә Нигъмәтуллина-Бубый. Ул елларда татар кызлары өчен башлангыч уку йортлары ачылган, әмма Аурупа дәрәҗәсендә белем биргән Иж-Бубый мәдрәсә комплексы кысаларында урта белем биреп мөгаллимәләр әзерләгән кызлар мәдрәсәсе Русиядә бердәнбер булган. Бу исем белән бәйле мәдрәсәгә аерым тукталуыбыз очраклы түгел.

Мөхлисә 1869 нчы елда элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостенең Иж-Бубый авылында дөньяга килә. Заманының барлык татар кызлары кебек, башлангыч аң-белемне әнисеннән ала. Әнисе – Уфа губернасының Минзәлә уезды Чебенле авылы имамы һәм мөдәррисе Иманкул-хәзрәт кызы Бәдрелбанәт 1857 нче елда Иж-Бубыйга аның яшь мулласы Габделгаллләм Нигъмәтуллинга кияүгә чыгып килә. Габделгаллләм 1811 нче елда әтисенең бабасы - мулла Габделкәрим Хәлиуллин ачкан, әтисе Нигъмәтулла-хәзрәт үлеменнән соң сүнеп, берничә ел эшләми ябылып торган мәдрәсәне торгыза һәм шунда укыта да.

Мөхлисә Бубый үзенең гомерен динне саклауга, хатын-кызларны балаларын милләт балалары итеп тәрбияләргә сәләтле аналар итеп

тәрбияләүгә багышлаган, алар турында кайгырткан, аларның хокуклары өчен көрәшкән, хатын-кызның илаһи көчкә сәләтле бөек зат икәнен, аның иҗтимагый тормышта үз урыны булырга тиешлеген раслаган. Үзенең кешелек сыйфатлары белән дә халкыбызның иң олы абруен яулаган, рухи камиллеккә ирешкән, үлем җәзасын да имән баганасына таянып горур атлап каршы алган олы шәхес буларак, ул бүген дә татар хатын-кызлары өчен якты үрнәк булып тора.

Мөхлисә Буби (1869-1937) – җәмәгать эшлеклесе, мөгаллимә.

Мөхлисә Буби (1869-1937) – җәмәгать эшлеклесе, мөгаллимә. Ул бертуган абыйлары, аларның хатыннары Нәсимә һәм Хөснифатыйма Нигъмәтуллиналар белән бергә Иж-Бубый авылында хатын-кызлар мәктәбенә нигез салган. Әлеге мәктәп татарларның иң беренче хатын-кызлар гимназиясе була. Иж-Бубый мәдрәсәсен Россиядә генә түгел, ә чит илләрдә дә беләләр. Ул мөселманнарның мәгариф үзәгенә әверелә. Биредә шәкертләр гарәп, төрек, француз, рус телләре, тарих, математика, физика кебек фәннәрне өйрәнә. Ә 1910 елда мәктәптә география һәм химия кабинетлары ачылуы мәгълүм. Мәдрәсәдә Н.Думави, З.Байчурина, Д.Гобәйдулла, Җ.Вәлиди кебек танылган шәхесләр укыган һәм укыткан. Әлеге белем бирү йорты бары тик бай татарлар, купецлар һәм сәнәгатьчеләрнең матди ярдәме белән генә эшләгән. Татар халкының мәгариф һәм тәрбия тармагына Мөхлисә Буби зур өлеш кертте. Ләкин халык аның тормышы, эшчәнлеге турында бик аз белә. Ә бит һәр халык үзенең тарихын һәм тарихи шәхесләрен белергә тиеш. Кем ул Мөхлисә Буби? Кемнәр һәм ни өчен аның мәктәбен ябып, үзен төрмәгә җибәргән?

Без булачак, укытучылар, халкыбызның горурлыгы, татар кызлары өчен беренче мәдрәсә оештыручы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, хатын-кызлардан беренче казый – Мөхлисә Буби турында укучыларыбызга җиткезергә һәм горурлану хисләре тәрбияләргә тиешбез.

# БУБЫЙ УНИВЕРСИТЕТЫ ПРОФЕССОРЛАРЫ

***Гәрәева Рида Тәлгать кызы***
*Казан шәһәре*
*ГБМБУ "Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 89 нчы урта гомуми белем мәктәбе"*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Мал туплауны төп максат итеп куйган шушы катлаулы заманда татар халкы милләт булып сакланып калырмы, балаларыбыз милләтебезнең киләчәк язмышын үз кулларына алырлык булып тәрбияләнеп үсеп өлгерерме, рухи-мәдәни кыйммәтләребезне аларга рухи терәк итеп тапшыра алырбызмы?

## Кызларга дини һәм мәдәни белем бирү – бу милләт анасын тәрбияләү

Хатын-кызның бурычы дөньяга бала китерү белән генә чикләнми, ул аны тәрбияли дә, ә бала тәрбияләүче ана гыйлемле, мәгърифәтле дә булырга тиеш, дигән фикерне күтәреп чыгалар татар зыялылары. Хатын-кызлар өчен уку йортларын татар байлары, зыялылары ача, аларга хатыннары, кыз туганнары кушыла, алар арасыннан хатын-кыз лидерлар калкып чыга.

«Татар дөньясын каплап алган калын караңгылык эчендә беренче шәмне күтәреп чыккан Бубыйлар…» Бертуган Нигъмәтуллиннар хезмәтенә тарих шулай бәя бирәчәк. Бубый мәдрәсәсе – аларның нәсел мирасы. Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә тырышлыгы-көче белән бу уку йорты Россия мөселманнарының гыйлем мәркәзенә әверелә. Биредә дин гыйлеме белән беррәттән, дөньяви фәннәр дә укытыла. Бубыйлар укытучы-мөгаллимнәр һәм укытучы-мөгаллимәләр укытып, имтихан кылып, таныклык биреп чыгару хокукы өчен рөхсәт алалар. Гобәйдулла Бубый Истамбул каласында укый. Ул төрек галимнәре, Каһирә профессорлары белән таныша, Америка көллиятләренең укыту системаларын өйрәнә. Туган авылына әйләнеп кайтуга, Гобәйдулла Иж-Бубый мәдрәсәсендә укытуны яңача (җәдид) ысул белән үзгәртеп коруга алына. Ул мәдрәсәдә география, фәлсәфә, мантыйк фәннәрен, төрек грамматикасын, француз, гарәп телләрен яңача укыта башласа, Габдулла химия, алгебра, физика буенча сабак бирә. Ике бертуган да мөселман мәдрәсәләре өчен яңа дәреслекләр яза.

**Мөхлисә Бубый. Дингә һәм милләткә бирелгән гомер.**

Мөхлисә Бубый абыйларының хатыннары белән бергә Иж-Бубый мәдрәсәсендә кызлар укыта. Аны «мулла-абыстай» дип йөртә башлыйлар. Ул галим, мөселман хокуклары белгече, теолог буларак та абруй казана.

1907 елда мәдрәсә хатын-кызлар өчен махсус гимназия итеп үзгәртелә. 1907 елда анда шәкертләр театры эшләргә тотына...Ә 1911 елда Иж Бубый мәдрәсәсен ябалар, мөгаллимнәрен кулга алалар. 1912 елда кызлар мәктәбендә дә укулар туктатыла. Мөхлисә Троицк шәһәрендә кызлар башлангыч мәктәбенә укытучы булып китә.

1917 елда Мөхлисә Бубый Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының I съездында Мөселман дини идарәсе әгъзасы һәм казый итеп сайлана. Аның гаделлеге һәм намуслылыгы хакында халыкта риваятьләр туа. Ислам дине тарихында казый дәрәҗәсенә ия булган бердәнбер хатын-кыз Мөхлисә Бубый 1937 елда революциягә каршы милләтчел эшчәнлек алып баруда, чит ил разведкасы белән элемтә тотуда гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителә. Шул ук елда ул атып үтерелә. 1960 елның 23 маенда, җинаять составы булмау сәбәпле, Мөхлисә Бубый аклана.

Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында Р.Зәйдулланың «Үлеп яратты» спектаклен караганнан соң туган фикерләр.

**Ркаил Зәйдулла үзенең әсәре турында**

Мөхлисә Бубый турында күптән язарга җыенып йөри идем. Бүген без милләтенә, диненә соңгы сулышына кадәр тугры калган татар хатын-кызы образына сусадык. Чөнки яшерен-батырын түгел, хәзерге татар хатын-кызларының күбесендә нигилизм, меркантильлек сизелә.

Ана теле дибез без, ләкин телебезне ана теле дип атарга кайчагында тел дә әйләнми._Укыту мәсьәләсендә татар теле нигә кирәк ул, ындыр артына чыгу белән аның әһәмияте бетә, дип әйтүчеләрнең күбесе хатын-кызлар бит. Ничек кенә карама, баласын, оныкларын милли рухта тәрбияләү хатын-кыз җилкәсенә йөкләнгән.. Шуңа күрә Мөхлисә Бубый турындагы пьесаны хатын-кызларга гыйбрәт өчен яздым.

**Нәтиҗә.**

Кызларга дини һәм мәдәни белем бирү -милләт анасын тәрбияләү –бу барыбызның да изге бурычы. Милләтне милләт итеп саклап калу үз актуальлеген бүгенге көндә дә югалтмый. Дәресләрдә, класстан тыш чаралар аша мәктәпләрдә бу эшне дәвам итергә кирәк. Ата-аналар җыелышларында да чыгыш ясаулар бик урынлы булыр.

Мөхлисә Бубый үзенең гомерен динне саклауга, хатын-кызларны балаларын милләт балалары итеп тәрбияләргә сәләтле аналар итеп тәрбияләүгә багышлаган, аларның хокуклары өчен көрәшкән, хатын-кызның илаһи көчкә сәләтле бөек зат икәнен, аның иҗтимагый тормышта үз урыны булырга тиешлеген раслаган.

Ул бүген дә татар хатын-кызлары өчен якты үрнәк булып тора, аның якты истәлеге милләт мәнфәгатьләре өчен хәрәкәт итәргә чакыра.

Ни өчен “Бубый университеты профессорлары” дип атадым эшемне?

1. Бу уку йортының даны Рәсәйдә, Европа һәм Урта Азия якларына да тарала.

2. Иж-Бубый мәдрәсәсе үзенең шәкерт-укучылары белән дан казана.

3. Анда югары белемле, әхлаклы, милләтпәрвәр мөгаллимнәр яңача укыталар. Мөгаллим һәм мөгаллимәләр әзерлиләр.

Нигмәтуллин-Бубыйлар тормышында безнең халкыбызның тарихы чагыла, аның авыр вакытларында да алар милләт турында уйлаганнар, аның мәгърифәтле, гыйлемле булуын теләгәннәр.

Хәзер халкыбыз белемле, тормышыбыз да яхшы, тик ни өчен үз туган телебездән йөз чөерәбез, ни өчен үз милләтебезгә тугъры түгелбез? Барысы да үзебездән генә тора бит.

## ҺӨНӘРЕМ – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМ

***Гарипова Гөлсинә Зөлфәр кызы,***
*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе, башлангыч сыйныф укытучысы*

Хәзерге заман укытучысы нинди булырга тиеш соң? Билгеле инде, төп профессиональ белемең, бала шәхесен яратуың, сиңа барлык авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Бала шәхесен чын күңеленнән яраткан һәм хөрмәт иткән укытучы аларны үз балалары кебек бертигез якын күрә, барысына да төпле белем һәм тәрбия бирергә тырыша.

Белем һәм тәрбия бирүнең төп нигезе башлангыч сыйныфларда салына. Иң беренче чиратта укыту методикасын үзләштерү өчен укытучыга педагогия көллиятен тәмамлау кирәктер. Шулай ук укытучы махсус профессиональ белеме белән генә чикләнеп калмыйча үз белемен тагын да камилләштерү өчен югары белемле дә булырга тиеш. Чөнки укыту мето-

дикасын яхшы үзләштерү белән беррәттән, укучылар, тирән белемле булган очракта гына укытучылар, ата-аналар арасында дәрәҗәле шәхес була ала. Икенчедән, сыйныфта төрле үсешкә ия булган балалар да утыра. Аларның һәркайсына аерым шәхси якын килү сорала. Бу очракта укытучыга яңа эш алымнарын һәм формаларын эзләргә, өйрәнергә туры килә. Моның өчен ул үзенең осталыгын даими камилләштереп торырга тиеш була. Хәзерге вакытта укытучыга үз белемен күтәрүдә укытучыларның квалификациясен күтәрү буенча югары уку йортлары ярдәмгә килә. Бары тик бу мөмкинчелекләрдән тиешле дәрәҗәдә файдаланырга гына кирәк...

36 еллык гомеремне башлангыч сыйныфларда белем һәм тәрбия бирүгә багышладым. Башлангыч сыйныфларда укыганда ук укытучы булу теләге зур иде. Хыялым мине, сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Арча педагогия көллиятенә илтте. Махсус уку йортыннан башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрен уңышлы гына үзләштереп, Теләче районы Күкчә башлангыч мәктәбенә мөдир һәм башлангыч сыйныф укытучысы итеп билгеләндем. Нәниләрне ихлас күңелдән ярату, аларга тиешле белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә белемемне тагын да камилләштерү максатыннан Алабуга педагогия институтының “Башлангыч белем бирү педагогикасы һәм методикасы” факультетын читтән торып укып тәмамладым. 1982 елны педагогик эшчәнлегем Саба районы мәгариф бүлеге тарафыннан югары бәяләнде һәм район Мактау тактасына тәкъдим ителдем.

1987 елдан педагогик эшчәнлегемне Кече Кибәхуҗа урта мәктәбендә дә башлангыч сыйныф укытучысы буларак дәвам итәргә туры килде. Теләче районы аерылып чыгып, яңадан оешканнан соң, яңа берләшмә булып эшли башлаганнан бирле, район мәгариф бүлеге каршында башлангыч сыйныф укытучылары өчен оештырылган методик берләшмә җитәкчесе һәм район аттестация комиссиясе члены вазыйфасын да намус белән башкарырга тырыштым. Мәгариф хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен тестлар төзү буенча Беренче Республика конкурсында катнаштым һәм ТР мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хатына лаек булдым.

Төрле үсешкә ия булган һәр балага шәхес итеп карадым. Аларның һәрберсен сау-сәламәт, тәрбияле һәм төпле белемле итү мине тагын да эзләнергә, белемемне камилләштерергә мәҗбүр итте. Яшел Үзән шәһәре методик кабинеты каршында В.Н. Зайцев тарафыннан башлангыч сыйныф укытучылары өчен оештырылган курсларда укуда булып, Зайцев методикасын үзләштердем. Эшемдә бу методиканы кулланып, югары нәтиҗәләргә ирештем. Шул методикага нигезләнеп, ”Дөрес язуны камилләштерү” темасына авторлык кулланмасы төзедем. Зайцев мето-

дикасы буенча район укытучылары арасында эш тәҗрибәм белән уртаклаштым.

Үземнең эш тәҗрибәмне “Теләче” һәм “Мәгърифәт” газеталарында, шулай ук “Мәгариф” журналларында яктыртып барырга тырыштым. Һәрбер үткәрелгән профессиональ конкурсларда актив катнаштым һәм призлы урыннарга лаек булдым.

Ирешелгән уңышлар гына мине канәгатьләндерми иде. Чөнки авыл балаларын шәхес итеп тәрбияләү мәсьәләсе һаман актуаль булып кала бирде һәм бу мәсьәләне чишүдә оптимальрәк юлны эзләү бурычы килеп туды.

Информацион-компьютер технологиясен дәресләрдә куллану да уңай нәтиҗәләр бирде. Дәресләрдә тестлар куллану, мультимедиа программасында эшләү, үзең төзегән презентацияләрне кулланып, башлангыч сыйныфларда белем һәм тәрбия бирүдә югары нәтиҗәләргә ирешү мөмкин икәнлеген аңладым. Ләкин азкомплектлы авыл мәктәпләренең 1 сыйныфына төрле үсешкә ия булган балалар укырга киләләр. Бу бик күп сәбәпләргә бәйләнгән:

– **баланың сәламәтлегенә** (кайбер балаларның организмы ныгып бетмәгән була, кайберләре хроник авырулар белән җәфа чигә);

– **баланың иртә өлгерү үзенчәлекләренә;**

– **эчке гаилә мөнәсәбәтләренең характерына**;

– **гаиләдәге тәрбия шартларына** (балага гаиләдә игътибар җитми, шуңа күрә танып – белү эшчәнлегендә һәм сөйләм үсешендә кимчелекләрне күзәтергә була).

Шуңа күрә төрле үсешкә ия булган укучыларда белем алуны һәм мәктәп тормышына ияләшүне булдыру, аларга белем һәм күнекмәләр бирү вакытында туган каршылыкларны бетерү, һәр укучыда танып-белү эшчәнлегенә карата кызыксыну тәрбияләү максатыннан, мин 2006 – 2007 уку елыннан башлап, “Укучыларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклап, Ә. З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе буенча белем бирүнең сыйфатын яхшырту” темасы өстендә эшләүне кирәк дип санадым.

Эшчәнлекнең темпларын тизләтү укучыга уңышларга тизрәк ирешергә ярдәм итә. Монда уку, язу, исәпләү күнекмәләре формалаштыру бик әһәмиятле. В.Н. Зайцевның “Белем бирү системасында тизләтү әйләнмәсе” курсын тыңлап, аңлы уку, язу, исәпләү темпы турында тирән уйландым. Уку тизлеге белән аңлы уку тизлеге төшенчәсен В.Н. Зайцев киң мәгънәсендә ачып бирә алды. Әлбәттә уку тизлеген тиешле дәрәҗәгә җиткерә алмасак, укучының иҗади үсеше турында сүз алып бару мөмкин дә түгел.

Д.Эльконин һәм В.Давыдов та, тиз укый һәм дөрес яза торган балалар тәрбияләргә кирәк, дип саный. Алар моның өчен кешенең фонематик

ишетүе камилләшкән булырга тиеш икәнлегенә басым ясый. Шуңа күрә дә мин укучыларымда белем алуга карата кызыксыну уяту, аларны толерантлы шәхес итеп тәрбияләү максатыннан, Д.В.Эльконин-В.В.Давыдов системасына нигезләнеп төзелгән, академик Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясенә игътибарымны юнәлттем. Эшемнең беренче этабында Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе буенча педагогик һәм методик әдәбият белән таныштым. 2006 елның 5 июненнән МҮИ да "Мәгарифне модернизацияләү шартларында башлангыч мәктәпнең вариатив модельләре" темасына уздырылган өч атналык курсларда булдым. Анда Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясен һәм А.Яхин методикасын үзләштердем. Балтач районы Салавыч урта мәктәбендә "Укучыларның иҗади үсешендә психологик-педагогик факторлар" темасына үткән республика семинарында катнаштым. Мәгариф" журналларындагы мәкаләләрне, новатор укытучыларның эш тәҗрибәләрен өйрәндем.

Һәр укучының үсеш дәрәҗәсен билгеләү өчен максатчан юнәлешле диагностик эш алып бардым, үсешләрен күзәттем. Шул ук вакытта физик сәламәтлекләренең тотрыклылыгына да ирештем.

Үземнең эш тәҗрибәмне коллегаларыма да җиткерергә тырыштым. Кече Кибәхуҗа урта мәктәбендә «Укучыларның мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белү сәләтләрен үстерүдә индивидуаль һәм төркемдә эшләүнең роле" темасына район күләмендә 4 сыйныф укытучылары өчен семинар оештырылды.

## ГӨЛЗАДӘ ӘХТӘМОВА ИҖАТЫНДА "МӨХЛИСӘ БУБЫЙ" ТЕМАСЫ

***Гыйльфанова Гөлфинур Әсгать кызы***
*Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы*
*"Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге*
*3 нче урта гомуми белем мәктәбе"*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Гөлзадә Әхтәмова иҗатында мәгърифәтчелек темасы киң чагылдырылган. Бу тема аңа бик якын. Гөлзадә апа туган ягының, торган җиренең үткәнен һәм киләчәген яхшы белүче, халкын яратучы, үзенең шигырь-хикәяләре аша мәгърифәтчелек фикерләрен алга сөрүче, укучыларга татар милләтле шәхесләр турында мәгълүмат бирүче һәм яшь буынга милли

тәрбия бирүдә зур көч куючы иҗади шәхес. Ул 40 елдан артык гомерен балалар укытуга багышлаган мөгаллим-шагыйрә.Унбиш китап авторы булган язучының ирешкән уңышлары да бик зур. 2004 елның апрель аенда Гөлзадә Әхтәмова Татарстан язучылар берлегенә кабул ителде. 2011 нче елда, бөек Тукайның 125 еллыгы һәм Гөлзадә апаның 70 яшьлек юбилее уңаеннан, безнең 3нче мәктәп укучылары белән берлектә, "Тукай эзе" китабы басылып чыкты. 2012 нче ел шагыйрә өчен тагын да истәлеклерәк булды. Гөлзадә Әхтәмовага Саҗидә Сөләйманова исемендәге дәүләт премиясе тапшырылды. Язучы бүген дә иҗат эшен дәвам итә. Педагог, җәмгыять эшлеклесе, тарихыбызның легендар хатын-кызы Мөхлисә Бубыйның язмышын, эшчәнлеген өйрәнеп, Гөлзада Әхтәмова аңа багышлап 2011 елда поэма яза. Үз кичерешләре аша Мөхлисә Бубыйны безнең күңелләргә тагын да якынайта, үткән гасырның фаҗигале дә, гыйбрәтле дә булган хәлләрен аңларга ярдәм итә. Мәгърифәтчелекнең барлыкка килүен, аның үсеш юлларын күрсәтә, алда булган киртәләр аша үтә алган мөгаллимәләргә мәхәббәт хисе уята. Шагыйрә Гөлзада Әхтәмова үзе дә тумышы белән Әгерҗе районыннан. Вакыйгаларның күбесе турында китаплардан укып кына түгел, ишетеп тә белә. Ул үз якташын, милләттәшен яратып, сагынып, кайгыларын үз йөрәге аша үткәреп, шул ук вакытта горурланып та яза. Поэма алдыннан кыскача аңлатма бирелә: "XIX гасыр азагы XX гасыр башларында Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында Гобәйдулла белән Габдулла Нигъмәтуллиннар, мәдрәсәдә беренчеләрдән булып, җәдитчәдөньяви белем биреп укыта башлыйлар. Сеңелләре Мөхлисә (1869-1937) хатын-кызларга белем бирә."Поэманың беренче юлларыннан ук ни өчен җәдитчә укытуга күчәргә кирәк булганлыгын аңлыйсың.

*Иж буенда урнашкан Иж-Бубый.*
*Җире бик аз иген игәргә,*
*Иш янына куштай – сәүдә эше*
*Ярдәм итә дөнья көтәргә.*
*Шуңа халкы белә зарурлыгын*
*Уку-язу, хисап, гыйлемнең.*
*Мәдрәсәдә җәдитчә укыту –*
*Иң кулае, ди ул, белемнең.*

Ике гасырга якын эшләп килгән мәдрәсәнең эшен киңәйтеп җибәрергә киңәшләшәләр ике бертуган Гобәйдулла белән Габдулла. Бергәләп татар телендә дәреслекләр төзиләр, шәкертләрне шул китаплардан укыталар. Гобәйдулла Бубыйның физика һәм җәгърәфия буен-

ча төзегән дәреслекләреннән, мәдрәсә ябылгач та, татар мәктәпләрендә озак еллар укыталар. Мәдрәсәнең даны еракларга тарала. Бөтен татар төбәгеннән шәкертләр агыла.

Ләкин менә шушы изге фән учагын җимерергә көчләр табыла, дип, үрсәләнә шагыйрә.

*Әмма*
*Мәгърифәт төбәге дигән исем*
*Бу якларда озак сакланган.*
*Зур шәхесләр аннан үсеп чыгу*
*Гасыр буе үзен аклаган.*

Хатын-кызлардан Зәйнәп Максудова кебек фән эшлеклеләре, Заһирә Байчурина кебек шагыйрәләр укып чыга. Саный китсәң, алар бик күпләр, ди шагыйрә. Алар барсы да Мөхлисә Бубыйны үзләренең остазы дип санныйлар. Бу мәдрәсәдә шул елларда Габдулла Тукайның сөйгән кызы Зәйтүнә Мәүлүдова да белем алып чыга. Аның Иж-Бубый мәдрәсәсендә бирелгән шәһадәтнамәсе сакланган.

Патша хөкүмәте мөселман хатын-кызларына белем бирү турында кайгыртмаган. Татар хатын-кызлары өчен мәктәпләрнең иң беренчесе – Иж-Бубый авылында Мөхлисә Бубый тарафыннан ачыла. Аның өчен, билгеле, Мөхлисә абыстайга бик күп каршылыклар аша үтәргә туры килә. Башта әле хатын-кызларның үзләрен үгетләргә кирәк була. Һәм Мөхлисә беркөн үз теләгенә ирешә. Мәдрәсәгә елдан-ел хатын-кызлар күбрәк йөри башлый. Хәтта сан ягыннан ир-егетләрдән дә артып китәләр. Бу Мөхлисәнең зур гыйлемле, алдынгы карашлы, батыр йөрәкле булуыннандыр.

Шулай эшен бик яратып, чын күңелдән тырышып йөргәндә, кара көчләр башта ирләр мәктәбен, аннан хатын-кызлар мәктәбен дә яптыруга ирешәләр. Мөхлисә Бубый Троицки каласына китеп, кызлар мәктәбенең мөдире һәм мөгаллимәсе булып эшкә урнаша.

Автор Мөхлисә Бубыйның гаилә тормышы турында да әйтмичә булдыра алмый:

*Күпме эзләнсәм дә, синең хакта*
*Һич тапмадым җанга сөенеч.*
*Бәхетем булыр дип, өмет иткән кешең*
*Алып килгән бары көенеч.*
*Интектергән сине –*

*Яратмаган кешең белән яшәү,*
*Җиде ел гаилә газабы.*
*Ике кызың белән качалгансың,*
*Аерылышу булган азагы.*

Мөхлисә Бубый, нинди генә тормыш каршылыклары булуына карамастан, ике кызына да югары белем алырга ярдәм итә, үз канаты астында тәрбияләп үстерә. Бу аның ныклы ихтыяр көче булуын, алдына куйган максатларына ирешә алган чын милләт анасы булуын күрсәтә. Шагыйрә шундый якташы булуы белән горурлана:

*И, Мөхлисә!*
*Якташым дип, горурланып куям,*
*Безгә чит-ят түгел горурлык.*
*Син берүзең гыйлемлегең белән*
*Әллә ничә иргә торырлык.*

1917 елда Мөхлисә Бубыйны Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлап куялар. Казыя булып эшләгән егерме ел эчендә Мөхлисә абыстай гаделлек ягында була, газиз халкы өчен җан атып яши, бигрәк тә ятим балалар, хатын-кызлар бәхете өчен аның тарафыннан “күпме яхшы гамәл кылына.” Нигезсез гаепләнеп, кулга алынган Мөхлисә Бубыйның гомере шулай фаҗигале рәвештә өзелә. Ләкин милләт анасына карата булган халык мәхәббәте йөрәкләрдә сүнми.

Шундый авыр көрәш елларында, иң беренчеләрдән булып, мөселман хатын-кызлары өчен уку йортлары нигезләгән, мөгаллимлек эшләрен үрнәк булырлык итеп алып барган, халыкны тәрбияләү эшендә зур көч куйган Мөхлисә Бубый – олы мактауга лаеклы шәхес. Гөлзада Әхтәмова “Мөхлисә Бубый” исемле поэмасында милләт анасын төрле яктан күрсәтеп, аны халыкка тагын да якынайта, аның үлемсезлеген исбатлый:

*Гыйлемең зурга “мулла-абыстай” булып,*
*Син яшисең халык күңелендә,*
*Үткәннәрнең биек баскычында,*
*Мәңге үлемсезлек күгендә!*

Шагыйрә Гөлзада Әхтәмова бу юлларда бик хаклы рәвештә әйткән. Без, татар мөгаллимәләре, аның бу сүзләренә ихлас күңелдән кушылабыз. Халкыбызның бөек шәхесе – Мөхлисә Бубый исеме алдында баш иябез.

# МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ МӘШҺҮР КЫЗЫ: МӨСЛИХӘ БУБЫЙ

***Исмәгыйлева Гөлнара Таһир кызы***
*"Буа муниципаль районы Зур Фролово төп гомуми белем мәктәбе" МБГБУ югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халкыбызның мәдәнияте тарихында мәдрәсәләр зур урын билиләр. XX гасыр башында халыкны аң-белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту-тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Россиядә дан-шөһрәт казанган татар мәдрәсәләре берничә генә. Алар – Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия», Әгерҗе төбәгендә Иж-Бубый мәдрәсәләре.

Егерменче гасыр башы, Россия. Дөнья ыжгырып милләтебез өстенә килә, бөтен җирдә алгарыш, прогресс, уку, ә Казан капкаларында исә: "Этләргә һәм татарларга керү тыелган", дигән такталар эленеп тора. Ә татарның укыйсы, һөнәрле буласы килә, аның дөнья аяк астында каласы килми. Әмма татарның үзенең дөньяви белем ала торган югары уку йортлары юк. Һәм татарның акыл ияләре, авылда булса да, үзләренең университетларын ачып куялар, дин белән бергә, анда дөньяви белем дә бирә башлыйлар.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең тарихы шактый зур һәм бай. Ул элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж-Бубый авылында 1781 нче елда оештырыла. Башка татар мәдрәсәләре белән беррәттән, ул да XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында зур үзгәрешләр кичерә. 1907 нче елдан башлап, бу уку йортында аерым фәннәр буларак гарәп, фарсы, төрек, рус, француз телләре, тарих, политэкономия, арифметика, геометрия, физика, астрономия, география, ботаника, медицина, психология, педагогика алдынгы рус һәм Европа уку йортлары дәрәҗәсендә укытыла. Фәлсәфә, логика, әхлак, Коръән, хәдис, ислам тарихы өйрәтелә. Укыту расписание буенча алып барыла, дәресләр үткәрү өчен бүлмәләр җиһазландырыла; уку елы ахырында имтиханнар уздырыла.

Бубыйлар, иң беренче чиратта, мәгърифәтчеләр, татар халкына белем орлыклары чәчеп калдырган милли зыялылар. Россиянең төрле почмакларыннан мәдрәсәгә укырга яшьләр килә. 1908-1911 нче елларда биредә һәр елны 500 шәкерт белем ала. Монда һәр атнада әдәби, фәнни кичәләр уздырыла. Мәдрәсәнең бай китапханәсе, махсус җиһазландырылган спорт мәйданчыгы була. Аны тәмамлап чыгучылар тирән фикерле, белемле,

киң мәгълүматлы шәхесләр булып формалаша. Иж-Бубый мәдрәсәсенең уңышларга ирешеп чәчәк ату елларында аның белән бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар җитәкчелек итә. Кечкенә туган авылларында мәктәп оештырып, аны Бохарадагы уку йортлары белән беррәттән торучы белем учагына әверелдерүгә ирешә. Ул – Русия университетлары, академияләре дәрәҗәсенә ия булган беренче татар уку йорты. Бу авылда Россиядәге мөселман хатын-кызлар өчен иң беренче уку йортларыннан кызлар мәдрәсәсе дә эшли. Ул Мөхлисә Бубый карамагында була.

## ДАНЛЫКЛЫ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘР НӘСЕЛЕ

***Миндубаева Нәзирә Хәсән кызы***
*Алексеевск муниципаль районы муниципаль*
*бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Урманасты Шынталысы гомуми урта белем бирү*
*мәктәбетатар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***«Кешегә сәламәт акылны бары тик яхшы***
***нәсел һәм дөрес тәрбия генә бирә”.***
***Габдулла Буби***

19 нчы гасыр ахырында Европа мәдәниятенең тәэсире, капитализм үсү, буржуазия барлыкка килү илдә иҗтимагый тормыш шартларын үзгәртә, прогрессив көчләр барлыкка килә. Халыкның хәлен үзгәртү өчен хәрәкәт башлана. Милләтне алга җибәрү, аң-белемле яшьләр тәрбияләү зарурлыгы туа. Андый яшьләрне тик аң-белемле, мәдәниятле аналар гына тәрбияли алуын аңлап, җәмгыятьнең хатын-кызларны, ягъни булачак аналарны укыту, мәдәниятле итү мәсьәләсе алга куела.

Индира Ганди, Беназир Бхутто 1950 нче елларда гына көрәш аренасына чыксалар, ә татар хатыннары XX гасыр башында ук иҗтимагый эшләр белән актив шөгыльләнә, бу татар халкының алдынгы, прогрессив фикерле белгән милләт булганын күрсәтә. Үзләренең тырышлыклары, уңганлыклары белән мәктәпләр салдырып, татар кызларыннан төрле белгечләр әзерләүгә нигез салган халкыбызның мөхтәрәмә ханымнары Ләбибә Хөсәения,Фатиха Аитовалар янәшәсендә Мөхлисә Буби да тора.

Мөхлисә Буби кем ул, кайдан ул? Аның тормышы һәм үлеме серләре, Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар турында тагын да күбрәк беләсем ки-

леп, мин төрле чыганакларга мөрәҗәгать иттем. Бертуган Бубиларның эшчәнлеген өйрәнгән мөхтәрәм галимнәребез Мөхәммәт Мәһдиев, Альта Мәхмүтова, Раиф Мәрданов, Рәфилә Гыймазоваларның хезмәтләрен барладым.

Һәр кешенең тормышы – үзенә бер тарих. Берәүләрнең ул, үз көенә генә аккан елга кебек, тыныч кына, сиздермичә уза. Ә икенчеләрнеке ярсу тау елгасына охшаган: юлында очраган вак-төяк нәрсәгә игътибар итмичә, каядыр ашкына, гел алга омтыла. Мөхлисә, Гобәйдулла һәм Габдулла Нигъмәтуллиннар – татар тарихында әнә шул тау елгасы төсле көчле, кырыс, җиңелмәс көрәшче һәм бөек шәхес буларак урын алган кешеләр.

Алар заманы өчен белемле, алдынгы карашлы Бәдрелбанат абыстай белән Габделгалләм хәзрәт Нигъмәтуллиннар гаиләсендә дөньяга киләләр. Башлангыч белемне дә аларга шул заманда ук гарәп, фарсы телләрен дә җитәрлек дәрәҗәдә белгән әниләре бирә. Белүебезчә, 18 яшендә Мөхлисәне Минзәлә өязендеге бер хәзрәткә кияүгә бирәләр. Ирнең яшь кәләштән күпкә өлкән, инде ике хатынын җирләп өлгергән кара фикерле, бозык холыклы адәм икәнлеге соңрак – никахтан соң гына мәгълүм була. Әти-әнисе кебек дус-тату гаилә корып, бергәләп балалар укытып, киңәш-табыш итеп яшәүне күз алдында тоткан Мөхлисәнең өметләре акланмый. Ир аны аңларга теләми, балалар укытуны кирәк эшкә санамый. Шулай 7 ел ни эшләргә белми газапланган Мөхлисә бәби тапканда вафат булган асрауның ятимә кызы Нажияне тәрбиягә ала. Бер елдан соң үзе дә ана булу бәхетенә ирешә, кызы Мөнҗия дөньяга килә. Иреннән киткәч, Мөхлисә абыйларының хатыннары белән бергә Иж-Буби мәдрәсәсендә кызлар укыта башлый.

Мөхлисә, Гобәйдулла һәм Габдулла Нигъмәтуллиннар – заманында гыйлем дөньясының зур мәгърифәт учагы булган Әгерҗе төбәгендәге Иж-Бубый мәдрәсәсен шаулатып яшәткән мөгаллимнәр. Гобәйдулла Буби Төркиягә китеп, Истанбул университетының табигать фәннәре факультетын тәмамлый. Сорбонна шәһәренең күренекле Паскаль лабораториясендә практика үтә.

Гобәйдулла төгәл фәннәр – физика, география, француз телен укыта. Габдулла исә дин тарихы, фәлсәфә, мантыйктан белем бирә. Укыту эшләре белән шөгыльләнеп кенә калмыйча, алар дәреслекләр дә төзиләр. Мәдрәсәдә заманча фәннәр укыту аның дәрәҗәсен нык күтәрә.

1905-1907 елгы революциядән соң Столыпин реакциясе шартларында янә авыр көннәр башлана. 1911 елда Иж-Буби мәдрәсәсе ябыла, 1912 елда кызлар мәктәбендә дә укулар туктатыла. Мөхлисә Троицки

шәһәренә кызлар башлангыч мәктәбенә укытучы булып китә. Мөгаллимә-галимәнең шөһрәте еракларга тарала. 1917 елның маенда Мәскәү каласында, Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда Мөхлисә ханымны Уфа шәһәренә караган мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлыйлар һәм 20 ел дәвамында вазифасында калдырыла. Аның гаделлеге һәм намуслылыгы хакында халык арасында риваятьләр тарала.

Оештыру, уку-укыту эшләре, халыкны тәрбияләү эше белән шөгыльләнгән галимәбезнең, 1937 елда гаепсезгә кулга алынып, гомере төрмәдә өзелә. Атна дәвамында җәзалап, аңардан допрос алалар. 30 ноябрьдә хөкем чыгарыла. 10 декабрьдә 68 яшьлек Мөхлисә Бубины Уфаның төрмәсендә атып үтерәләр. “Халык дошманы” дигән яла ягыла.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Ркаил Зәйдулланың «Яңа татар пьесасы» – 2010 конкурсында Мәдәният министрлыгының махсус премиясенә лаек булган «Үлеп яратты» дип исемләнгән пьесасын сәхнәләштерде. Халкыбыз, ниһаять, тамырларына, милли үзаңына һәм иманына кире кайткан бу чорда үз туган телендә гомуми һәм дини белем алуга мохтаҗ. Нәкъ шушы, бүгенге көн өчен әһәмиятле мәсьәлә Ркаил Зәйдулла иҗат иткән “Үлеп яратты” пьесасының төп идеясен тәшкил итә. Татар театрында, ниһаять, тарихи шәхес турында пьеса сәхнәләштерелде. Бу театрның мөһим һәм мактауга лаек адымы. Көчле шәхесләр халыкка символ буларак кирәк.

Минем уйлавымча, тарихыбызның легендар хатын-кызы Мөхлисә Буби язмышына сәнгать һәм каләм әһелләренең мөрәҗәгать итүе – милләтебез һәм динебез өчен зур алгарыш. Мөхлисә Бубиның татар хатын-кызларына үрнәк булырлык шәхес булуын белдерде. Әлеге олуг затларыбыз салган иманлы юлны, рухи ныклык үрнәген без дә, киләсе буыннар да лаеклы рәвештә дәвам итсә иде дигән теләктә калам мин. Татар галимнәренең башларын югары тотып, үз милләтләренә хезмәт итүләрен, татар халкын күтәрүләрен телим, чөнки милләт күтәрелсә, алар да югарыда булыр, һәм галимнәр ярдәмендә татарларны дөнья өр-яңадан ачачак әле, иншаллаһ! Үткәнебезгә битараф булмасак иде. Үткәнен онытканның киләчәге юк диләр бит.

# МӨХЛИСӘ БУБЫЙ – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘГАРИФЕН ҮСТЕРҮГӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ГАЛИМ-ПЕДАГОГ

***Мостаева Венера Марсел кызы,***
*Алабуга муниципаль районы*
*“2 нче гимназия” белем бирү учреждениясе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Әлеге хезмәттә без аерым игътибарны Мөхлисә Бубыйга багышларга теләдек. Ни өчен? Чөнки халкына мәгърифәт нурларын таратучы, дөреслекне-яңалыкны алга сөрүче, хаким итүче властьтан курыкмаучы ханымның фаҗигале тормыш юлын өйрәнү – мөһим һәм хөрмәткә лаек эш ул.

Мөхлисә Буби 1869 елда Вятка губернасы, Сарапул өязе, Әгерҗе волостендагы Иж-Бубый авылында хәлле крестьян гаиләсендә туа. Гаиләдә алар өчәү була: Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә. Әтиләренең исеме – Габделгалләм, әниләренең – Бәдрелбанат. Габделгалләм һәм Бәдрелбанат Нигъматуллалар үз заманасының укымышлы кешеләре булалар. Алар, татар теленнән тыш гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы беләләр. Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә дөньяви фәннәрдән һәм төрле телләрдән нигезле гыйлем-мәгълүмат алалар.

Мөхлисә бик яшьли бер имамга кияүгә чыга. Кызы Мөнҗия тугач, Мөхлисә иреннән аерылып кайта. Иж-Бубида энеләре укыткан һәм җитәкчелек иткән мәдрәсәдә кызлар сыйныфлары ачып, мөдирә була. Монда ул төрле фәннәрдән укыта башлый. Шуны да әйтергә кирәк, Иж-буби мәдрәсәсе укыту-күрсәтмә әсбаплар һәм башка кирәк-яраклар белән әйбәт җиһазлаган була. Н. Меньшиков исемле инспектор үзенең отчетында болай дип яза: “...Ижбайкинское, например, медресе, благоустроенное, однако, по обоей постановке медресе “Ижбобие” стоит значительно выше, почему учителя русско-татарских школ сравнивают его с магометанской академией.” (1904)

Мөхлисә абыстай мәктәбендә рус теле, татар теле-әдәбияты, арифметика, география, тарих, табигать белеме, рәсем, матур язу һәм ислам дине сабагы укытыла. Үз вакытында алдынгы уку йорты исәпләнгән бу мәдрәсәдә Себердән, Зайсаннан, Ташкенттан, Пржевальскидан, Пишпәктән һәм башка ерак җирләрдән килеп укучы хатын-кызлар күп була. Татар мәгариф тарихында эз калдырган РСФСР мәктәпләренең атказанган укытучысы Сара ханым Габбасия, Казан шәһәреннән Мәрьям

ханым Зәйнетдин, Зәйнәб Максудия, мәшһәр мәгърифәтче, татар басма язуы өчен күп хезмәтләр күрсәткән, дәреслекләр язып калдырган Мөхәммәд әфәнде Идрисинең кызы – Рабига ханым Идриси һәм башкалар Мөхлисә абыстайдан тәрбия, гыйлем эстәгәннәр.

Үз кызы Мөнҗия белән бер яшьлек ятимә кызны (Наҗияне), күз карасыдай асрап үстерә, икесенә дә югары белем мәгълүмат алырга ярдәм итә.

1910-1911 нче елларда патша хакимиятләре татар җәдит мәктәпмәдрәсәләрен аяусыз рәвештә яптыралар. 1912 нче елның 21 гыйнварендә Бубый мәдрәсәсе дә тар-мар ителә. Шушы фаҗигале хәлләрдән соң, 1911 елда ук, Мөхлисә ханым Троицкий шәһәрендә (хәзерге Чиләбе өлкәсендә) Габделвәли (мәшһүр Ф. Аит, атаклы скрипач Мөхәммәд Яушның әтисе) Яуш варислыгында хезмәт итүче Габдрахман Әхмәр ачкан кызлар урта мәктәбендә укыта башлый. Төрле фәннәрдән сабакдәрес бирә. Соңыннан бу мәктәп Яушевлар исеменә күчә. Мөгаллимәгалимә Мөхлисә Бубыйның шөһрәте бөтен киң Русиягә тарала.

Олуг галимебез Ризаэддин бине Фәхреддин җитәкчелегендә, хатынкызлар арасында, зур оештыру, аңлату эшләре алып бара. Җаны-тәне белән халыкка тәрбия бирү диңгезенә чума, ул вакытта (1924-1927 елларда) Уфада нәшер ителгән “Ислам мәҗәлләсе” битләрендә мәкаләләрен бастыра, тәгълим-тәрбия өлкәсендә Фәхрелбанат Сөләймания (казый Габдулла Сөләйманиның әнисе), Гайшә абыстай (Җиһангир Абызгилдинның хатыны), Багбостан ханым, Ләбибә Хөсәен, Фатыйма Аитларның уңай тәҗрибәләрен дәвам иттерә. 1917 елның маенда, Мәскәү каласында, Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда Мөхлисә ханымны Уфа шәһәрендә җирләшкән мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлыйлар.

1917 нче елдан Уфада эшли, Диния нәзарәтенең гаилә эшләре бүлеге белән җитәкчелек итә, метрика кенәгәләрен тутыру, гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу, ислам диненә дәгъватлау һ.б. эшләр белән шөгыльләнә. Буби шулай ук хатын-кызлар арасында мәгърифәтчелек эшчәнлеге алып бара, «Өлфәт», «Әхбар», «Вакыт» газеталарында, «Сөембикә», «Ислам мәҗлесе» журналларына мәкаләләр яза. Ислам тарихында беренче һәм иң соңгы бердәнбер казыя-хатын була.

Шәхес шөһрәте чорында, 1937 елның 20 ноябрендә “Башкортстандагы контрреволюцион буржуаз милләтчел оешма әгъзасы” булуын күрсәткән яшерен белешмә нигезендә, революциягә каршы милләтчел эшчәнлек алып баруда, чит ил разведкасы белән элемтә тотуда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итәләр. 1937 елнын, 23 декабрендә 68 яшьлек

Мөхлисә Бубыйга чыгарылган хөкем карары җиренә җиткерелә. 1960 елның 23 маенда аның гаепсез икәне раслана.

Бүгенге көндә дә Мөхлисә Бубый тормыш юлын өйрәнү актуаль булып кала. Ркаил Зәйдулла аңа багышлап пьеса яза. Бу пьесага режиссер Илгиз Зәйни Галиәсгар Камал театрында спектакль куя. Шагыйрьләр исә шигырьләрендә Мөхлисә Бубыйны зурлап-хөрмәтләп искә алалар.

Хезмәтебезне Сания Әхмәтҗанованың шигыре белән тәмамлыйсы килә.

*Гыйлем таҗы*
*Изелгән, асылган, киселгән,*
*Тапталган, иленнән сөрелгән,*
*Йолкынган, тамыры өзелгән,*
*Хәл җыеп, яңадан терелгән.*
*Тернәкле орлыктан үрчегән,*
*Очкыннан кабынып дөрләгән.*
*Дым-шифа эзләгән тирәннән,*
*Түбәннән югары үрләгән.*
*Яраткан, җылыткан, бүлешкән.*
*Үз-үзен аямый көрәшкән...*
*Гыйлемле туташлар, ханымнар*
*Халкыма мәгърифәт өләшкән.*

## "ХЕЗМӘТКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР"

*( Мөхлисә Бубиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге буенча фәнни-тикшеренү эше)*

**_Мөбарәкшина Энҗе Мулланур кызы_**
*Апас муниципаль районы МБГБУ "Азбаба урта гомуми белем бирү мәктәбе" татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Тән азыгы-икмәк, җан азыгы – гыйлем һәм мәгърифәт.***
***Халык мәкале***

Мәгърифәт – аң-белем, культура дигән сүз. Мәгърифәтче – галим, гыйлем иясе дигәнне аңлата. Татар халкында белемгә омтылыш, аңа хөрмәт, укымышлы кешеләрне олылау борынгыдан килгән матур гадәт. Безнең төрки бабаларыбыз инде алтынчы гасырда ук укый-яза белгәннәр.

Идел буе Болгар дәүләтенең чәчәк ату чорында уку-укыту эшенә аеруча да зур игътибар бирелгән. Мөселманнарның һәр мәчете каршында мәдрәсә булуы мәгълүм. Билгеле булганча, мәдрәсәләрнең төп юнәлеше – дини белем бирү. Әмма халкыбызның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә нигез салу да шуннан башланган. Дөрес, мәдрәсәләрдә белем алу тормыш итүгә яраксыз, мәгънәсез дини сүзләр ятлауга кайтып калган кебек фикерләр бүгенге көнгәчә яшәп килә. Әмма, минем уйлавымча, мәдрәсәнең шәкертләргә гарәп телен өйрәнергә, хәтерләү сәләтен арттырырга, җаваплылык, түземлелек сыман уңай сыйфатларын үстерергә ярдәм итүен дә әйтмичә калу мөмкин түгел. Халыкны аң-белемле, тәрбияле итүгә зур өлеш керткән күп кенә татар мәгърифәтчеләре белем алуны шушы мәдрәсәләрдә башлап җибәрә. Әлеге шәхесләр, үз чиратында, халыкка дөньяви фәннәр өйрәтү зарурлыгын яхшы аңлый, кешеләрне яшәү өчен кирәкле мәгълүматлар белән коралландырып, һөнәр өйрәтеп, татар җәмгыятен уңай якка үзгәртеп коруны максат итеп куя.

XIX йөзнең уртасы һәм икенче яртысы халкыбызга яңа фикри юллар ача. Нәкъ менә шушы чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте өлкәсендә зур борылыш булып тора. Татар милли мәгарифен алга җибәрергә, кешеләрнең аңын үстереп, горурлыгын уятып, татар халкының югалткан дәүләтчелеген торгызырга омтылган милли хәрәкәт барлыкка килә. Мәгърифәтчеләр эшчәнлеге һәм иҗаты нәтиҗәсендә татар иҗтимагый фикерендә тәнкыйди башлангычка нигез салына, кешеләрнең дөньяга карашын урта гасыр фанатиклыгыннан азат итүдә мөһим адым ясала. Мәгърифәт йолдызлыгында аеруча якты балкыган шәхесләр исемлегенә без Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗәни,Хөсәен Фәезханов,Ризаэддин Фәхреддин, Шәмсетдин Күлтәси, Габденнасыйр Курсави кебек татар зыялыларын кертә алабыз. Татар мәгърифәтчеләре арасында Мөхлисә Буби аерым урын алып тора,чөнки ул үзенең гаҗәеп авыр һәм якты тормышы белән башкалардан аерыла.Ислам дөньясында ул бердәнбер татар хатыны-казый була. Халыкта аны «мулла-абыстай» дип йөртәләр. Мөхлисә Бубиның эшчәнлеге мәктәп программасында әдәбият дәресләрендә өйрәнелми,шуңа күрә дә аның тормышы,язмышы миндә зур кызыксыну уятты.

# ХАТЫН-КЫЗГА, ГЫЙЛЕМ ТАҖЫ КИЕП, ҮЗ ИРЕГЕН ДАУЛАП АЛУ КИРӘК!..

***Мөхәммәтшина Гөлфинә Шәйхетдин кызы***
*Казан шәһәре ГБМБУ "71 нче мәктәп"*
*татар теле һәм әдәбият укытучысы*

Сайлаган **теманың актуальлеге**. Халкыбызның күренекле, бөек, үзаңлы мәгърифәтче кызларның тормышы һәм кабатланмас эшләре турында хәзергә аз язылды, аз өйрәнелде. Әдәбият белгечләребез һаман да аларның биографияләренең ачыкланып бетмәгән фактларын тикшерәләр, истәлекләрен барлыйлар. Мин дә үземчә шул сорауларга җавап эзләү эшенә алындым.

Төп **максатым** – мәгърифәтче кызларның тормышы һәм кабатланмас эшләре турында күзаллау булдыру һәм шул файдалы мирасны укыту-тәрбия процессында куллану.Милли үзаңлы хатын-кызларыбызның шул чордаүз-үзләрен камилләштерү юлында башкаларны да үзләре артыннан ияртә алу сәләтләрен бәяләү. Хезмәтебезнең **тикшерү объекты** – шәхси тормышлары, ә **тикшерү предметы**– шул чорда мәгарифнең торышы

**Кулланылган чыганаклар.**

Эш барышында төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде.

Эшнең **структурасы.**

Фәнни эшем кереш, төп өлештән, йомгаклаудан, әдәбият исемлегеннән һәм кушымтадан (презентация) тора.

Максатымны тормышка ашыру өчен эшемнең **бурычлары**:

– Мәгърифәтче татар хатын-кызларын һәм алар турындагы истәлекләрне барлау, чыганаклар туплау.

– Мәгърифәтче татар хатын-кызларының мәгарифкә керткән өлешен өйрәнү.

Афәтле тарих юлларын узганда милләтебезне ана теле, Ислам дине, асыл гореф-гадәтләребез саклап килгән. Бүгенге глобализация чорында милләтне милләт итеп саклап калу мәсьәләсе яңадан актуаль төс ала. Мал туплауны төп максат итеп куйган шушы катлаулы заманда татар халкы милләт булып сакланып калырмы, балаларыбыз милләтебезнең киләчәк язмышын үз кулларына алырлык булып тәрбияләнеп үсеп өлгерерме, рухи-мәдәни кыйммәтләребезне аларга рухи терәк итеп тапшыра алырбызмы, дигән уйлар күпләрнең күңелен борчый торгандыр. Мондый уйлар исә хатын-кыз, ана төшенчәләренә барып тоташа, чөнки балаларны югары әхлаклы, иманлы кешеләр, милләт балалары итеп

тәрбияләүдә төп роль хатын-кыз җилкәсенә төшә, иманлылык хисен күкрәк сөте белән ул гына сеңдерә, ул гына туган телле итеп үстерә ала газиз баласын.

Мәгрифәтче хатын-кызларыбыз үзләренең гомерен динне саклауга, хатын-кызларны балаларын милләт балалары итеп тәрбияләргә сәләтле аналар итеп тәрбияләүгә багышлаган, алар турында кайгырткан, аларның хокуклары өчен көрәшкән, хатын-кызның илаһи көчкә сәләтле бөек зат икәнен, аның иҗтимагый тормышта үз урыны булырга тиешлеген раслаган. Үзләренең кешелек сыйфатлары белән дә халкыбызның иң олы абруен яулаган, рухи камиллеккә ирешкән, үлем җәзасын да имән баганасына таянып горур атлап каршы алган олы шәхес буларак, алар бүген дә татар хатын-кызлары өчен якты үрнәк булып тора, аның якты истәлеге милләт мәнфәгатьләре өчен хәрәкәт итәргә чакыра ала. Менә ни өчен кирәк бүген халкыбызның тарихи хәтерен яңартырга. Уку-укытуның дәрәҗәсен үстерү, халыкны тәрбияләү, мәдәниятне үстерү өчен ул туганнары белән үзенең бик күп өлешен кертә. Алар өчен бик мөһим шарт: наданлыкны, артта калганлыкны бетерү була. Мөхлисә Бубыйның тормыш юлы бик катлаулы юллар аша үтсә дә, аны көчле рухлы булуы сынуга юл куймый.Белемнәрен, көчләрен үзеннән соң килүче буыннарга тапшырып, үзләре инде күптән безнең арадан киткән бу Фатыйха Аитова мәктәбенең затларны, бу укытучыларны йолдызларга тиңләрлек. Халкыбызның аң-белемгә мөгаллимәләре һәм укучы омтылышы таңында балкып чыккан таң йолдызлары– Зөһрәләре алар.

Мәгърифәтчелек һәм гуманизм рухында язган Галимәтелбәнат Биктимерова әдибә «мөмкин кадәр үз телемез илә язарга гайрәт иттем» дигән принципларына прозаик әсәрләрендә турылыклы булып кала. Зөһрә таң билгесе булган кебек Сара Шакулова тормышы һәм физика-математика биеклекләрен яулаудагы батырлыгыда фән үрләренә күтәрелергә ашкынган безнең татар хатын –кызлары күңелендә юл күрсәтүче йолдыз булып җемелди.

Алар укымышлы, зыялы, тәртипле һәм тәрбияле, хөрмәткә лаек хатын-кызлар булган. Үз чиратында хөрмәтен, мәхәббәтен, күңелен тудырган үлемсез хезмәтләре һәрвакыт халык күңелендә калалар. Без бүген дә чиксез горурлык хисләре белән искә алабыз.

Татар халкы милләт булып яшәгәндә Мөхлисәләр, Фатыйма Аитовалар, Галимәтелбәнат Биктимерова, Сара Шакулова да яшәр, һәрвакыт безнең белән очраштырыр.

# “ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ” МӨХЛИСӘ БУБЫЙ

***Сибгатуллина Миләүшә Габдулла кызы,***
*Чистай районы бнчы төп гомуми белем бирү мәктәбе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,***
***Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.***
***Бер милләтнең там яртысы без булгачдыйн,***
***Карап карыйк: ирәнләрдән ничек ким без?!***
***Маһруй Мозаффария***

“Татар хатыныниләр күрми”! Бу җөмләне гасырлар авазы аша ишетеп, кайсы көнгә туры китереп әйтсәк тә, һичшиксез, нәкъ безнең чор фразасы бу диеп уйларга була. Иман ныклыгы, кылган гамәлләре белән дә бары тик горурлык хисләре генә тудыра ала торган тарихыбызның легендар хатын-кызы Мөхлисә Бубый язмышында да йөрәк авыртырлык урыннар биһисап. Халкыбызның горурлыгы булып торган Мөхлисә Бубый – татар кызлары өчен беренче мәдрәсә оештыручы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, хатын-кызлардан беренче казый.

Татар халкын торгынлыктан чыгаруны үз бурычы итеп куйган җәдитчеләр тәрәккыйпәрвәр – «яңа кеше” тәрбияләүне хатын-кызның җәмгыятьтә һәм гаиләдәге хәлен үзгәртү белән бәйләп караганнар. Беренчеләрдән булып, бу проблеманың чишелеш юлларын галим, мөдәррис, дин белгече Ризаэддин Фәхретдин үз әсәрләрендә эзли башлаган. Яхшы тәрбияле, киң белемле кызлар гына чын милләт аналары булып җитешәчәк һәм киләчәктә милләтне алга алып барырлык шәхесләр тәрбияләячәк дигән фикерне дәлилләп чыккан ул. Мөхлисә Бубый тәкдиренең бер өлеше үзеннән күпкә олы кешегә кияүгә чыгып, ахыры уңышсызлыкка дучар булып, ике баласы белән аерылып, яңа тормыш башлаудан тора. Изелгән татар хатын кызны яклаучы, киләчәккә өмет тудыручы Мөхлисә калган гомерен татар мөселман гаиләсе институтына багышлый. Ризаэтдин Фәхретдинов башлангычын дәвам итүче ул була.

1931-1937 еллар... Илнең аңлы, сәләтле, булдыклы, алдынгы фикерле, көчле ихтыяр көченә ия булган аерым уңай шәхесләрдән арыну чоры... Ялган уйдырма, гаеп тагып, аларны кабул итәгә мәҗбүр итеп, физик җәзалаулар юлы белән гаиләләрен, нәселләрен куркыту юлы белән никадәр уникаль шәхесләрне, асыл затларны җир йөзеннән себереп ташлаганнар. Мөхлисә Бубый да шул афәтле еллар корбаны.

Бүгенгесе көннең проблемаларын җиңеп чыгар өчен аның образы безгә юл яктырткыч йолдыз булып тора, тарихи шәхесләребезгә, динебезгә карата горурлык хисләре тәрбияли, әлеге олуг затларыбыз салган иманлы юлны, рухи ныклык үрнәген киләсе буыннарда да лаеклы рәвештә дәвам итәргә чакырып кала. Шул авыр тормыш шартларында башкаларга да таяныч ышаныч була алган шәхес бүгенгесе көндә дә безнең тормышта үзенең уңай яклары белән үрнәк.

## МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ – ТАТАР ХАТЫЗ-КЫЗЛАРЫ КУЛЫНДА

***Хәйруллина Айсылу Рәсим кызы***
*Казан шәһәре Яңа Савин районың ГБМУ*
*"Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә*
*торган 71 нче татар – рус урта мәктәбе"*
*I категорияле татар теле*
*һәм әдәбияты укытучысы*

Гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, татарларда аң-белемгә игътибар зур булган, халык үзе гыйлемен буыннардан – буыннарга тапшырып килгән, мәчет салса, аның каршында мәдрәсә ачкан, шуңа да патша Русиясендә татар халкы иң гыйлемле халык булып саналган. Әмма мәдрәсәләрдә ир балалар гына белем алган, кызлар исә өйдә я муллаларның хатыннары – абыстайларда укыргаязарга өйрәнгәннәр, башлыча догалар ятлау белән чикләнгәннәр. Үсеш чорына кергәндә татар кызларына системалы белем бирү максаты алга калкып чыга. Хатын-кызның бурычы дөньяга бала китерү белән генә чикләнми, ул аны тәрбияли дә, ә бала тәрбияләүче ана гыйлемле, мәгърифәтле дә булырга тиеш, дигән фикерне күтәреп чыгалар алдынгы карашлы татар зыялылары. Кызларга дини һәм мәдәни белем бирү милләт анасын тәрбияләү бурычына килеп тоташа. Хатынкызлар өчен уку йортларын татар байлары, зыялылары, дин әһелләре ача, аларга хатыннары, кыз туганнары кушыла, алар арасыннан хатын-кыз лидерлар калкып чыга. Татар хатын-кызлары арасыннан Фәхрелбанәт Сөләйманова, Газизә Самитова, Маһруй Барудия, Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффариялар, Ләбибә Хөсәенова, Фатиха Аитова, Фатыйма-Фәридә Ваһапова-Нәүрүзова, Мөхлисә Бубый һәм башка бик күпләр милләтебезне мәгърифәтле итү өчен зур эшләр башкаралар, мәгърифәтчеләр рәтенә басалар.

Алар арасында Мөхлисә Бубый аерым урын алып тора. Заманында югары үсешкә юл тоткан, кызларга да белем биргән гыйлем учагы буларак танылган «Иж-Бубый” мәдрәсәсе ил тарихында беренче һәм әлегә кадәр бердәнбер казый дәрәҗәсенә лаек булган хатын-кыз исеме белән дә бәйле. Ул – Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсе белән җитәкчелек иткән Мөхлисә Нигъмәтуллина-Бубый. Ул елларда татар кызлары өчен башлангыч уку йортлары ачылган, әмма Ауропа дәрәҗәсендә белем биргән Иж-Бубый мәдрәсә комплексы кысаларында урта белем биреп мөгаллимәләр әзерләгән кызлар мәдрәсәсе Русиядә бердәнбер булган.

Мөхлисә Бубый үзенең гомерен динне саклауга, хатын-кызларны балаларын милләт балалары итеп тәрбияләргә сәләтле аналар итеп тәрбияләүгә багышлаган, алар турында кайгырткан, аларның хокуклары өчен көрәшкән, хатын-кызның илаһи көчкә сәләтле бөек зат икәнен, аның иҗтимагый тормышта үз урыны булырга тиешлеген раслаган. Үзенең кешелек сыйфатлары белән дә халкыбызның иң олы абруен яулаган, рухи камиллеккә ирешкән, үлем җәзасын да имән баганасына таянып горур атлап каршы алган олы шәхес буларак, ул бүген дә татар хатын-кызлары өчен якты үрнәк булып тора, аның якты истәлеге милләт мәнфәгатьләре өчен хәрәкәт итәргә чакыра ала. Менә ни өчен кирәк бүген халкыбызның тарихи хәтерен яңартырга. Дини җирлектә, гомерләрен динне саклауга, мәгърифәтне үстерүгә багышлаган затлы вә зыялы гаиләдә туып үскән, дини белем, гыйлем алган Мөхлисә, якыннары белән кулга-кул тотынып хезмәт иткән, шуңа да рухи үсешкә ирешә алган, халыкка хезмәт итүгә бәйле эшчәнлегендә көчле булган.

Татар милләте генә түгел, бөтен совет халкы язмышында кара көннәр булып язылып калган Сталин репрессияләре дигән афәтне татар хатын-кызлары арасында беренче казыя Мөхлисә Бубый образы тамашачыга яшь режиссер Илгиз Зәйниев һәм пьеса авторы Ркаил Зәйдулланың “Яңа татар пьесасы” конкурсында җиңү яулаган “Үлеп яратты” дигән пьесасында күрсәтелә. Спектакльне карагач, милләт фаҗигасен күрәсең, татар хатын-кызының рухи яктан никадәр көчле булуы, иман ныклыгына тагын бер кат инанасың.

Пьесада 1937 елда Уфада булган вакыйгалар тасвирлана. Спектакль Үзәк Диния нәзарәтендә казый булып эшләгән Мөхлисә Бубыйның өендә намаз укыган вакытында кулга алынуы белән башлана. Аның өендә тентү ясала һәм сандык төбендә көмеш беләзекләре, алтын алкалары табыла: Мөхлисә Бубый гомере буена хаҗ кылу турында хыялланып яши һәм зәркән эшләнмәләрен изге сәфәр өчен җыйган, саклаган булган. НКВД хезмәткәренә аны кулга алыр өчен бу факт җитә

һәм аны контрреволюцион эшчәнлек алып баруда гаеплиләр. Мөхлисә Бубый гаебен танымый һәм кыйналуга, мәсхәрәләүгә дучар ителә. Спектакльдә Макаев образы аша автор чарасызлыктан, газаплауларга түзә алмыйча, танышларын гомер булмаган вакыйгаларга катнашы барлыгын раслаган, мескен кешеләрне күрсәтә. Хәтта ки, Корбанов фамилияле НКВД кешесе дә башта Мөхлисә Бубыйга "кортка" дип кенә караса да, ахырдан аны сындыра алмыйча, үзе атыллып үлә. Бу вакытта казыяга 68 яшь була. Өлкән булуына карамастан, ул НКВДның сират күперен горур үтә. Кыйнап та карыйлар, мәкерле хәйләләр уйлап табып, гаебен танытырга тырышалар, танышларыннан "доносларˮ яздырталар, ләкин, нәтиҗәдә, Мөхлисә Бубыйның рухын сындыра алмыйлар. Киресенчә, аңа донос язган, рәнҗеткән кешеләрне ул кызгана, җылы сүзләр табып бәхилләшә, Ходайдан аларның кичерелүен ялвара.

Спектакльдә Мөхлисә Бубыйның төрмәгә кадәрге тормышы штрихлар рәвешендә генә бирелә. Аның кара фикерле надан муллага кияүгә бирүләре, аннан соң абыйларының аны ике бала (берсе – үз кызы, икенчесе – мәрхүмә асрау кызы) белән урлап алып кайтулары, 1911 елда мәдрәсәне патша жандармериясенең ябып кую күренешләре төрмәгә эләккән Мөхлисә хәтерендә яңара. М.Бубый гомер буе мәгърифәт, гуманизм идеяләрен, яхшылык тарата. Әлеге якты башлагычны И.Зәйни кыңгыраулар тоткан кызлар рәвешендә уңышлы сурәтләгән. Спектакль ахырында шушы кызларның караңгылыкта яктырткычлар тотып йөрүе дә әлеге идеяләренең дәвам итүен күрсәтә.

Мөхлисә ролендә – Г.Камал исемендәге театрның Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Дания Нуруллина. Дания ханым Мөхлисә Бубыйның трагедиясен, аның уй-кичерешләрен бөтен тулылыгы белән тамашачыга җиткерә алды. Пьеса авторы Ркаил Зәйдулла әлеге спектакльне милләт язмышы турында уйлануларга этәрә дигән иде. Шуңа күрә дә ул Мөхлисә Бубый авызыннан "Милләт язмышы – татар хатын-кызлары кулында", – дип әйттерә. Катнаш никахлар, ата-аналарның, бигрәк әни кешеләрнең балаларын татар мәктәпләренә бирмәве милләтнең бетүенә юл ача да инде. Ә Мөхлисә Бубый һәм аның ир туганнарының татар балаларының туган телдә белем алуы өчен тырышып йөрүе, Мөселман дини идарәсендә гаилә эшләре бүлеген җитәкләве, хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләрен уңышлы хәл итүе, җәмгыятьтә аларның хокукларын яклау буенча күп эш башкаруы бүгенге гүзәл затларыбыз өчен үрнәк булып тор Спектакльдә милләт язмышы шулкадәр тирән итеп тасвирлана, хәтта кайбер урыннарда күзләр яшьләнә. Мин үзем дә бу спектакльне берничә тапкыр ка-

радым. Ул безне уйландырырлык әсәр. Әле безнең милләт өчен янып – көеп йөргән хатын – кызларыбыз бүгенге көндә бик аз өйрәнелгән. Әсәрдә фикерләр ачыктан-ачык әйтелә, нәрсәгәдер төреп бирелми. Бу пьесаның иҗади идеясе – ул көч кулланугa, рәхимсезлеккә каршы торырга кирәклек, кеше рухының көчен күрсәтү. “Милләт язмышы–татар хатын-кызлары кулында”, ди төп героиня.

# ДИНГӘ ҺӘМ МИЛЛӘТКӘ БИРЕЛГӘН ГОМЕР

***Хуҗина Гөлгенә Мөхәммәтнур кызы***
*Яр Чаллы шәһәре «13 нче гомуми белем*
*бирү мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халкыбызның күпгасырлы тарихы шанлы да, аянычлы да. 16 нчы гасырда татар халкының дәүләтләре белән бергә бай рухи-мәдәни мирасының да күп өлеше эзсез югала, зыялылар юкка чыгарыла, милләт үсеше тоткарлана. Тик XVIII гасырның ахырында гына, Екатерина Икенченең Ислам диненә карата булган тыюларны, чикләүләрне җиңеләйткән Указы (1788 ел) чыгып, таш мәчетләр салырга рөхсәт ителгәч, татарларда рухи тормыш җанлана башлый, караңгылыктан чыгып югарыга күтәрелү өмете уяна. Татар зыялылары алга үсеш юлларын эзләүдә яңа баскычка күтәреләләр, халыкның аңын үстерү өчен агарту эшенә керешәләр.

XIX йөзнең уртасы һәм икенче яртысында халкыбызда фикер җанланышы күзәтелә, татар дөньясына Шиһабетдин Мәрҗани өр-яңа фикерләр белән килеп керә. Ул дин белән бергә милли аңның татар үсеше өчен зур әһәмиятен аңлап эш итә. Аңа тулысынча фикердәш була алмаса да, Каюм Насыйри да татар үсешенә үзеннән гаять зур өлеш кертә. Исмәгыйль Гаспралы җәмгыять үсеше өчен мәгариф системасын үзгәртеп кору мәсьәләсен күтәреп чыга, җәдитчелек хәрәкәтенә нигез сала. Татар зыялыларының сәяси эшчәнлегендә дә үзгәрешләр хасил була.

Гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, татарларда аң-белемгә игътибар зур булган, мәчет салса, аның каршында мәдрәсә ачкан. Әмма мәдрәсәләрдә ир балалар гына белем алган, кызлар исә өйдә я муллаларның хатыннары – абыстайларда укыргаязарга өйрәнгәннәр, башлыча догалар ятлау белән чикләнгәннәр. Татар хатын-кызлары арасыннан Фәхрелбанәт Сөләйманова, Газизә Самито-

ва, Маһруй Барудия, Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффарияләр, Ләбибә Хөсәенова, Фатиха Аитова, Фатыйма-Фәридә Ваһапова-Нәүрүзова, Мөхлисә Бубый һәм башка бик күпләр милләтебезне мәгърифәтле итү өчен зур эшләр башкаралар, мәгърифәтчеләр рәтенә басалар.

Алар арасында Мөхлисә Бубый аерым урын алып тора. Заманында югары үсешкә юл тоткан, кызларга да белем биргән гыйлем учагы буларак танылган «Иж-Бубый” мәдрәсәсе ил тарихында беренче һәм әлегә кадәр бердәнбер казый дәрәҗәсенә лаек булган хатын-кыз исеме белән дә бәйле. Ул – Иж-Бубый кызлар мәдрәсәсе белән җитәкчелек иткән Мөхлисә Нигъмәтуллина-Бубый. Ул елларда татар кызлары өчен башлангыч уку йортлары ачылган, әмма Ауропа дәрәҗәсендә белем биргән Иж-Бубый мәдрәсә комплексы кысаларында урта белем биреп мөгаллимәләр әзерләгән кызлар мәдрәсәсе Русиядә бердәнбер булган.

Бу исем белән бәйле мәдрәсәгә аерым тукталуыбыз очраклы түгел. Афәтле тарих юлларын узганда милләтебезне ана теле, Ислам дине, асыл гореф-гадәтләребез саклап килгән. Бүгенге глобализация чорында милләтне милләт итеп саклап калу мәсьәләсе яңадан актуаль төс ала. Мал туплауны төп максат итеп куйган шушы катлаулы заманда татар халкы милләт булып сакланып калырмы, балаларыбыз милләтебезнең киләчәк язмышын үз кулларына алырлык булып тәрбияләнеп үсеп өлгерерме, рухи-мәдәни кыйммәтләребезне аларга рухи терәк итеп тапшыра алырбызмы, дигән уйлар күпләрнең күңелен борчый торгандыр. Мондый уйлар исә хатын-кыз, ана төшенчәләренә барып тоташа, чөнки балаларны югары әхлаклы, иманлы кешеләр, милләт балалары итеп тәрбияләүдә төп роль хатын-кыз җилкәсенә төшә, иманлылык хисен күкрәк сөте белән ул гына сеңдерә, ул гына туган телле итеп үстерә ала газиз баласын.

# ДӨНЬЯНЫҢ ЯКТЫРТЫП ТОРУЧЫ НУРЛАРЫ

***Бәдретдинова Гүзәлия Нургали кызы***
*Балык бистәсе районы Корноухово урта*
*гомуми белем мәктәбе татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы*

Һәр милләт үзенчә бөек һәм зирәк. Татарларның бөеклеге аларның мөстәкыйль рухлылыгында, сугышларда баһадирлыгында, теләсә нинди эштә уңган һәм һәвәс булуында чагыла. Милли сыйфатларның юкка чыгуы – милләтнең юкка чыгуы ул, шуңа күрә халкыбыз гыйлемгә тартылган, беренче чиратта, мәктәп– мәдрәсәләр ачуга әһәмият биргән.

XVIII-XIX гасыр уртасында акыл һәм фәнгә таянып, кеше һәм җәмгыятьнең чын табигатенә туры килә торган “табигый тәртипкә” ирешү мөмкинлегенә нигезләнгән фикер агымы– мәгърифәтчелек барлыкка килә. Бәла-казаларның сәбәбен наданлык, дини фанатизмда күргән мәгърифәтчеләр сәяси азатлык, хокукый тигезлекне яклап, феодаль тәртипләргә каршы чыгалар. Элек-электән гыйлемгә тартылган татар халкы өчен мәгърифәт мөстәкыйльлекнең төп юлдашы була. Күренекле этнограф Карл Фукс “Казан татарлары” дигән хезмәтендә татарларның Европадагы бик күп халыкларга караганда мәгърифәтлерәк булуын билгеләп үтә. Тарихтан билгеле булганча, 1917 елга кадәр татарлар укый-яза белү, китап бастыру буенча иң алдынгы урыннарны алып торганнар. Халыкның педагогик культурасын үстерүдә, үз халкы турында кайгыртып, бөтен белемен, көчен халыкка аң-белем таратуга биргән шәхесләрнең роле, һичшиксез, зур. Юкка гына мәгърифәтче Ризаэддин бине Фәхреддин: “Галимнәр-пәйгамбәрләрнең варислары, дөньяның яктыртып торучы нурлары” дип язып калдырмаган. Аларның һәркайсының иҗаты, эшчәнлеге аерым өйрәнүгә лаек. Үземнең чыгышымда мин хатын-кыз мәгърифәтчеләр, аларның милләтебез үсешенә керткән өлешләре турында сөйләрмен.19 гасырның ахыры – 20 гасырның башы – татар мәгърифәтчелегенең үсеш чоры. Бу чорда җәдиди мәктәпләр ачыла, хатын-кызларга да гыйлем алу мөмкинлеге туа. 1917 елгы Октябрь борылышына кадәр, укымышсыз, хокуксыз мөселман хатын-кызлары турындагы фикер ныклап урнашкан булуга карамастан, татар хатын-кызының роле гаилә кысаларында гына калмый. Алар иҗтимагый тормышта да әһәмиятле роль башкаралар. Кыз балаларны укыту, аң-белемле итү күп каршылыкларга очрый, ләкин бу алар белем алудан мәхрүм калган дигән сүз түгел әле. XIX гасырның 60 елларында тарихчы М.Лаптев

татарларның шактый укымышлы, хәтта хатын-кызлар арасында да укый-яза белүчеләрнең күп булуы турында яза. Шактый эре капиталга ия булган Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар, Шакир һәм Закир Рәмиевләр, фабрикант Акчуриннар, Үтәмешевләр белән бергә матди байлыклары әллә ни зур булмаган хатын-кызларыбыз да милли мәгариф үсеше өчен үзләреннән зур өлеш кертәләр.

1866 елның ноябрендә Оренбург губернасының Троицк каласында сәүдәгәр Габделвәли Яушев гаиләсендә дөньяга килгән иганәче, җәмәгать эшлеклесе, татар халкына дөньяви белем бирү тарафдары Фатиха Габделвәли кызы Аитова (1866-1942) – халыкка аң-белем таратуда, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда зур тырышлык куйган фидаи затлардан. 1897 елда Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыга. Иренең рухи һәм матди ярдәме белән Казанда татар кызлары өчен, бушлай тегү-чигү эшләренә өйрәтүче мәктәп ачтыра. Әмма Фатиха Аитованың иң зур хыялы – милли кызлар гимназиясе ачу була. 1910 елда әтисе вафатыннан соң калган мираска дүрт сыйныфлы дөньяви мәктәп ачтыра. ул 1916 елда кызлар өчен беренче хосусый гимназия итеп үзгәртелә. Бу гимназия укыту эшләренең куелышы һәм укытыла торган фәннәрнең рус мәктәпләренекенә туры килгән бердәнбер уку йорты була. Анда укыган өчен түләү гаиләнең матди хәленнән чыгып билгеләнә. Фәкыйрь гаиләләр балалары өчен акчаны кимрәк күләмдә түләгән яисә түләүдән бөтенләй азат ителгән. Әлеге мәктәптә 30-40 кыз бала бушлай укыган. Гимназияне тотуга киткән чыгымның яртысын Ф.Аитова үзе түләгән. Кызлар гимназиясендә татар һәм гарәп телләре, рус теле һәм әдәбияты, тарих, география, арифметика, табигать белеме, кеше анатомиясе һәм физиологиясе, гигиена, педагогика, матур язу, рәсем, кул эшләре һәм дин гыйлеме укытылган, кием кисү һәм тегү, шулай ук аш-су әзерләргә өйрәтү курслары ачылган.

Әлбәттә, мондый уку йортында эшләргә укытучыларның да иң осталары гына сайлап алынган. Укыту-тәрбия эше шул заманның алдынгы педагогы Мәһруй ханым Мозаффария (1873-1945) һәм махсус әзерлекле хатын-кыз мөгаллимәләр җитәкчелегендә алып барылган. Мәсәлән, рус телен, русча матур язуны – Казандагы хатын-кызлар югары курсларын тәмамлаган Бибимәрьям Акимбәтова (ул шул ук вакытта гимназия мөдире дә булган), татарча матур язу һәм табигать белемен – Шумкова гимназиясен тәмамлаган Мәрьям Мөштәриева, география һәм татар тарихын – Котова гимназиясендә белем алган Мәдинә Сәгыйтова укыта. Татар хатын-кызларыннан беренче булып, Сорбонна университетын тәмамлаган, соңыннан Мәскәү университетында югары математик белем алган Сара

Шәкүлова да шушы гимназиядә белем бирә. Менә шундый тирән белемле укытучылар да бу уку йортының чын бәһасен билгели. Аның даны еракларга тарала. Тагын бер игелекле хатын-кыз, күренекле мулла һәм мөдәррис Галимҗан Барудиның хатыны Бибимаһруй Үтәмешева-Галиева “Мөхәммәдия “мәдрәсәсен киңәйтү өчен үзенең 2000 сум акчасын бирә, соңрак шунда ук кыз балалар өчен мәктәп ача. Ул “Бибимаһруй абыстай мәктәбе “дип атала. Аның мәктәбенә, укытуның рәвешләрен, дәресләрен карау өчен, хатын-кызлар күп җыела торган була. Фатыйма-Фәридә Нәүрүзова исә Омскида татар мәктәбе ачу максаты белән, Себергә күчеп китә, ә вафаты алдыннан бөтен байлыгын хәзерге Ютазы районы Кәрәкәшле авылында мәктәп төзү өчен васыять итеп калдыра. Россия Хөкүмәте Думасы әгъзасы, күренекле галим С. Җантуринның хатыны Суфия Җантурина 50 мең сум акчасын Уфадагы “Галия“мәдрәсәсенә бирә; Башкортстанның Бүздәк районы Килем авылында кызлар һәм малайлар өчен 2 мәктәп төзетеп, укытучыларга хезмәт хакы түләп тора; шул ук авылда мәчет төзү өчен акча бирә. Суфия Җантуринаның ачлык елларында мохтаҗларга ярдәм итүе, Петербургка барып, туку станоклары алып кайтуы һәм бу эшкә авыл халкын да өйрәтүе билгеле.

XIX гасыр ахырында кызлар өчен ачылган рус-татар мәктәпләре шулай ук соклану уята. Бу башлангычка 1872 елда Казанда Бәдриҗамал Әпсәләмова нигез сала. Соңрак Шәмсенур Гайнетдинова, Хәдичә Әхмәрова, Әминә Фәезханова бу эшне дәвам итәләр.

Иҗтимагый тормышта үз урыннарын тапкан, алай гына да түгел, гасырлар буе формалашкан тәртипләргә каршы, башкалар язмышын уңай якка үзгәртергә дип, көрәшкә күтәрелгән кыю хатын-кызларыбыз арасында, һичшиксез, тарихыбызның легендар хатын-кызы Мөхлисә Буби аерым ихтирамга һәм игътибарга лаек. Ул үзенең гаҗәеп авыр һәм якты тормышы белән аерылып тора. Буби бертуганнарының хатыннары Нәсимә һәм Хөснифатыйма белән берлектә яңа типтагы хатын-кызлар мәдрәсәсен оештыруда актив катнаша. 1901 елда 6 сыйныфлы татар хатын-кызлар мәктәбе ачыла, һәм Мөхлисә Буби аның мөдире була. Анда дин гыйлеме белән беррәттән төрле дөньяви фәннәр, 1905 елдан рус теле укытыла. 1907 елда 1 сыйныфлы рус-татар училищесы ачыла, ул хатын-кызлар мәдрәсәсенең бер бүлегенә әверелә. Иж-Бубый мәдрәсәсе мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллимәләр әзерләүдә беренче уку йорты була.Бирегә укырга Уфа, Сембер, Самара, Әстерхан, Ташкент, Петропавловск, Мәскәү кебек шәһәрләрдән килләләр.

1911елда Бубинең абыйсы һәм энесе кулга алына, уку йортлары ябыла . Буби Троицк шәһәренә күчеп китә һәм анда хатын-кызлар мәктәбен

җитәкли, хатын-кызлар гимназиясендә дин гыйлеме укыта. 1914 елда мөгаллимәләр семинариясе ачуга ирешә.

1917 елның маенда Мәскәүдә узган Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда Мөхлисә Буби Мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы һәм ислам тарихында хатын-кызлардан беренче казый итеп сайлана. 1930 елның 20 ноябрендә Буби «Башкортстанның контрреволюцион милләтчеләр оешмасында» катнашуда гаепләнеп кулга алына һәм 7 ел кимсетелү, авыр газаплар күргәннән соң атылуга хөкем ителә. 1937 елнын ноябрендә 68 яшендә атып үтерелә. Вафатыннан соң аклана.

Халкыбыз зыялы, укымышлы милләтпәрвәр улларын һәм кызларын онытмаска тиеш. Бу– безнең төп бурычыбыз. Бөек акыл иясе Шиһабетдин Мәрҗани сүзләре белән әйткәндә:” Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк”. Күп гасырлык тарихы булган татар милләтенең киләчәктә яшәргә хакы да, мөмкинлеге дә бар.

## БЕРЕНЧЕ ДӨНЬЯВИ МӘКТӘПЛӘР

***Ваһапова Гөлүсә Равил кызы***
*Аксубай муниципаль районы*
*“Шәрбән төп гомуми белем бирү мәктәбе”*
*МБГБУ тарих укытучысы*

XIXгасырның 60-70 нче елларында Россиядә иҗтимагый фикернең һәм азатлык хәрәкәтенең гомуми күтәрелеше. 1861 елда крепостное правоның бетерелүе, патша хөкүмәтен күп кенә реформалар үткәрергә мәҗбүр итә.

Шундый шартларда царизм мәгариф системасын да үзгәрешсез калдыра алмады. Мәгариф эшенә караган реформалар арасында Идел буендагы милләтләрне укыту эшенә кагылышлы 1870 елның 26 март “Кагыйдәләр”е аерым урын алып тора. Бу “Кагыйдәләр”нең икенче өлешендә укыту рус телендә алып барыла торган училищеларда, шулай ук мәдрәсәләрдә татарлар өчен рус теле өйрәтү классалары ачу билгеләнә. Дәүләт советы, әлеге “Кагыйдәләр”нең татарларга караган өлешен тормышка ашыру өчен, 1871 елның 28 октяберендә Казан укыту округы идарәсе каршында махсус “татар мәктәпләре инспекторы” булдыру турында карар чыгара. Инспектор итеп 1871 елның нояберендә Көнчыгыш телләре белгече В.В. Радлов билгеләнә. В. В. Радлов ярдәмендә К. На-

сыйри 1872 елда Казанда татар балаларына рус телендә фәнни белем нигезләре бирә торган беренче училищега нигез сала һәм ул беренче рәсми дөньяви мәктәп оештыру авырлыкларын үз башыннан кичерә.

Киңәеп барган алдынгы демократик хәрәкәттән рус уку йортларында белем алган, алдынгы рус культурасы белән таныш булган һәм илдәге азатлык хәрәкәтенең төп юнәлешен дөрес аңлаган татар хатын-кызлары да читтә калмый. Татар хатын-кызларыннан беренче булып бу демократик хәрәкәттә катнашучылар Г. Әбсәләмова, Сәйфуллина һәм Шәмсенур Гайнуллина булалар. Аларның эшчәнлеге татар мәктәпләре тарихында игътибарга лаеклы урын алып тора.

1872 елның апрель башында Әбсәләмова (исеме Гөлҗамал булырга тиеш) татар мәктәпләре инспекторы В.В. Радловка Казанда кыз балалар өчен К. Насыйри үрнәгендә мәктәп ачарга һәм анда эшләргә теләге зур булу турында белдерә. Ул үзенең рус телен яхшы белүен күрсәтә, якын арада хәзерләнеп, укытучылыкка имтихан тотарга вәгъдә итә. 1873 елның 20 январендә "Казанда татар кызлары өчен тәҗрибә тәртибендә бер елга хөкүмәт мәктәбе ачарга" рөхсәт алуга ирешә.

1873 елның ахырында В.В. Радлов бу мәктәптә булып, укучыларның белемнәрен тикшереп һәм мәгариф министрлыгына биргән отчетында түбәндәгеләрне яза: "Барлык укучы кыз балалар да русча яхшы укыйлар һәм язалар, хәттә әйбәт кенә сөйләшәләр дә. Арифметика буенча беренче ике гамәлне үтәп, күп кенә мәсьәләләр эшләгәннәр .

Укыту планнан тыш, Әбсәләмова үзенең укучыларын тегәргә, чигәргә һәм бәйләргә өйрәтү буенча да күп кенә эш башкара. Болар барысы да аның тормышны тирән аңлаган һәм зур педагогик сәләткә ия булуын күрсәтәләр.

Уңышлы гына башланган эшне Әбсәләмовага 1874 елда ике сәбәп аркасында алга таба дәвам иттерергә мөмкинлек булмый: беренчедән, патша мәгариф министрлыгы бу мәктәпне финанслаудан баш тарта; икенчедән, татар реакцион элементларның коткысына ияреп, ата-аналарның күбесе балаларын мәктәпкә җибәрүдән туктый. Шул рәвешчә, балалар өчен ачылган беренче дөньяви мәктәп аз гына яшәп кала. Мәктәп ябылуны Әбсәләмова татарларда башланган алдынгы иҗтимагый хәрәкәткә удар итеп карый, бераз төшенкелеккә бирелеп йөри. Шулай да иҗтимагый хәрәкәттән, татар хатын-кызларының хокуклары өчен көрәштә читләшми. Ул балаларны өендә русча укытуын дәвам иттерә.

1873 елда Әбсәләмова белән бер үк вакытта, Казан Адмиралтейство бистәсеннән Сәйфуллина да, үзенә мәктә ачарга рөхсәт бирүне сорап, В.В. Радловка мөрәҗәгать итә. Аңа ул үзенең чыгышы ягыннан крестьян

семьясыннан булуын, руханилар катлавына бернинди мөнәсәбәте юклыгын, ләкин белеме һәм сәләте белән, һәр абыстай шикелле балаларны укытырга хакы барлыгын белдерә. Үзенең гаризасына бистәдә күп кенә эшче семьяларының кыз балалар өчен махсус ачуны яклауларын раслаган кәгазь беркетә.

Мәктәп инспекторы В.В. Радлов гаризада китерелгән дәлилләрне урынлы дип саный, мәктәп ачарга рөхсәт сорап, 1873 елның 11 мартында попечительгә яза, 15 мартта попечитель мәсьәләне уңай хәл итә. (Кызганычка каршы, Сәйфуллина һәм ул ачарга йөргән мәктәп язмышы турында архивта башка документлар табылмады.)

Кыз балаларга рус телендә башлангыч белем бирү буенча тагын бер мәктәп (училеще) 1878 елның 24 июлендә Казанның Пороховой (Эшчеләр) бистәсендә ачыла. Башта мәктәптә ун укучы укыган булса, 13 сентябрьдә аларның саны 15 җитә. Мәктәпне ачуда һәм, аның эшен юлга салып, уңышлы алып баруда Уфада кызлар гимназиясен тәмамлаган Шәмсенур Гайнуллина зур инициатива күрсәтә. Гайнуллина эшчәнлеген мәктәп өяз земствосы хисабына яши. Нинди генә тырышлыклар күрсәтүенә карамастан, В.В.Радлов бу мәктәпне Мәгариф министрлыгы бюджетына күчерә алмый. Патша самодержавиясе рус булмаган милләтләрне укыту буенча “зур чыгымнар” тоту турында демагогик рәвештә шапырынса да, чынбарлыкта ул “чыгымнар”ның гаять азлыгы билгеле. Мәсәлән, 1873 елны Казан укыту округында 26 март “Кагыйдәләр”е нигезендә татарлар өчен ачылган 13 мәктәпнең бары тик икесе (Казандагы К. Насыйри ачкан һәм Петряксәдәге мәктәпләр) Мәгариф министрлыгы бюджетында булганнар.

1882 елда Земство әлеге мәктәпне финанслаудан туктый, шул сәбәпле ул ябыла.

XIX гасырның җитмешенче елларында кыз балалар өчен ачылган беренче дөньяви мәктәпләр аз эшләсәләр дә, алар беренче булып татар кызларын русча укыта башлау эшенә нигез салалар.

Әбсәләмова, Сәйфуллина, Гайнуллина башлаган эшне 1905-1907 елларда Фатыха Аитова, Ләбибә Хөсәенова, Суфия Таһирова, Мәдинә Терегулова, Нәфисә Казакова, Фатыйма Саинова һәм башкалар яңартып һәм тирәнәйтеп җибәрәләр. Аларның да эше властьлар һәм җәмгыятьтәге реакцион элементларның зур каршылыгына очрый; кара реакция һәм сугыш елларында кыз балалар өчен ачылган мәктәпләр саны нык кими.

# КАЗАН-АЛАБУГА.
# МӘГЪРИФӘТКӘ ИЛТКӘН ЮЛ

***Вагыйзова Ләюзә Гыйлембаян кызы,***
*Алабуга муниципаль районы*
*ГБМБУ "1 нче гимназия"*
*югары категорияле татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы*

1000 еллык тарихы булган Алабуга шәһәре үзенең бөек шәхесләре белән күренекле. Гомер-гомергә күренекле кешеләрнең кылган эшгамәлләре нәтиҗәсендә Алабуга Чулман буеның мәдәни һәм мәгърифәт үзәге булып торган. Шуның нәтиҗәсе буларак, шәһәр тарихы сәүдәгәрләр, язучылар, рәссамнар, музыкантлар исеме белән тыгыз бәйләнештә. Шәһәребезне Стахеев, Гирбасов кебек сәүдәгәр династияләре тагын да данлый төшә. Алардан калган үзенчәлекле тарихи йортлар бүгенге шәһәребезнең бизәге, мактанычы. Алабугада сокланырлык, тырыш, тормышны, туган якларын өзелеп сөюче кешеләр яши. Алар арасында әле эшләгән эшләре зур булып та, фәнни яктан өйрәнелмәү нәтиҗәсендә халыкка танылмый калганнары да байтак. Нәкъ менә шундыйларның берсе– татар хатын-кызлары арасында беренче укытучыларның берсе, хатын-кыз филологлар арасында беренче диссертацияне яклаучы галимә, бик күп фәнни хезмәтләр авторы, филология фәннәре кандидаты, Алабуга дәүләт педагогия институты доценты Маһинур Гайнулла кызы Фәйзуллина да бар. Районда депутат Файзуллина чыгыш ясамаган клуб, аннан методик ярдәм күрмәгән мәктәп калмагандыр. Маһинур Гайнулловна татар әдәбиятының М.Жәлил, Г.Әпсәләмов, Х.Туфан, А.Шамов, Һ. Такташ, И.Нуруллин, Ә.Фәйзи, К.Нәҗми, Ш.Камал, Н.Дәүли кебек күренекле, зур әдипләре белән аралашкан, озак вакытлар алар белән бергә эшләгән, хат алышкан. М.Г. Фәйзуллинага яшьлек елларында М.И.Калинин, беренче дипломат хатын-кыз Колантай, К.Цеткин белән очрашырга, Н.К.Крупская белән сөйләшергә, киңәшләшергә туры килгән. Кремльнең зур сараенда тәрҗемәче булып та эшләгән ул. Менә шушы күренекле шәхеснең тормыш юлы, язмышы турыдан – туры туган ягыбыз Алабуга белән бәйле.

Маһинур Гайнулла кызы Файзуллина 1901 елның 13 июнендә Казахстанның кечкенә генә шәһәре Атбасарда сигезенче бала булып дөньяга килә. Әтисе Файзулла улы Гайнулла Арча районы Базарлы Ашыт авылыннан. Гайнулла абзый үз авылындагы Гайниҗамал исемле кызны

тормыш иптәше итеп сайлап ала һәм Себердәге Күкчәтау өязе Акан-Бөкеш авылына юл тота. Ә Гайниҗамал 12 яшендә ятим калып, абыстайда тәрбия алган кыз була. Ул аннан дөрес итеп язарга һәм укырга өйрәнеп кала. Үз чиратында Гайниҗамал тормыш иптәше Гайнулланы һәм кызы Маһинурны да уку серләренә өйрәтә. Табигать кызны зур сәләтләр белән бүләкли, ул искиткеч зирәк булып чыга. 5 яшендә укырга-язарга өйрәнә, ә инде 7 яшендә әтисенең үтенече белән еракта гы татар авылында яшәүче туганнарына хатлар яза башлый. Ата– ана кызны тагын да белемлерәк итү теләген тормышка ашыру максатыннан, мәдрәсәгә укырга бирә. Мәктәп белән абыстай җитәкчелек итә, анда төрле яшьтәге балалар йөри. Төп белем чыганагы-абыстай. Мендәрләр кабартып өелгән сандык өстенә утырып, үзенең янына җыелышкан балаларга дин сабаклары укый. Бер кулында китап, ә икенче куында тыңламаучылар өчен махсус әзерләнгән тал чыбыгы. Бер ел үткәч балалар бераз гыйлем җыя һәм иҗекләп укый башлыйлар.

1910 елда Атбасарга Казан губернасы һәм Иж-Буби мәдрәсәсеннән яшь укытучылар килә. Алар беренче булып яңача укыту системасын алып киләләр. Татар теле, тарих, география, арифметика буенча дәреслекләр күзгә чалына башлый. Яшь белгечләр әдәбиятка алдынгы караш та була, үзләре дә бик күп укый. Казаннан китап һәм дәреслекләр кайтарталар. Яшь мөгаллимнәр Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Камал ише әдипләр турында күп мәгълүматлар бирәләр.Ул еллар турында Маһинур ханым болай дип сөйли торган була: «Исемдә калганча, 1913 елда Г.Тукай үлгәч, бар да елады, хор белән аның шигырьләрен сөйләттеләр, соңыннан дәресләрне алыштырып өйләребезгә тараттылар».

Данлыклы Иж-Буби мәдрәсәсеннән Атбасарга килгән яшь укытучылар киңәшен истә тотып 13 яшьлек Маһинур Троицк шәһәренә укырга китәргә ният итә. 160 чакрым араны ат белән узып, Омскига барып җитә. Аннан поезд белән Троицкига юл тота. Вокзалдан туп-туры Г.Б.Яушева карамагындагы кызлар семинариясенә барып керә. Чын мәгънәсендәге кызыклы шәхесләр белән очрашулар яшь кызның күңелендә эзсез калмагандыр, могаен. Маһинур Файзуллина семинариядә бик тырышып белем ала. Укуны тәмамлау турындагы таныклыгына 17 фән язылып куелган. Барысы янында да «отлично» дигән язу бар. Шуннан соң Маһинур Гайнулловна туган шәһәре Атбасарга кайтып татар мәктәбендә балаларга белем бирә башлый. Аны Омск шәһәренә эшкә чакыралар. Ул бернәрсәгә дә карамыйча, барлык эшләрен ташлап шунда китә. Анда аңа бик зур бәя бирәләр. Омск мәктәпләрендә Маһинур апа тырышып укыта. 1922 ел азагында Маһинур Гайнулловнаның, тормышында зур үзгәреш була: «Азат

Себер» газетасы редакторы Хәбиб Валиев белән Мәһинур Файзуллина тормыш корып җибәрәләр. Икесе дә бәхеткә, тормышның әле яхшырагына ышаналар. 1924 елда гаиләнең шатлыгы тагын да арта-беренче уллары Ук дөньяга килә. Шул ук елда Хәбиб Вәлиевны Бөтенсоюз Үзәк эшчеләр комитетына инструктор итеп билгеләп, Мәскәүгә эшкә җибәрәләр. Яшь гаилә Мәскәүгә күчә. Мәһинур Гайнулловна исә, Нариманов исемендәге татар мәктәбенә эшли башлый. Мәскәүдә яшәү һәм эшләү чорында аңа бик күп күренекле шәхесләр белән очрашырга, иңне – иңгә куеп эшләргә туры килә.Тормыш иптәше Хәбиб татар типографиясен җитәкли, матбугат эшләрен җанлы, нәтиҗәле итеп оештыруга күп көч куя. Күп тә үтми аның талантын күреп Казанга Өлкә комитетның җир эшләре бүлегенә җитәкче итеп эшкә җибәрәләр.

Шулай итеп, Мәһинур Гайнулловна тормышында яңа чор – Казан чоры башлана. Кайда гына яшәсә дә, үзкамилләштерү юлын сайлаган Мәһинур апа алга таба үсү юлын карый. Ул ике улы белән Казанга күчә, педагогия институтының әдәбият– лингвистика факультетына укырга керә.Бер елдан, 1929 нчы елда нур өстенә нур өстәп, кызлары Ария бу дөньяга аваз сала. Казандагы тормыш матур, бәхетле булып башланып китә. 1931елда Мәһинур Гайнулловна Казан педагогия институтын тәмамлый һәм күренекле әдип, тәнкыйтьче, әдәбият һәм сәнгать белгече профессор Галимҗан Нигъмәти җитәкчелегендәге аспирантурада калдырыла.

Мәһинур Гайнулловнаның язмышы тормышының җиңел һәм авыр яклары белән бик тыгыз бәйләнгән. Ачы сагыш белән ул 1937 нче елны исенә еш төшерә торган була. Ул елларда Хәбиб Вәлиев җир эшләре буенча бүлек урынбасары була. Өйгә бик сирәк кайта, күп вакыты эш белән үтә. 1939 нчы елның җәй азагында аны бер сәбәпсез эштән куалар, ә бер айдан имеш, авылларда малларны агулап йөргән, шул сәбәпле, маллар күп үлә дип кулга да алалар. Ачык суд була, анны төрмәгә ябалар. Төрмәдә утырганда ничек интектерүләре, кыйнаулары, малларны агулау турындагы гаепне көчләп тагарга тырышулары турында Хәбиб абый үзенең хатында еш яза торган була. Мәһинур Гайнулловна ярдәм сорап, Мәскәүгә барып, Н.К.Крупская белән сөйләшергә уйлый. Ул Мәскәүгә киткән арада, Хәбиб Вәлиевны атып үтерәләр. Ату турындагы хәбәр «Кызыл Татарстан» газетасында басылып чыга. Мәһинур Гайнулловна өч нарасые белән ялгызы кала, ә бит олысына да бары тик 13 кенә яшь була. Ә алда зур сынаулар. Әмма Мәһинур апа сыгылып төшми, нык булып калырга үзендә гаҗәеп көч таба, чөнки әле сабыйларын кеше итәсе була...

Күп тә үтми, коллегалары төрле сәбәпләр табып, «халык дошманнары» белән элемтә тотканы өчен, Мәһинур апаны институттан кудыр-

талар. Мәһинур Гайнулловна еллар буе кабаттан эшкә урнаша алмыйча йөри, аны хәтта кирпеч заводына да эшкә алмыйлар. Квартирасын тартып алырга телиләр. Репрессия дулкыннары бераз кимегәч кенә, ул зур авырлык белән кирпеч заводына эшкә урнаша. Күпмедер вакыт үткәннән соң аны элекке эшенә – педагогия институтына кабул итәләр. Тормыш иптәшен югалту ачысы белән бергә Мәһинур апа рухи түбәнсетүләрне дә йөрәге аша үткәрә. Бу кайгылы авыр көннәрдә аңа иптәшләре С.Әдһәмова, Л.Жәләй, З.Тинчурина зур терәк була, сынмаска, сыгылмаска рухи яктан этәргеч бирәләр. Казан Казан инде, яманнары булган кебек, зыялы затлары да, кайчан гына булмасын, җитәрлек. Соңгыларының ярдәме белән Мәһинур апа югары уку йортында укытырга яңадан алына. 1939 елда Казанга халкыбызның бөек шагыйре М. Җәлил кайта һәм Татарстан Язучылар Союзына җитәкче итеп билгеләнә.

М.Г. Фәйзуллина нинди генә авырлыкларга юлыкса да югалып калмаган, тормышның авырлыкларына җайлашып алга барган. Аның максаты: кешеләргә файдалы булу һәм үзеңнән соң киләчәк буынга эз калдыру. Һәм максатына ирешкән. Әгәр дә кешенең максаты бар икән, ул аңа омтыла, димәк, ул аның өчен нәрсәдер эшли, димәк, ул яши! Яши әле Мәһинур апа, оныклары күңелендә яши, укучылары, хезмәттәшләре күңелендә яши.Ә без исә, шушындый данлыклы шәхес, татар галимәсенең язмышы, яшәеше Алабуга белән турыдан – туры бәйле булуы белән чиксез горурланабыз.

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЕ
# ҺӘМ ФАТИХА АИТОВА МӘКТӘБЕ

***Вафина Әлфия Мансур кызы***
*Әлки муниципаль районы*
*Иске Чаллы урта гомуми белем мәктәбе*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халкыбызның гомер-гомергә аң-белемгә, мәгърифәткә омтылып яшәве, укымышлы кешеләрне олылавы, укырга яратуы барлык кешегә дә мәгълүм.

«Җирнең нуры – кояш, кеше нуры – гыйлем» дигән гыйбарәне безнең халкыбыз ерак заманнардан аңлап эш иткән.

Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә нинди белем бирелүе турында бер мисал китереп китик. 1810 нчы елда Казан губернаторы кушуы буенча татар мәктәп-мәдрәсәләре программасын тикшергән комиссия үзенең рапортында: “Анда татар, гарәп, фарсы телләрен укыталар, арифметика, геометрияне өйрәтәләр, физика нигезләрен, Аристотель философиясен үтәләр, мөселман халыклары тарихларын тикшерәләр, Коръән ятлыйлар, аны шәрехлиләр, дини йола-гадәтләрне укыталар”,– дип нәтиҗә ясый. Бу отчет “Журнал министерство народного просвещения” дә хәтта басылып та чыга. Әнә шул татар мәктәп– мәдрәсәләрен тәмамлаган кешеләр көнчыгыш илләрдә Россиянең дипломатик эшләрен башкаралар, тәрҗемәчеләр булып илчелекләрдә, Тышкы эшләр министрлыгында эшлиләр, рус типографияләрендә Көнчыгыш телләрендә язылган әсәрләрне басарга әзерлиләр, рус уку йортларында гарәп, фарсы, төрки-татар телләрен укытып киләләр. Әнә шул мәктәп– мәдрәсәләрдә укырга, язарга өйрәнгән кешеләрдән Хәлфиннәр династиясе, Курсави, Т.Яхин, Ф.Халиди, Ш.Мәрҗәни, Х.Фәезханов, Г.Ильяси һ.б. татар мәгърифәтчеләре үсеп чыга. Мәгълүм булганча, татарлар арасындагы надан фанатиклар һәр яңалыкка каршы төшәләр. Алар, халыкны буйсындырып тоту өчен, мәктәп-мәдрәсәләрдә феодализм схоластикасына корылган шәригать законнарын гына өйрәтүне яклап чыгалар. Ә хатын-кыз мәсьәләсенә килгәндә, янәсе, ирләр белән бертигез була алмый, хатын-кыз физик яктан да, акыл ягыннан да, имештер, ирләрдән ким. Хатын-кызның укырга, язарга, фән-сәнгать белән кызыксынырга . эшкә керергә хакы юк, дип раслана.

1905 нче елгы инкыйлаб чорында, башка бик күп төрле прогрессив хәрәкәтләр белән берлектә, татар кызлары өчен булган мәктәпләргә яңалыклар кертүне яклаган хәрәкәт җәелә. Җәмгыятебезнең яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар, барлык хокуклардан мәхрүм булып, кол хәлендә яшәгәндә, искелек калдыкларына каршы көрәшүче, яңалыкка омтылучы һәм хатын-кыз азатлыгы, хокуклы булу мәсьәләсен хәл итәргә омтылучы кыю кызлар калкып чыга. Алар милләтне алга җибәрү, аң-белемле яшьләр тәрбияләү зарурлыгын аңлыйлар.

Татар хатын-кызларын мәгърифәт юлына чыгаруда, халыкка аң-белем таратуда, мәктәп-мәдрәсәләр ачуда аеруча зур тырышлык куйган, иганәче, җәмәгать эшлеклесе, татар халкына дөньяви белем бирү тарафдары Фатиха Габделвәли кызы Аитова бу җәһәттән аерым урын алып тора.

Ул 1897 нче елда Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыккан-да зур бер шарт куя: Фатихага, әтисе үлгәч, бик зур мирас – байлык кала.

Кияве Фатиха өчен шул мирастан Казанда татар кызларын укытырга заманча мәктәп салдырып бирергә һәм тормыш иптәшенә шул мәктәпне җитәкләргә каршы килмәскә тиеш була. Халкыбызның олы галиме, Фатиханың әнисенең якын дусты,Фатиханың рухи атасы Шиһабетдин Мәрҗәни аның туенда баш ата булып утыра. Фатиха Аитованың улы Йосыф ага: "Әнием Шиһабетдин хәзрәтләрен бик хөрмәт итә иде. Ул әниемнең рухи атасы булган. Әниемә тигән йөз мең сумлык мираска халкыбыз өчен кыз балалар мәктәбе салдыру теләге Шиһабетдин хәзрәтләренең әниемә биргән рухи тәрбиясенең нәтиҗәсе"– ди. Фатиха Аитова үзе гаҗәп гүзәл, буй-сыны нәфис, зәвык белән киенүче, бик тәвәккәл характерлы, куйган максатына һичшиксез ирешә торган шәхес була. Иренең мораль һәм матди ярдәме белән 1897 нче елда Казанның Суконный бистәсендә яшәүче татар кызлары өчен бушлай тегү-чигү эшләренә өйрәтүче мәктәп ачтыра. Кызларның барысы да фәкыйрь гаиләләрдән була.Ул укыту кирәк-ярагын ире акчасына сатып ала. Әлеге мәктәп нибары өч ел яшәп кала. Әмма Фатиха Аитованың иң зур хыялы – милли кызлар гимназиясе ачу була. Аитова мәктәбе укытучыларының сөйләве буенча, мәктәп ачу шактый авырга туры килә. Күп җирләргә җитә, күп акчалар түгә.

Ф.Аитова җитәкчелегендә мәктәпнең план – проекты төзелә. Раслана һәм, ниһаять, элеккеге Екатеринская һәм Четырех Евангелистов (хәзерге Тукай, Татарстан) урамнары чатында мәһабәт таш капкалы, ике катлы, бик затлы таш пулат – мәктәп салына.Сыйныфлар барлык уку әсбаплары белән тәэмин ителә.Уку-укыту эшләре өчен бөтен шартлар тудырыла.

1913-1914 нче елларда гына да ул Казан губернасының халык училищелары директоры М.Пинегинга биш тапкыр язмача үтенеч белән мөрәҗәгать итә, әмма аларның барысы да кире кагыла.Укытучылар мәктәбе ачу мәсьәләсе Казан укыту округы попечителе алдында да куела, ләкин аның да рөхсәте булмый. Ахыр чиктә, зар-мәшәкатьләр чигеп, рөхсәт ала. 1910 нчы елда ул әтисе вафатыннан соң калган мираска дүрт сыйныфлы дөньяви мәктәп ачтыра.Ул 1913 нче елда – алты сыйныфлы мәктәп, ә 1916 елда кызлар өчен беренче хосусый гимназия итеп үткәрелә. Тарихчы Т.Биктимерованың "Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында" китабында язганча, җирле властьлар аша максатына ирешә алмаган Фатиха Аитова Петроград чиновниклары белән турыдан-туры бәйләнешкә керә. Аерым алганда, Дәүләт думасында Казаннан сайланган депутат И.Годневка мөрәҗәгать итә. Мәгариф министры ярдәмчесенә җирле чиновниклар өстеннән шикаять тә бирә. Министр ярдәмчесе исә аңа 1914 нче елның 1 нче июлендә кабул ителгән "Хосусый уку йортлары турын-

дага закон”га таянып эш итәргә киңәш итә. Әлеге закон нигезендә аерым кешеләргә уку йортлары ачу буенча шактый мөстәкыйльлек, әйтик, уку йортын тотучыга үзе теләгән башлангыч, урта һөнәри белем бирү яисә катнаш мәктәп ачу, аларда уку-укытуны үзе теләгән кадәр телдә алып бару, укытыласы фәннәрне сайлау, программалар төзү хокукы бирелгән була. Казанга кайткач, Фатиха Аитова шушы закон нигезендә эш йөртә һәм 1916 нчы елның 4 нче мартында “Казанда мөселман кызлар өчен хосусый уку йорты ачарга” рөхсәт алуга ирешә. Бу – заманы өчен олы вакыйга була. Ф. Аитова оештырган гимназия укыту эшләре куелышының һәм укытыла торган фәннәрнең рус мәктәпләренекенә туры килә торган бердәнбер уку йорты була. Ул татар кызларының дөньяви белем алуга тулысынча җавап бирә һәм милли зыялылар арасында зур популярлык казана. Ф.Аитованың олы улы Исмәгыйль Габдулла Тукай, Фатих һәм ибраһим Әмирханнар белән дуслашып, аралашып яши. Шулар аша Фатиха Аитова да Тукай иҗаты белән таныша.

## МӘГЪРИФӘТЕБЕЗ ТАҢЫНДАГЫ БЕРЕНЧЕ ЯШЬ ЙОЛДЫЗЛАР

***Габделхакова Равия Фәһми кызы***
*Казан шәһәре Яңа Савин районының чит*
*телләрне тирәнтен өйрәтүче 132 нче*
*гомуми урта белем бирү мәктәбе*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кешелек үзенең яшәеше дәверендә гаять бай тормыш тәҗрибәсе туплаган. Аның бер өлешен яшь буынны мөстәкыйль тормышка әзерләү тәшкил итә. Һәр милләтнең, һәр халыкның бу өлкәдә үзенә генә хас карашлары, үзенчәлекле фикерләре, тәрбия алымнары, гасырлар буе сакланып килгән гореф-гадәтләре бар. Яшь буынны туган телендә сөйләшүче, халкын сөюче, аның чын дөрес тарихын өйрәнүче, үз милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртучы, иҗатка сәләтле, белемле буын итеп тәрбияләү эшен халык педагогикасыннан, аның хәзинәләреннән, мирасыннан башка күз алдына да китерү кыен. Шуңа күрә дә үзенең мөгаллимлек эшен шул юнәлештә алып барырга, тормышка ашырырга теләгән һәр укытучыга татар мәгарифенең күп гасырлык бай тарихын белү, беренче мәгърифәт карлыгачларыбызның тәҗрибәсеннән файдалану зарур.

1909 елда Казанда бер төркем кыз, татар кызлары өчен ачылган беренче мәктәпне тәмамлап, иң беренчеләрдән мөгаллимәлеккә шаһәдәтнамә алу бәхетенә ирешәләр. Шул көннән халкыбызны мәгърифәтле итү юлына аяк басалар, ягъни татар кызлары өчен ачылган икенче мәктәптә укыта башлыйлар. Әнә шул безнең беренче яшь мөгаллимәләребезгә-беренче «карлыгачларыбызга» канат иңдергән, мәгърифәтебез таңында беренче яшь йолдызларыбызга нур биргән, үзләренең тырышлыклары, уңганлыклары белән мәктәпләр салдырып татар кызларыннан төрле белгечләр әзерләүгә нигез салган, гомумән, татар хатын-кызларын мәгърифәтле, мәдәниятле итүгә зур көч куйган беренчеләр рәтендә халкыбызның мөхтәрәме ханымнары Ләбибә Хөсәения һәм Фатиха Аитова булды.

Патша хөкүмәте халыкларның алга, яңалыкка омтылышын гасырлар буе бастырып килде. Хәтта мәгариф өлкәсен дә өстен сыйныфларга сүзсез буйсынучы хезмәтче-коллар тәрбияләү өчен генә файдаланды. Рус булмаган халыклар бигрәк тә авыр хәлдә булды, күбесенең үз язмалары да, мәктәпләре дә юк, алар туган телдә мәктәп ачу хокукыннан да мәхрүм иделәр. Патша хөкүмәте анда-санда сакланып калган мәчетләр каршындагы кечкенә генә мәктәпләрне дә рус булмаган халыкларны руслаштыру коралы, бөтен яңалыкка каршы тору коралы итеп файдаланды, халыкны артка өстерәүче фанатиклар тәрбияләү максатын куйды.

Ә җәмгыятьнең яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар, барлык хокуклардан мәхрүм булып, кол хәлендә яшәделәр.

Патша хөкүмәте, халыкны агарту эшеннән хөкүмәткә каршы революцион хәрәкәт күтәрелер, ә рус булмаган милләтләрдә милли азатлык хәрәкәте башланыр, дип курыкты.

Вакыт үзенекен итә. XIX гасыр ахырларында Европа мәдәниятенең тәэсире, капитализм үсү, буржуазия барлыкка килү илдә иҗтимагый тормыш шартларын үзгәртә, прогрессив көчләр барлыкка килә. Халыкның хәлен үзгәртү өчен хәрәкәт башлана.

Кызганычка каршы, татарлар арасындагы надан фанатиклар һәр яңалыкка каршы төшәләр. Алар, халыкны буйсындырып тоту өчен, мәктәп-мәдрәсәләрдә феодализм схоластикасына корылган шәригать законнарын гына өйрәтүне яклап чыгалар. Ә хатын-кыз, янәсе, ирләр белән бертигез була алмый, хатын-кыз физик яктан да, акыл ягыннан да, имештер, ирләрдән ким. Шунлыктан ул иргә берсүзсез буйсынырга тиеш. Хатын-кызның җәмәгать урыннарында ачык йөз белән күренергә, укырга, язарга, фән-сәнгать белән кызыксынырга, эшкә керергә хакы юк, дип раслана.

1905 елгы революция чорында, башка бик күп төрле прогрессив хәрәкәтләр белән берлектә, татар кызлары өчен булган мәктәпләргә

яңалыклар кертүне яклаган хәрәкәт җәелә. Шул чорда байтак урыннарда татар телендә чыга башлаган газеталар да бу мәктәпләргә яңа уку тәртибе кертү һәм гомуми-дөньяви белем бирү кирәклеген язып чыгалар.

Кайбер шәһәрләрдә татар кызлары өчен яңа типтагы мәктәпләр ачыла башлый. Шундый мәктәпләрнең берсе Казан шәһәрендә Фатиха Аитова мәктәбе була.

# ИЗУЧЕНИЕ ЖИЗНИ И ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ВЫДАЮЩИХСЯ ЗЕМЛЯКОВ В ФОРМИРОВАНИИ СОЦИАЛЬНО АКТИВНОЙ ЛИЧНОСТИ ШКОЛЬНИКА

***Гизатуллина Рима Ильдусовна***
*учитель математики МБОУ*
*«Нурлатская СОШ ЗМР РТ»*

Воспитание патриотизма и гражданственности на примере сопричастности к судьбе своей Родины через изучение жизни и деятельности, выдающихся наших земляков – одна из основных задач моей педагогической деятельности. Поэтому при проведении внеклассных мероприятий, какой бы теме оно не было посвящено, включаю страницы о людях, которыми может гордиться наше село, наш край.

Начинаю краеведческую работу с учащимися с изучения родословной, истории своей семьи. При проведении цикла классных часов, посвящённых Великой Отечественной войне, ученики выяснили, какой след оставила война в жизни их семьи. Например, на классном часе «По страницам блокадной книги» они знакомятся с главами: «Враг у ворот», «В блокадном кольце», «Дорога жизни», «Город собирает силы», «Прорыв блокады».

Глава «Книга Памяти». Школьники с волнением и гордостью рассказывают о своих родственниках, принимавших участие в освобождении Ленинграда, свидетелях страшных дней блокады. В ходе поисково– исследовательской работы дети учатся сопереживать, гордиться, понимать души людей. Так рождается любовь к своей семье, малой родине, Отечеству.

Внеклассное мероприятие по математике «Математика без границ» раскрывает перед учащимися неограниченные возможности математи-

ки в нашей жизни. И математику творят люди, среди которых можно назвать великого математика Н. Лобачевского. В течение 40 лет он преподавал в Казанском университете, в том числе 19 лет руководил им в должности ректора. Среди плеяды этих выдающихся учёных – наш земляк доктор физико-математических наук, профессора Ильдуса Бариевича Хайбуллина.

Изучение исторического и культурного наследия родного края становится основой для гармоничного всестороннего развития личности школьника, создает тот нравственный стержень, который поможет юному человеку противостоять натиску бездуховности, сохранить чистоту души, богатые национальные традиции родного народа.

Богат наш край талантливыми людьми. Писатели, поэты, музыканты, артисты, учёные, государственные деятели. Вот только некоторые из них:

**Каюм Насыри** – выдающийся просветитель, ученый-мыслитель, педагог, общественный деятель.

**Ваисов Сардар (Гайнанутдин)** (1878– 1918) – руководитель национально – освободительного движения, борец за восстановление Булгарского государства.

**Ганиев Виль Халимович** – литературовед, переводчик, заслуженный работник культуры Российской Федерации.

**Валеев Рамзи Калимович** – доктор исторических наук, профессор, заслуженный деятель науки Республики Татарстан.

**Саттаров Гумар Фаизович** – языковед, доктор филологических наук, профессор, Заслуженный деятель науки ТАССР.

**Айдарский Газиз (Газиз Исхакович Валитов)** – актер, режиссер.

**Альмеев Усман Гафьятович** – певец, народный артист ТАССР. Мухамедов Ирек Джавдатович – заслуженный артист РСФСР, солист Большого театра в Москве, с 1990 года – Королевского балета Великобритании.

**Шамов Афзал Шигабутдинович** – талантливый прозаик, публицист, переводчик, общественный деятель, член Союза писателей СССР. Сафиуллин Юнус Габдулович – драматург, заслуженный деятель искусств РТ.

**Зариф Фирдаус** – писатель-прозаик, переводчик, публицист.

**Шафигуллин Фаиль Хафизович** – знаменитый поэт, писатель, сатирик. Асадуллин Абдулла Шагеевич – педагог-методист, доктор педагогических наук, профессор, Заслуженный деятель науки Республики Татарстан.

Мы гордимся ратным подвигом нашего земляка Героя Советского Союза Хайруллина Халила.

Чем раньше ребенок приобщится к краеведению, тем сильнее будет его любовь к малой родине, к ее истории, культуре, традициям.

# МӘГЪРИФӘТ ЙОЛДЫЗЛЫГЫНДА

***Гыймадиева Гүзәл Илдус кызы***
*Казан шәһәре Киров районы*
*4 нче интернат-гимназия, китапханәче*

Яшь буынны туган телендә сөйләшүче, халкын сөюче, аның чын тарихын өйрәнүче, үз милләтенең мәнфәгатләрен кайгыртучы, белемле буын итеп тәрбияләү эшен халык педагогикасынынннан, аның хәзинәләреннән, мирасыннан башка күз алдына да китерү кыен . Шуңа күрә дә безгә мөгаллимлек эшен шул юнәлештә алып барырга, тормышка ашырырга теләсәк, татар мәгарифенең күп гасырлык бай тарихын белү, беренче мәгърифәт карлыгачларыбызның тәҗрибәсеннән файдалану зарур. Төрек бабаларыбызның 4 гасырда ук укый-яза белгәннәре тарихта мәгълүм. Уку-укыту эшләре дә бик күптәннән, х гасырда, ислам дине кабул ителеп, мәчетләр һәм алар каршында мәктәп-мәдрәсәләр ачылгач ук тәртипкә салына. Тарихчыларыбызның тикшерүендә Болгар хатын-кызлары арасында гыйлем ияләре, галимнәр дә күп булган. Болгар сүзенең мәгънәсе – белемле кеше.

Белемле кешене алар “Беләр” дип атаганнар, шуңа күрә бу илне гарәп теленә яраклаштырып Болгар дип йортә башлаганнар. Шундыйларның берсе хан нәселеннән булган Туйбикә абыстай. Аны хермәт йозеннән олылап “Ана” дип йөрткәннәр. Болгарда ул төрле илләрдән килгән кызлар укыган мәдрәсә токан. Ул мәдрәсәне “алтмыш алты абыстай мәдрәсәсе” дип йөрткәннәр ди. Ул изге абыстайлар булган ди. Туйбикә әмере белән, бу алтмыш алты абыстай, алтмыш алты якка таралып, күп халыкны хак юлга күндергәннәр.

Болгар халкының азатлык керәшендә катнашып исеме легендага әйләнгән Гайшабикә образын искә алмыйча булмый. Иске Казан урыныннан ерак түгел Татар Әйшәсе авылына әле дә аның каберен эзләп “изге Гайшәбикә”гә дога кылулары гаҗәп түгел...

Казан ханлыгы буйсындырылгач, халыкның мөлкәте талана, китаплар утка ягыла, мәктәп-мәчетләр җимерелә, алар урынына чиркәү-монастырьлар корыла. Изелеп яшәгән татар мадәниятен һәм мәгарифенең үстерү турында сүз дә алып барырга мөмкин түгел. 1804 елда Рәсәйнең көнчыгышында иң зур фән һәм культура үзәге булган Казан университеты ачыла. Яңару, уяну хәрәкәтенең беренче карлыгачлары булып югары күтәрелгән татар культура, мәгариф, әдәбият эшлекләре яңалыкларга, төрле юнәлешләргә юл ярырга омтылалар. Университетта татар телен

укыту кертелә, шунда эшкә чакырылган бер теркем татар укымышлылары барлыкка килә. Алар арасында иң беренче урында Ибраһим Халфин (1778-1829) тора. Ул 1819 елда "Татарларны мәгърифәтле итү" проектын төзи.

XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән милли уяну дәвере хатын-кызларга да бер этәргеч була. Кыз балалар өчен мәктәпләр ачылу барыннан да бигрәк киң таралган җәдитчелек хәрәкәте белән дә тыгыз бәйләнгән. Кызлар мәктәпләренә беренче нигез салуга да җәдид муллалар, аларның абыстайлары катнаша. Казанда исә, ир балалар өчен беренче җәдид мәктәбен 1889 елда күренекле дин белгече,мулла һәм мөдәррис Галимҗан Баруди ачса, кыз балалар очен беренче мәктәпкә 1890 елда аның хатыны Маһруй абыстай нигез сала.

Инде Оренбург, Троицк шәһәрләренә чыксак, xx гасыр башында алтмышлап мәктәп-мәдрәсәләр ачкан, кырыктан артык мөгаллимгә хезмәт хакы түләгән һәм дистәләрчә татар яшьләренә чит илләрнең югары уку йортларында белем алырга ярдәм иткән атаклы Хөсәеновлар, Яушевлар, Екатеринбургтагы бертуган Агафуровлар.

Агафуровлар ярдәме белән Екатеринбургта кызлар өчен мөселман мәктәбе ачканнар. Аның хәйриячесе булып Зәйнетдин Агафуровның тормыш иптәше Әсма Садыйк кызы Агафурова чыга. Бу мәктәпләрне 20 ел буена алар үз хисапларына асрап 100000 меңнән артык акча сарыф иткәннәр. Алар белән бергә янәшә тарихта матур эз калдырган мөхтәрәмә хатын-кызларыбызның исемнәре дә бар: Мохәммәдия мәдрәсәсен зурайтыр очен 2000 сум акча биргән Махруй исхак кызы (Г. Барудиның хатыны) – олуг затларның берсе.

XVIII гасыр ахырында – xx гасыр башында Мәскәү, Петербург шәһәрләрендә татарларның саны күренеп арта бара. Мәскәүнең татар бистәсендә 1811 елда 225 татар яшәсә, 1871-1912 елларда аларның спны 5300 гә кадәр җитә. Мәскәүдә Сәлих Ерзин, Мөхәммәдрәхим Исаков, Муртаза Дәвишев исемле 1,2 гильдия сәүдәгарләре дан тоткан. Татарланың саны Мәскәүдә артына 1813 елда анда мәчете төзелүе сәбәп була. Бу мәчетне үзенең акчасына сәүдәгар Кастров төзи.

Татарлардан беренче хатын-кыз библиогрф та Таһирилар нәселеннән чыга. Ул – Шакирҗан Таһириның кызы-Суфия. Суфия Шакирҗан кызы Таһирова 1888 нче елның 25 ноябрендә туа. Ул Укытучылар мәктәбенә имтиханнарны экстерн тәртибендә бирә. Шул рәвешле, әтисенең юлын дәвам итеп, тормышын укытучылык эшенә, балалар тәрбияләүгә багышлый. 1904 нче елда Казанда кыз балалар өчен ачылган Ләбибә Хөсәенова мәктәбендә Суфия Таһирова рус теле, арифметика һәм география дәресләрен алып бара. Кызларны кул эшенә өйрәтүне дә үз өстенә ала.

Ул анда 1918 нче елга кадәр эшли. Суфия Таһирова эш тәҗрибәсеннән чыгып, дәреслекләр дә язган. Безгә аның энесе Фаик белән чыгарган “Безнең әлиф” дип аталган әлифбасы билгеле. Әлифбада төсле рәсемнәр урын алган, ә сүзләр латин шрифты белән язылган. Рәсемнәре дә көнкүрештән алынган: шырпы, сәгать, әтәч һ.б. Әле искә алынган Троицк сәүдәгәрләре Яушевлар гаиләсендә туып үскән Фатыйха Аитованы онытып буламы.. Ул Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыкканда, үзенә гаиләдән бирелгән малны кызлар мәктәбе ачуга сарыф итү белән генә калмыйча, Казанда әле татарның ир балаларына өчен дә гимназия ачыла алмаган бер вакытта, ягъни 1916 елда, шул мәктәпне милли кызлар гимназиясе дәрәҗәсенә кадәр үстерә. Бу гимназиядә Махруй Мозаффария, Мөхетдин Курбангалиев. Соңыннан Аитова мәктәбе директоры һәм математика укытучысы, Париждагы Сорбонна университетын тәмамлап кайткан Сара Шәкулова кебек ул заманның күренекле кешеләре укыта. Франциядә, данлыклы Сорбонна Университетында белем алган Сара Касыйм кызы Шакулова турында әйтәсе килә . Шакуловлар – Россия татарлары арасында билгеле нәсел. Аларның шаҗәрәсе Мөхәммәд пәйгамбәр нәселенә барып тоташкан. Ягъни, тамырлары 5-6 гасырга ук киткән. Бу нәсел пәйгәмбәр оныгы Хөсәен тармагына караган, һәм сәет атамасын йөртергә хокуклы булган. 45 нче буынга карган булган. Руслар арасында тормыш көткән, Касыйм татарлары, шулар исәҗеннән Шакуловлар нәселе дә мәдәнияткә иртәрәк якыная башлаганнар. Татар кызларыннан беренче табибә Разия Котлыярованың Касыйм шәһәре кызы булуы очраклы хәл түгел. Сара Шакулова атаклы Фатыйха Аитова мәктәбендә һәм Ләбибә Хөсәениянең мөгаллимәләр әзерли торган кызлар мәктәбендә геометрия укыткан. 1925 елда ул атаклы Асадуллаев йортында урнашкан беренче татар мәктәбен оештыручы һәм аның беренче җитәкчесе була.

Татар халкының яңаруы аның рухи яктан сәламәтлендерүе аша гына мөмкин. Аның күңелен ялганнан, комсызлыктан арындырып кына без телебезгә, мәдәниятебезгә карата мәхәббәт тәрбияли алабыз. Ләбибә Хөсәения мәктәбе 1904 елда яңа укуты методикалы булып кызлар өчен ачыла. Ләбибә Хөсәения 7 декабрьдә 1880 елда Чистай районының Әмзә авылында мулла гаиләсендә туа . Ләбибә яшь кызларга белем бирүне беренче бурыч итеп санап үсә. Шул теләген тормышка ашырыр өчен, уналты яше тулгач ук Гурьевка дигән җиргә миллионер Акчуриннарның кызлар мәктәбендә укыта. Галимҗан хәзрәт чакыруынча Казанга барып Махруй атыстай белән балаларны укыта башлый. Ләбибә бөтен мәхәллә байларыннан үз өенең ишегалды түренә кызл ар укыту өчен мәктәп салдырып бирүгә ирешә. Фәкыйрь балалар бушлай укытыла.

Ләбибә Хөсәениянең зур теләге – үзенең мәктәбен татар мөгаллимәләре әзерләп чыгара торган уку йорты итеп үстерү. Ул данлыклы Мөхәммәдия мәдрәсәсеннән яшертен генә мөгаллимнәр чакыртып, кызларның белемнәрен күтәрү өчен Укытучылар әзерләү курсларын оештыра. Ләбибә Хөсәения мәктәбе милләтебез өчен бик кирәкле сәләтле яшь буынны тәрбия итәрлек белемле, мәдәниятле аналар тәрбияләде. Ул аналарның күбесе үзләренең кызларын, оныкларын халкыбызның күренекле кешеләре булырлык итеп тәрбияләп үстерделәр.

## ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ МИЛЛИ АГАРТУ ЮЛЫНДА

***Исхакова Лилия Шәүкәт кызы***
*Казан шәһәре 177нче урта мәктәбенең*
*милли эшләр буенча директор урынбасары,*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Татар мәдәниятенең күп гасырлык тарихы бар. Ләкин, кызганычка каршы, без әле бүген үзебезнең рухи мирасыбызны тиешле дәрәҗәдә тирән беләбез дип горурлана алмыйбыз. Моны истә тотып, милләтебезнең асыл затларын барлау һәм аларның халкыбыз тарихында тоткан ролен, бөеклеген исбатларга тырышып карыйк.

Күренекле галим, укытучы-педагог һәм әдип ***Каюм Насыйри*** татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнады. Аның иң беренче хезмәте – «Нәхү китабы», ягъни татар теле синтаксисы (1860). Русча өйрәнүче татарларны, татарча өйрәнүче русларны күздә тотып, бу дәреслек рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип аталган. Текстларда татарча һәм русча китерелгән сүзлек бирелгән. Шул ук елда аның «Буш вакыт» исемле китабы да басылып чыга. Бу хезмәтендә автор балаларны һәм дөньяви фәнннәрдән башлангыч белем алучыларны анатомия, табигать белемнәреннән кыскача мәгълүматлар белән таныштыра.

Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең тагын да бер асыл заты, фәлсәфәче, тарихчы, дини ислахчы – ***Шиһабетдин Мәрҗани***. Мәрҗани әле этнограф та, археограф та, шәркыят галиме һәм мөгаллим дә. Унҗиде яшендә инде ул мәдрәсәдә укыта башлый һәм, фарсы теле морфоло-

гиясе дәреслеге белән канәгать булмыйча, үз дәреслеген төзи. Мәрҗани татар халкының этногенезы проблемаларына мөрәҗәгать иткән беренче татар тарихчысы иде.

Күренекле мәгърифәтче ***Ризаэддин Фәхреддин*** турында да мәгълүмат биреп китү урынлы булыр. Мәдрәсәнең өлкән сыйныф шәкерте булганда ук Ризаэддин үз хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә: башлангыч сыйныф балаларын укыта. Дөньяви фәннәр укытуы, укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануы белән ул бик тиз танылып өлгерә. Гомумән, бу һөнәренә гомере буена тугрылыклы булып кала.

Р. Фәхреддин үзенең әсәрләрендә, милләтне аң-белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Дини белемнәр белән бергә фәнни белемнәрне үзләштерү, укыту-тәрбия ысулларын үзгәртеп кору һ. б. төрле фәннәр белән бик нык кызыксынган һәм алар буенча күп санлы һәм кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган.

***Йосыф Акчура*** – татар халкының танылган иҗтимагый-сәяси эшлеклесе, галим, сәяси төркичелеккә нигез салучыларның берсе, татар һәм төрек милләтләренең барлыкка килүенә гаять зур өлеш керткән кеше. Ул Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих һәм география укыта башлый. Әлеге мәдрәсәдә укыган лекцияләре базасында берничә китап бастыра. 1905 елның көзеннән «Казан мөхбире» дигән беренче татар газетасы чыга башлый. Аның нашире – присяжный поверенный Сәетгәрәй Алкин, ә редакторы Йосыф Акчура (Б. Шәрәф белән бергәләп) була.

***Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы)*** педагог, яңа метод (ысулы җәдит) белән укытуга нигез салучы һәм «Тәрҗеман» исемле гомумтөрки газетаны чыгара башлаучы журналист буларак мәгълүм. Ул беренче тапкыр, бай кешеләрне җәлеп итеп, җәмгыяте хәйрияләр оештыра. Мәдрәсәдә эшләгәндә һәм югары мәктәпнең камил булмавын күреп, ул мөселман мәктәпләрен үзгәртеп кору зарурлыгына инана.

Милләтебезнең асыл затлары – ***бертуган Рәмиевләр***. Алар да татар халкының милли үзаңын формалаштыруда, әдәби һәм мәдәни тормышын баетуда гаять зур урын билиләр.

Рәмиевләр күченеп утыргач, Юлык авылының йөзе үзгәрә. Алар иң әүвәл таштан зур иттереп үләренә йорт-җир җиткерәләр, кибетләр ачалар. Эшләре алга киткән саен, авылга ярдәмнәрен дә арттыра баралар. 1898 елда мәһабәт итеп таш мәчет торгызалар. Авылда зур мәдрәсә ачалар, озак та үтми, русча укыта торган мәктәп салалар. Хәлфәләрне, укытучыларны үз исәпләренә тоталар. Юлык тарихындагы беренче китапханәне дә алар нигезлиләр.

***Дәрдемәнд (Закир Рәмиев)*** матди байлыгының да шактый өлешен милләтебезне аң-белемле, мәдәниятле итүгә тота. Шагыйрь булмыйча, бары тик татар халкына күрсәткән игелекләре өчен генә дә Закир һәм аның абыйсы Шакир Рәмиевләр рәхмәт хисләре белән тәкъдир ителергә тиешләр.

1906 елда ***Шакир белән Закир Рәмиевләр*** «Вакыт» газетасын, 1908 елда «Шура» журналын чыгара башлыйлар. Шулай итеп, бертуган Рәмиевләр – татар мәдәнияте тарихында якты эз калдырган, исемнәре хөрмәт белән искә алынырга тиешле шәхесләр. Алар нәшир иткән газета-журналларның татар вакытлы матбугатын, әдәбиятыбызны һәм иҗтимагый фикерне үстерүдә өлешләре бик зур. ***Сәгыйть Рәмиев*** – үз заманының актив җәмәгать эшлеклесе, халыкның иҗтимагый аңын үстерүгә зур өлеш керткән, мәдәниятебезне чәчәк аттыру өчен ихлас янып-көеп яшәгән шәхес. Шунысына игътибар итәргә кирәк, кайсы гына гәзиттә эшләмәсен, С.Рәмиев аның телен, төрек йогынтысыннан арындырып, халыкка якынайту гамәленә керешә.

Соңгы елларда исемнәре һәм иҗатлары туган иленә әйләнеп кайткан зыялылар арасында ***Гаяз Исхакый*** исеме аеруча мөһим урын алып тора. Төрек-татар халыклар азатлыгы, матур тормышы һәм социаль тигезлеге өчен гомеренең алтмыш елын багышлаган бу олуг шәхес татар тарихында тирән эз калдырган. Г. Исхакыйның милләт язмышы өчен көрәше язучы, мөхәррир һәм сәясәтче буларак эшчәнлегендә төп максат булып тора.

Бүген әлеге кешелекле сыйфатларга ия булган кайбер шәхесләребезнең кәркәм эш-гамәлләре, милләт файдасына башкарган омтылыш-теләкләре турында фикер йөрттек. Андый шәхесләребез, иншалла, бөген дә байтак. Изге эшләр безнең милли йөзебезне, татарлыгыбызны билгели торган гамәлләр булып калсын, мәңге янәшәбездә булсын иде. Бердәм халык, зиһенебез сау-сәламәт булганда гына без бер йодрык – җиңелмәс милләт! Үткәннәргә карап гыйбрәт алыйк!

# КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕ, ДИН БЕЛГЕЧЕ ГАЛИМҖАН БАРУДИНЫҢ МИЛЛИ МӘГАРИФ ҮСЕШЕНДӘ РОЛЕ

***Миннеханова Энҗе Рафыйкъ кызы***
*Казан шәһәре Совет районы*
*“156 нчы урта гомуми белем мәктәбе”*
*гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*
*1нче категорияле татар теле*
*һәм әдәбияты укытучысы*

Татар мәгрифәтчелегенең күп гасырлык тарихы бар. Ләкин, кызганычка каршы, без әле үзебзнең рухи мирасыбызны тиешле дәрәҗәдә тирән беләбез дип горурлана алмыйбыз. Аның сәбәпләрен санап чыксаң, минем чыгышымның чиге булмас иде. Ләкин иң җитди сәбәпләрнең берсен атап китмичә булмас. XVI гасырның икенче яртысында татарлар дәүләтләре белән бергә үзләренең бай рухи мирасларын саклау һәм яңа мәдәни җәүхәрләре булдыру мөмкинлекләрен дә югалттылар. Рухи байлыгыбызның күбесе эзсез югалды. Татар җәмгыяте мескен хәлгә төшә. Аның зыялылары юкка чыгарылды. Яңадан югары мәдәниятле халы булыр өчен күп гасырлар үтәргә кирәк була. Россия дәүләтендә үзләренең законлы урынын аныклу өчен көрәшкә басалар. Бу көрәш– милләт бердәмлеген кайгырту, аның рухи нигезе булган ислам динен саклау, халыкны агарту, аның үзаңын һәм иманын ныгыту булып тора. Көрәш юлы безне бүгенге көн милли мәгрифәтенә, мәдәниятенә китереп җиткерә. Бу көрәш юлында күпкенә мәгрифәтчеләрнең, реформаторларның өлешләре бик зур. Аларның барсы турында сөйләп чыгып бетереп булмый. Шулай да бу чыгышымда эчке Руссия татарларының иң мәшһүр һәм атаклы мәдрәсәләреннән берсе, асылда милли университет вазифасын үтәгән “Мәдрәсәи Мөхәммәдия” не аның нигез ташларын салучысы, җитәкчесе, мөдәррис Галимҗан Галиев-Баруди исеменә тукталмый мөмкин түгел. Ул XIX йөз ахырларында ук күренекле мәгърифәтче, дин белгече һәм реформаторы, философ, педагог буларак, дистәләрчә китаплар язып бастыра. 2011 елда бу олпат шәхеснең дөньяга килүенә -155 ел, ә аның данлыклы Мөхәммәдия» мәдрәсәсе оешуга 130 ел тулды.

Г.Барудиның кылган гамәлләре колач җитмәстәй зур. Чыгышымның төп максаты мәгърифәтченең тормыш юлын эзәрлекләп, ул нигез салган “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең милли мәгариф үсешендә ролен ачыклау булып тора.

Галимҗан мәдрәсәдә алырга мөмкин булган белемнәренең барсында ала. Ул үз белемнәрен камилләштерүнең яңа юлларын эзли башлый. Ул 1875 елда белемен тирәнәйтү өчен, Бохарага китә. Анда “Мир-гәрәб” мәдрәсәсендә 7 ел укып, өйрәнелә торган барлык фәннәрне үләштерә.

Ачылган вакытында “Мөдрәсәи Мөхәммәдия” башка иске тәрдәге уку йортларыннан берни белән дә аерылмый диярлек, фәкать гарәп теле һәм дин дәресләре генә яңа баскычка куела. Галимҗан Баруди һәм аның фикердәшләре тырышлыгы белән “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе XX йөз башларында һәр җәһәттән уңышлар казана. Мәгърифәтче үзенең мәдрәсәсендәге эшчәнлеген тагын да камилләштерә, аның программасына дөньяви фәннәрне тагын да күбрәк кертергә омтыла. Нәтиҗәдә, “Мөхәммәдия”дә киң планда “төрки”, ягъни татар, рус, гарәп фарсы телләре, арифметика, алгебра, Русия тарихы, төрки кавемнәр тарихы, гомуми тарих, ислам тарихы, физика, гарәп әдәбияты, фәраиз (мирас бүлү фәне), әхлак, гигиена, ритмика, риторика, психология, логика, философия, методика, педагогика һ.б. предметлар укытыла. Яңадан 1993 елдан эшли башлауга мәдрәсәнең Ислам хәрәкәте һәм гарәп теле факультетында ир-егетләр өчен имам-хатыйб, мөдәррис, гарәп теле укытучысы, хатын-кызлар өчен гарәп теле мөгаллимәсе һәм тәрҗемәче белгечлекләрен әзерләү яңа шартларда дәвам итә.

XIX-XX гасыр башында татарлар өчен мәдрәсәләр бердәнбер белем, гыйлем алу чыганагы булган. Аларда дини дәресләр белән беррәттән дөньяви фәннәр дә укытылган. Әлбәттә, хәзерге мәдрәсәләрдә дә төп игътибар дини белем бирүгә бирелә. Тик бүгенге заман шартларында кеше күп төрле дөньяви белемгә дә ия булырга тиеш. Шуңа күрә мәдрәсәдә филология һәм педагогика, гарәп, инглиз, татар теле, әдәбияты, тарихы кебек фәннәргә зур урын бирелә. Бүген мәдрәсәдә Татарстанда гына түгел, Россия төбәкләрендә яшәүче татар малайлары һәм кызлары да белем ала. Мәдрәсәне тәмамлаучылар ислам шәригате һәм гарәп теле, ислам фәннәре һәм әхлагы дигән белгечлек алалар. Дәресләр нәкъ үзебезчә татар телендә үтә. Минемчә, нәкъ татар телендә укытулары белән ул бик тә якын һәм кадерле. Татар халкы болай да бик авыр язмыш узган, кимсетелеп яшәгән. Хәтта белем алу өчен дә мөмкинлекләр булмаган. Ул вакытларда мәдрәсәдә дини белемнәр белән беррәттән дөньяви гыйлемнәрдә бирелгән. Димәк, мәдрәсә татар халкының үзаңын үстерүдә, дөньяга карашын киңәйтүдә һәм динле, иманлы итеп тәрбияләүдә зур урын алып тора.

# РАЙОНЫБЫЗ ҖИРЛЕГЕННӘН ЧЫККАН ПЕДАГОГ-МЕТОДИСТ

***Мәрьям Галләмова***
***Рәхимова Гөлүзә Әзһәм кызы***
*Сарман муниципаль районы*
*«Саклау-Баш урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халыкның көче турында сөйләгәндә, ул халык аралаша торган тел беренче урынга куела. Телне саклаучы булып халык саналса да, аны билгеле бер нормаларга салып камилләштерү эшен, эзлекле система белән өйрәнү методикасын тел галимнәре башкара. Татар халкын илгә, дөньяга таныткан шәхесләр Сарман төбәгеннән дә аз чыкмаган. Алар: Гали Чокырый, Фәрит Яхин, Флера Илдарханова, Саимә Ибраһимова, Зарипов Марсель, Мәрьям Галләмова, Дамир Гарифуллин һ.б. Без татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфлары өчен “Туган тел”, “Татар теле” дәреслекләре һәм йөзләгән методик кулланмалар язган Галләмова Мәрьям Шакир кызы мирасын өйрәнергә булдык.

Мәрьям Шакир кызы Галләмова, 1902 елның 4 февралендә, хәзерге Сарман районына кергән Саклау-Баш авылында урта тормышлы крестьян гаиләсендә бишенче кыз бала булып дөньяга килә. Әниләре 12 кыз бала тапкан булса да, аларның күбесе кече яшьтә үк үлә. Бары бишесенә генә исән калырга насыйп була. Мәрьямгә 7-8 яшьләр тирәсендә, авылның мөәзине үлгәч, Шакир абзыйны аның урынына куялар. Ул, революциядән соң, озакламый мөәзинлеген ташлап, бары крестьян гына булып яши башлый. Авылда күмәкләшү башлангач, колхозга кереп, төрле эшләрдә эшли. Шакир абзый бәхетле заманалар якынаюын тоемлый. Революциягә кадәр хатын-кызлар бөтен хокуклардан мәхрүм булаганлыктан, аларга җир бирелми. Шакир абзый гаиләсенә дә бер “җан” җир белән яшәргә туры килә. Әлбәттә, тормыш җиңелдән булмый. Шунлыктан балалар азрак үсә төшү белән, аларны әниләренең туган авылы хәзерге Мөслим районындагы Салавуз-Мухан авылына бабаларына озата торган булалар. Мәрьям Шәмсия исемле апасы белән шул авылда диярлек үсә.

1910-1911 елларда биредә кыз балалар өчен Җәдит мәктәбе ачыла. Алар апасы белән башлангыч мәктәпне шушында тәмамлыйлар. Аннары хәзерге Сарман районы Мортыштамак кызлар мәктәбенә – Хәдичә Буби мәктәбенә укырга күчәләр. Биредә Иж Бубидан килгән

мөгаллимнәр һәм мөгаллимәләр дәрес бирәләр. Кызлар 1917 елны урта мәктәпне тәмамлыйлар. Мәгърифәтче кызлар бередән мәгариф юлына чыгалар һәм гомер буе шул юлда халыкка хезмәт итәләр. Алга китеп шунысын да әйтик: Шәмсия Шакир кызы 42 ел башлангыч мәктәптә укыта. Татарстанның атказанган укытучысы дигән исемгә лаек була, Ленин ордены белән бүләкләнә. Октябрь революциясе Мәрьямнең хыялларын чынга ашыра. Аңа якты юл ача. Ул үзенең хезмәт юлын туган авылы Саклау-Башта, 1917 елның көзендә, кыз балалар укытудан башлый.

1918 елның җәендә, Минзәлә шәһәрендә укытучылар хәзерләү өчен 3 айлык курслар ачыла. Мәрьям дә, апасы да бу курсларда укып, укытучылыкка имтихан тапшырып, таныклык алалар. Ул елларда Совет хөкүмәте, авыл һәм шәһәрләрдә яшәүче хезмәт массаларының наданлыгы белән көрәшү өчен, һәр урында грамота мәктәпләре ача. 1918 елның көзендә Мәръямне Минзәлә өязенә керә торган Наратлы Кичү авылына өч комплектлы мәктәпкә мөдир итеп билгелиләр. Бу эшкә керешкәнче, аларның кулларына, укып танышу өчен, В.И.Ленин тарафыннан язылган “Мәктәпләрне мәчетләрдән, чиркәүләрдән аеру турында” дигән декрет бирелә. Совет мәктәбен ничек оештыру турында инструктаж үткәрелә. Шулай итеп, Мәрьям 120 балага җитәрлек дәреслек, уку-язу әйберләрен 2 олауга төяп, классларны җиһазлау өчен кулына документ алып, яңа мәктәп оештырырга китеп бара. Ул, коллегалары килгәнче, халык салдырган элеккеге дин мәдрәсәсен, авыл мулласы белән сөйләшеп, килешеп (аларга шулай кушылган була) ала, тагын 2 урында баерак тормышлы кешеләрнең 2 өен алып, 2 класс итеп хәзерли. Бу эшне башкаруда аңа яңа гына оешеып килә торган ярлылар комитеты әгъзалары булыша. Аннан волость үзәге Станково авылына барып, кулындагы документ белән, класс такталары, парталар алып кайта һәм утын мәсьәләсен хәл итеп куя.

Уку елының беренче яртысын тәмамлаганда, өяз мәгариф бүлегеннән килгән инструктор П.А.Мутин да аларның мәктәбен өяздә яңа ачылган мәктәпләр арасында иң дөрес һәм яхшы оештырылган дип таба. Шуның өчен Мәрьям Шакир кызына мәгариф бүлеге приказы белән беренче мәртәбә рәхмәт белдерелә.Бу вакытта алар мәктәп, укыту эшеннән тыш театр оештыру эше белән дә шөгыльләнәләр Каршы көчләр күп була, ләкин төрле авыллардан театр карарга килүчеләр саны арта бара. Бу эшне оештырып йөрүдә волость военкомы Р.Н.Нәбиуллин җитәкчелек итә. 1919 елның март ахырларында, Станково авылында театр куйганда, Минзәлә шәһәренә Колчак гаскәрләренең бәреп керүләрен хәбәр итәләр. Театр куючылар авылларга таралалар. Ләкин авылда да аларның кайтуын

көтеп торалар инде. Мәрьям укыта торган авылыннан качып, туган авылына кайтып китә. Колчак килгәч, кулаклар баш калкыталар. Мәрьям кебек совет укытучыларына һөҗүмнәр башлана. Ул туган авылына кайтуга ук, Колчак штабына хәбәр иткән булалар. Салкын көннәрнең берсендә, үзен алырга киләселәрен сизенеп, качып өлгергән Мәрям төне буе салкында ялангач йөреп, бик нык салкын тидерә. Бу көнне аларның авылыннан бик күп гаскәр үтә. Бер куштаны үтеп баручы солдатларга аның турында хәбәр итә.Аны өйләреннән алып чыгып, салкын сарайга ябалар. Шул көнне Колчак гаскәре авылга ялга туктый. Мәрьямнән әллә ничә мәртәбә сорау алалар: ”Син коммунистмы? Авылда коммунистлардан кемнәр бар?” Төн җиткәч, туганнан туган абыйсы һәм иптәшләре аны качыралар: Салавузга озаталар. Ул монда, кызыллар килгәнче, 17 көн базда яшеренеп ятарга мәҗбүр була һәм сәламәтлеген нәкъ менә шунда югалта да инде. М.Ш.Галләмовага соңыннан 25 ел буе Казан тубдиспансерында учетта торып дәваланырга туры килә. 1919-1920 елларда Мәрьям Шакир кызы Саклау-Баш авылыннан ерак түгел Иске Имән авылында укыта. 1920 елның язында кулак фетнәсе-сәнәклеләр кузгалышы була. Ул үзе белән бик күп кайгы-хәсрәтләр, фаҗигаләр алып килә. Мәрьям мең бәлаләр белән качып китеп, эвакуацияләнүче гаскәрләргә кушыла.1920 елда, кантонда беренче буларак, Теләнче Тамак авылында икенче баскыч мәктәп оештырыла. М.Ш.Галләмованы шунда укытырга күчерәләр. 1922 елда Минзәләдә районара партия мәктәбе ачыла. Ул шунда укырга китә. 1922-1925 елларда партия мәктәбенең үзендә эшли, коммуна мәктәбендә укыта. Минзәлә шәһәре аның хезмәт юлында бик кадерле, бик яхшы истәлекләр калдыра. Ул Совет укытучысы дигән мактаулы исемне шушында ала. Совет мәктәбенә беренче адымны шушыннан башлый: Совет партия мәктәбендә укып, шунда политик белемен күтәрә, шунда комсомолга керә, комсомол – яшьләр һәм хатын-кызлар арасында ялкынлы пропагандист булып эшләргә өйрәнә. 1925 елны Минзәлә канткомы М.Ш.Галләмованы Казанда обком тарафыннан оештырылган пропагандистлар хәзерли торган 6 айлык курсларга укырга җибәрә. Биредә аларны комуниверситет укытучылары укыта. Хатын-кызлар икәү генә була. 1925-1928 елларда ул совпарт школада эшли. 1929 елны Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керә. Аны 1932 елның җәендә тәмамлый. Институтта укыган вакытта ук инде аңа эшләргә туры килә: Казан горроносы каршында зурлар өчен кичке мәктәпләр, производствода эшләүчеләр өчен Октябрь мәктәпләре оештыручы инспектор булып эшли. Соңрак мех һәм силикат техникумнарында, пединститутның физкультура бүлегендә җәйге курсларда укыта.

Институт тәмамлап диплом алгач, М.Ш.Галләмованы Казан педтехникумына татар теле, әдәбият, методика укытучысы һәм педпрактика җитәкчесе итеп билгелиләр. Ул анда 1932-1939 елларда эшли.

1939 елда минпрос аны ТИУУга методист итеп күчерә. М.Ш.Галләмова биредә пенсиягә чыкканчыга кадәр эшли. 1932 елдан башлап нәшриятта рецензия, редакция эшләренә катнаша башлый,газета-журнал битләрендә мәкаләләре басылып чыга. Институтта эшләгән елларында университетның татар теле факультетында да методикадан укыта һәм практикага җитәкчелек итә. Сугыш елларынды ук инде көн тәртибенә дәреслек төзүнең кирәклеге килеп баса, чөнки күренекле галим Мөхетдин Корбангалиев төзегән “Туган тел” дәреслеге күләме ягыннан бик кечкенә була. Бу эшне Мәрьям Шакировна башкарып чыга.

1940 елдан башлап методика өлкәсендә кулланмалар төзеп, аларны нәшриятта бастырып чыгару эшенә керешә. Ә шушы елны беренче китапчыгы “Укучыларның өлгерешен бәяләү нормалары” басылып чыга. “Башлангыч мәктәптә татар теле укыту методикасы” дигән зур күләмле хезмәте эшләнеп бетә. Аны профессор Мөхәммәтхан Фазлуллин махсус редактор буларак, бик җентекләп редакциялогәч, 1940 елда басмага бирә. Методик китаплардан “Укучыларның сөйләм телен үстерү методикасы”, “Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы”, “Аз комплектлы мәктәптә бер укытучының берьюлы берничә класс белән эшләве” һ. б. хезмәтләре басылып чыга. М.Ш.Галләмовага татар теле һәм аның методикасына караган бик күпләрнең хезмәтләрен редакцияләүдә һәм рецензияләүдә нәшрият һәм минпрос йөкләмәләрен бик күп башкарырга туры килә. Ул шулай ук «Совет мәктәбе” журналында бик күп еллар редколлегия члены булып татар теленә караган методик материалларның барысын да ул редакцияли. Чөнки ул вакытларда редакциядә ике өч кенә кеше эшләгән чор була.

М.Ш.Галләмова, туганннары әйтүенә караганда, 2001 елны 96 яшендә бакыйлыкка күчә.

# КОРЪӘН ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

***Салихова Рания Рәдиф кызы***
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*71 нче татар-рус гомуми урта белем бирү мәктәбенең*
*10-нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе:* ***Шафиева Гөлсинә Фазылҗановна***
*татар әдәбияты һәм татар теле укытучысы*

Төрки язма мәдәнияты 1500 еллап вакытны үз эченә ала. Шуның исә мең елдан артыгы мөселман дине белән мөнәсәбәтле.

Коръән – мөселманнарның изге китабы, Аллаһы тарафыннан Мөхәммәдкә күктән индерелгән дини ышанулар, әдәп кагыйдәләре, хокукый кануннар җыентыгы һәм гарәп әдәбиятының классик ядкәре. Коръән китабының күләме 500 бит тирәсе. Ул 114 сүрәдән гыйбарәт. Коръән текстының байтак өлеше рифмалашкан прозадан тора.

Коръәннең буеннан-буена бераллага ышану идеясе үткәрелә. Ул – барысын да яратучы, тиңсез.

Шәригать кануннары Коръәндә әхлакый кагыйдәләр, кешенең үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, фикерләве белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Биредә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый матур әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә.

Мөселманнарның дини тәгълиматында Коръән беренче һәм иң әһәмиятле чыганак булган һәм менә 14 гасыр дәвамында бу китап, дини чыганак буларак кына түгел, тарихи, әдәби чыганак буларак та, үзенең кыйммәтен югалтмый. Без моны татар әдәбияты мисалында да ачык күрәбез.

Коръән төрки-татар әдәбиятын мең ел буена тукландырып, аңа идея һәм сәнгать ягыннан төп юнәлеш биреп килә. Ул әдипләрнең дөньяга карашында төп фактор була. Мин үз алдыма шундый сорау куйдым: Алланы бер итеп карап, аңа сыену, аннан ярлыкау көтү, аңа табынуны кайсы шагыйрьләрдә, кайсы әсәрләрдә очратырга мөмкин? Һәм гаҗәеп нәрсә ачыкланды: теләсә кайсы каләм иясе аның берлеген, барлыгын, бөеклеген таныган.

Кандалый әсәреннән:

*Сәнеңчөн нә дәкле бән әйләдем зар,*
*Әгәр, ялган, дисәң, бер Ходаем бар!*

Ул аны Язмыш Алласы, Бәхет Алласы дип тә, бер Алланы күздә тота. Тукай шигыреннән бер өзек:

*Мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен.*

Тукай мирасында Бөек көчкә атап язылган шигырьләр аз түгел. Шуларның берсе «Аллага гыйшкына» дип атала. Бу шигырь алда китерелгәнгә бер ягы белән охшаш: анда да, Алла безне танысын, яратсын, бәхетле итсен өчен, начар сыйфатлардан арынып, үз милләтебезне алга илтүче уңай якларыбызны арттырыйк, идеясе бар.

Рефератымны Нәҗип Думавиның (1883-1933) татар укучысына язган «Син – кеше!» шигыре (1916) белән төгәллисем килә:

*Бирмә серне, бул гали – типсен йөрәк зурлык белән!*
*Булма мәхзүн – сынма төшенкелек белән, хурлык белән!*

*Бирмә тезгенне кара көчләргә – булма кол кеше!*
*Бул – батыр! Бул – нык кеше! Бул – ир кеше! Бул – хөр кеше!*

*Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын?*
*Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!*

*Син – бөек! Салган Ходай күктән сиңа үз орлыгын.*
*Бул – гали! Таптатма, зинһар, шул ходайлык зурлыгын!..*

# АВЫЛЫМ МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

***Сафиуллина Зөлфирә Тәлгать кызы***
*Балык Бистәсе муниципаль районы*
*МББУ "Иске Арыш төп гомуми белем бирү мәктәбе"*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Безнең төрки бабаларыбыз IV гасырда ук укый-яза белгәннәр. Идел буе Болгар дәүләте чорында мәгърифәт эше нык алга киткән. Чөнки Исламда гыйлем һәрвакыт игътибар үзәгендә булган, уку йортлары тоту изге эш дип саналган. Мөселманнарның һәр мәчете каршында мәдрәсә булган. Әлбәттә, бу мәдрәсәләрнең төп юнәлеше – дини белем бирү, мәдрәсә программасына Коръәнне үзләштерү һәм ятлау, аның тәфсирен, хәдисләрне, шәригатьне һәм гарәп телен өйрәнү кертелгән, аларда белем бирү югары булмый. Әмма халкыбызның мәгърифәтенә нигез салу шу-

лардан башланган бит. Казан ханлыгында иң зур уку йортларының берсе сәед Кол Шәриф мәдрәсәсе булган. Биредә үзенең диненә һәм ватанына чын күңелдән бирелгән шәкертләр тәрбияләнгән. Аларның барысы да 1552 елда Казанны урыс гаскәрләреннән саклаганда һәлак булганнар. Патша хөкүмәте,Казанны сугышып алганнан соң, татар мәчетләре белән бергә алар янындагы мәдрәсәләрне юкка чыгарырга тырышкан. 18 нче йөзнең 70 нче елларыннан башлап, мәдрәсәләрнең хәле шактый җиңеләйгән. Ул чорда Казанда ике уку йорты – Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре, 1780 елда Әмирхания мәдрәсәсе ачыла. XVIII гасыр ахырында атаклы авыл мәдрәсәләре оеша башлый. Кышкар, Мәнгәр, Сатыш, Саба, Бәрәскә, Эстәрлебаш, Мәчкәрә, Тайсуган, Ташкичү авылы мәдрәсәләре шундыйлардан. Ләкин руслаштыру сәясәтенең көче дә кимеми. Шундый шартларда мәйданга мәгърифәтчеләр килә. Алар татарны милләт буларак саклап калуда һәм үстерүдә мәгарифкә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Күп кенә мәдрәсәләр ачыла башлый ”Касыймия”, ”Галия”, ”Хөсәения”, ”Рәсүлия”, ”Буби”. Татарның элекке буын күпчелек күренекле шәхесләре дә нәкъ менә шушы мәдрәсәләрдән чыккан. Кыскасы, бездә гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, аң-белемгә игътибар зур булган, татарлар революциягә кадәр үк гыйлемле халыкларның берсе саналган.

Тормышыбызның һәр мизгеле, һәр өлкәсе гүзәл хатын-кызларыбыздан аерылгысыз. Аларның бөеклеген беркем дә кире кага алмый. Җәмгыятебезнең иң кечкенә берәмлеге булган гаиләнең нигезе, нигездәге туган тел, милләт сакчысы да – хатын-кыз.

Авылыбызда зур ихтирамга лаек укытучыларыбыз Гайнетдинова Фатыйма апа һәм Җаббар абыйларны авыл мәгърифәтчеләре дип атасак, бер дә ялгыш булмас. Мин әлеге чыгышымны шушы мөхтәрәм затларга багышладым.

Фатыйма Шәмәрдән кызы Гайнетдинова 1927 нче елның 22 декабрендә Иске Арыш авылында туа. Башлангыч сыйныфларда Иске Арыш башлангыч мәктәбендә белем ала. Аннары Балыклы Чүкәй һәм Олы Солтан авыллары урта мәктәпләрендә укый. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан педагогия училищесында белем алып, туган авылы мәктәбенә укытырга кайта. Фатыйма апа белән Җаббар абый 40 ел буена бик күп укучыларга белем бирделәр. Алар укыткан балалар илебезнең төрле төбәкләрендә үз урыннарын табып эшлиләр һәм яшиләр. Бүгенге көндә Фатыйма апаның укучылары – Гөлназ Мөҗиповна, Минзилә Нәҗибовна, Роза Гыйльмановна остазларының юлын дәвам итеп, безнең мәктәбебездә укучыларга белем бирәләр. Фатыйма апаны алар һәрвакыт үзләренә өлге

итеп, яратып, хөрмәт белән искә алалар, аның киңәшләрен тоталар. Фатыйма апа 88 нче яше белән барса да, мәктәп белән ныклы элемтәдә тора. Ул – һәрвакыт безнең яраткан кунагыбыз, киңәшчебез, остазыбыз. Матбугат битләрендәге яки телевидение яңалыклары дисеңме, яңа чыккан законнар дисеңме... Фатыйма апа һәрнәрсәдән хәбәрдар, бөтенесен белә, ишетә, тыңлый,үз фикерләрен әйтә.Мәктәпкә килгәч, укучыларга да матур теләкләрен, киңәшләрен бирә. Әти-әниләрне хөрмәт итүне, туган якка, милләтебезгә, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт тәрбияләүне тормыш максаты итеп алырга өйрәтә... Фатыйма апаның эшен безукучылары– Иске Арыш төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары дәвам итәбез. Хәзер балаларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә, халкына, тарихына, туган ягына мәхәббәт уяту, рухи яктан бай, физик яктан камил шәхес тәрбияләү аеруча игътибарга лаеклы проблемаларның берсе булып тора. Үзенең үткәненә һәм тарихына хөрмәт һәм ышаныч белән караган халыкның гына киләчәге бар. Шуңа күрә без олы шәхесләребез, бөек халкыбыз, үткән олы тарихыбыз белән горурланырга, алар рухы белән яшәргә тиешбез. Дәрестә һәм дәрестән тыш вакытларда укучылар белән төрле темаларга презентацияләр, фәнни эшләр башкарабыз. Мәктәп музее да укучыларда милли үзаң тәрбияләүгә, гореф-гадәтләр, йолаларыбызга ихтирам, хөрмәт тудыруда зур роль уйный. Авылыбызда гомер-гомердән бик тырыш халык яшәгән. Алар итек басу, шәл бәйләү, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр. Укучыларыбызны да туган җирен, халкын, милләтен яратучы һәм хөрмәт итүче шәхес итеп тәрбияләргә тырышабыз. Төрле фән атналыкларын, бәйрәм кичәләрен зур әзерлек белән үткәрәбез.Укучыларыбызда милли үзаң тәрбияләү – безнең бурычыбыз.

Ә Фатыйма апабыз бүгенге көндә дә безнең янәшәбездә, остазыбыз, киңәшчебез булып яши. Танылган татар мәгърифәтчеләре рәтенә Фатыйма апа һәм Җаббар абыйны да куярга тулы хакыбыз бар безнең.

# XX ГАСЫР БАШЫ: ФАТИХА АИТОВА МӘКТӘБЕ

***Сөнгатуллина Рәзинә Нурислам кызы***
*Казан шәһәре ГБМБУ “71 нче мәктәп”*
*татар теле укытучысы*

Татар мәгарифенең күп гасырлык тарихы бар. Безнең бабаларыбыз борынгы төркиләр IV гасырда ук укый һәм яза белгәннәр. Идел буе Болгар дәүләте чорында мәгариф эше аеруча алга китә. Татарларның һәр мәчете каршында мәдрәсә булган. 1742 елда аларның саны 536 га җитә. 1858 елда Казан губернасында 430, Оренбург губернасында – 418 татар мәктәбе эшләгән. Рәсәй империясендә татар мәктәбе бернинди дәүләт ярдәменә өметләнә алмаган, әмма шулай булуга карамастан, революциягә кадәр Казан губернасында гына исәпсез күп мәктәпләр һәм алардан югарырак баскычта торучы 845 мәдрәсә исәпләнгән. Тарихи материаллар күрсәткәнчә, татар шәкертләренең грамоталыгы шактый югары булган.

Патша хөкүмәте халыкларның алга, яңалыкка омтылышын гасырлар буе бастырып килде. Рус булмаган халыклар бигрәк тә авыр хәлдә булды, аларның күбесенең үз язмалары да, үз мәктәпләре дә юк, туган телдә мәктәп ачу хокукыннан да мәхрүм иделәр. Җәмгыятьнең яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар барлык хокуклардан мәхрүм булып, кол хәлендә яшәтелделәр.

XIX гасыр ахырларында капитализм үсү буржуазия барлыкка килү илдә җәмгыять тормышы шартларын үзгәртә, прогрессив көчләр барлыкка килә. Халыкның хәлен үзгәртү өчен хәрәкәт башлана. Татарлар арасында башланган хәрәкәтләрнең берсе җәдитчелек хәрәкәте була. Бу – феодализм калдыкларына каршы көрәш, белемгә, яңалыкка омтылу һәм хатын-кыз мәсьәләсен хәл итүгә омтылу була. Милләтне алга җибәрү, аң-белемле яшьләрне тәрбияләү зарурлыгы туа. Андый балаларны-яшьләрне тик аң-белемле аналар гына тәрбияли алуларын аңлап, хатын-кызларны – булачак аналарны укыту, мәдәниятле итү мәсьәләсе алга куела. Гадәттә, кызларга гарәп телендәге догаларны укып ятлый алырлык дәрәҗәдә генә белем бирелә. Һичбер төрле укыту программалары, дәрес бирү системасы булмый. Кызларга коллык, буйсынучанлык әхлагы тукыла. 1905 елгы революция чорында башка бик күп төрле прогрессив хәрәкәтләр белән берлектә, татар кызлары өчен булган бу мәктәпләргә яңалыклар кертү өчен дә киң хәрәкәт җәелә. Кайбер шәһәрләрдә татар кызлары өчен яңа типтагы мәктәпләр ачыла башлый. Шундый мәктәпләрнең берсе Казан шәһәрендә Фатиха Аитова мәктәбе була.

Фатиха Габдевәли кызы Аитова 1866 елда Оренбург өлкәсе Троицк шәһәрендә миллионер Яушев гаиләсендә туа. Үзе бик яшь, матур булуына карамастан, өч хатыны үлгән Казан бае Сөләйман Аитовка дүртенче хатынлыкка кияүгә чыгарга риза була. Ләкин бер зур шарт белән: Фатихага атасы үлгәч, бик зур мирас-байлык кала. Фатиха өчен шул мирастан Казанда татар кызларын укытырга заманча итеп мәктәп салдырып бирергә һәм шул мәктәптә җитәкчелек итүгә комачауламаска. Халкыбызның олы галиме Шиһаб Мәрҗани Фатиханың әнисенең якын дусты, Фатиханың рухи атасы була. Фатиха Аитовага 100 (йөз) мең сумлык мираска халкыбыз өчен кыз балалар мәктәбе салдыру теләге Шиһабетдин хәзрәтнең рухи тәрбиясенең нәтиҗәсе була.

Фатиха Аитова бик тәвәккәл характерлы, куйган максатына һичшиксез ирешә торган шәхес була. Мәктәп ачу шактый читен була. Аитова патша хакимиятенең барлык инстанцияләрендә күп мәртәбәләр була, пристав, губернатор һ.б. белән сөйләшә.Фатиха Аитованың үз җитәкчелегендә мәктәпнең планы-проекты төзелә, раслана һәм (хәзерге Тукай – Татарстан) урамнары чатында йорт салына.

Мәктәп бинасы салыну елларында Фатиха Аитова күрше урамда булган Ләбибә Хөсәения мәктәбенең эш алымнарын, эш барышын өйрәнә. Үзләрен мәгърифәт эшенә багышлаган бу ике ханым төрле мәсьәләләр буенча бергә киңәшеп эш итәләр. Аитова мәктәбенә укытучылар җитмәгәндә дә, Ләбибә Хөсәения үзенең алдынгы укучыларын яңа ачылган мәктәпкә укытучылар итеп җибәрә. Казанда кызлар өчен беренче шәхси татар гимназиясе. 1909 елның 27 августында Казан губернасы халык мәктәпләре директоры М.Н. Пинегин рөхсәте белән Ф. Аитова тарафыннан башлангыч җәдид кызлар мәктәбе буларак ачыла. Ф. Аитованың мирас акчасына мәктәп өчен барлык таләпләргә дә туры китерелеп җиһазланган махсус ике катлы таш бина салына. Мәктәпкә үрнәк итеп Буби һәм Ләбибә Хөсәения кызлар мәктәпләре алына, аларның тәҗрибәсе киң кулланыла (карагыз «Буби» мәдрәсәсе, Ләбибә Хөсәения мәктәбе). Укытучылыкка да аларда белем алган кызлар чакырыла. . Аитова мәктәбе башта дини башлангыч мәктәп булып ачыла. Анда дин дәресләре укытыла. Догалар һәм намаз уку өйрәтелә. Шулар белән бергә татар, рус телләре, арифметика, геогафия, табигатьне өйрәнү, матур язу, рәсем фннәре өйрәтелә. Шулай ук гаилә тормышы өчен кирәк булган аш-су хәзерләү, кисү-тегү, чигү эшләре өйрәтергә Фатиха Аитова аерым осталар чакыра Мәктәпнең даны, Ф.Аитованың абруе елдан-ел үсә. Аитова 1913 елда мәктәбен рус гимназиясе кебек урта белем бирүче, 8 еллык мәктәп итү теләге белән югары органнарга мөрәҗәгать итә, рөхсәт ала алмагач, Петербургка Мәгариф ми-

нистрлыгына хәтле барып җитә. Фатиха Аитованың башлангыч мәктәбе 1916 елда "Казандагы татар кызлары гимназиясе"нә әйләнә.

Аитова мәктәбе татар җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну тудыра. Чит өлкәләрдән Оренбург, Уфа, Троицк һәм башка бирләрдәге мәктәпләрдән аның эш тәҗрибәсен өйрәнергә киләләр. Мәктәптә эш барышы турында газета-журналлар хәбәрләр биреп торалар. Фатиха Аитова мәктәбен тәмамлаган кызлар тормышта үз урыннарын табалар, туган илләренә турылыклы хезмәт итәләр. Алар арасында РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Камская, Татарстанның халык артисткасы композитор Сара Садыйкова, 45 ел гомерен татар музыка сәхнә сәнгатен үстерү эшенә багышлаган җырчы Мәрьям Рахманкулова һәм башкалар.

Фатиха Аитова Бөек Ватан сугышының иң авыр елы – 1942 елда Казанда вафат була.

## РӘМИЕВЛӘРНЕҢ МАТБАГАЧЫЛЫК ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Хуҗанбердиева Чулпан Тимергали кызы,***
*Түбән Кама муниципаль районы Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе "35 нче лицей" югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

